Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

*Ризаэтдин Фәхретдин*

# Көтебе ситтә вә мөәллифләре

## Гыйльме хәдистән

Казан – 2019

УДК 297.1
ББК 86.38
Р 49

*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни мөхәррир:**
тарих фәннәре кандидаты
*Дамир Шәһабиев*

**Басмага әзерләүче:**
филология фәннәре кандидаты
*Айдар Гайнетдинов*

Р 49 **Ризаэтдин Фәхретдин. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән** / Басмага әзерләүче *А. Гайнетдинов*. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. – 104 б.

ISBN 978-5-94981-328-7

«Көтебе ситтә» – хәдис гыйлеменә караган хезмәт. Анда хәдис терминологиясе аңлатыла, хәдис төрләре, үзенчәлекләре билгеләнә, шулай ук хәдисләрне җыеп, җыентыклар төзегән шәхесләрнең кыскача тәрҗемәи хәлләре, эшчәнлекләре, хезмәтләре яктыртыла. Китап ислам дине һәм тарихы белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә, дини уку йорты шәкертләре өчен дәреслек булып кулланыла ала.

ISBN 978-5-94981-328-7 УДК 297.1
ББК 86.38

© ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2019
© Гайнетдинов А., 2019

# Кереш сүз

*Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) исемен телгә алуга ук без милләтебез, динебез өчен бөтен көчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган бөек татар галимен күз алдыбызга китерәбез. Ул – дин, тарих, әдәбият, педагогика һ.б. фән өлкәләре белән бәйле бәяләп бетергесез бик зур мирас калдырган энциклопедик белемле шәхес. Шуңа күрә галимнең һәрбер сүзе, фикере, мәкаләсе, китабы гаять зур игътибарга лаек.*

*Кызганычка каршы, галимнәр, белгечләр тарафыннан Р. Фәхретдиннең бөтен хезмәтләре дә халыкка кайтарылды дип әлегә әйтеп булмый. Кайберләре һаман үз чиратын көтеп ята. Мәсәлән, шундыйлардан «Көтебе ситтә вә мөәллифләре. Гыйльме хәдистән» («Алты мәшһүр хәдис җыентыгы һәм аларның төзүчеләре: Хәдис гыйлеменнән») китабы бар иде. Бу хезмәт 1909 елда язылып, 1910 елда «Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Хәдис вә сөннәт галимнәре кашында мәгъруф улан көтебе ситтә вә шәрехләре, мөәллифләренең тәрҗемәи хәлләре, хәдис гыйлеме хакында бәгъзе бер кирәкле файдаларны мөштәмил рисаләдер. Гыйльме хәдистән» («Алты китап һәм төзүчеләре: Хәдис һәм сөннәт галимнәре каршында билгеле булган алты китап һәм шәрехләре, төзүчеләренең тәрҗемәи хәлләре, хәдис гыйлеме хакында кайбер кирәкле файдаларны үз эченә алган китаптыр. Хәдис гыйлеменнән»), 1913 елда «Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән» исемнәре белән Оренбургның «Вакыт» матбагасында басылып чыккан булган. Инде гасырдан артык вакыт узса да, әлегә кадәр бу хезмәт кириллицада басылып чыкмаган иде, ни өчендер ул игътибардан читтә калган. Чынлыкта исә, «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» китабында күп кенә файдалы мәгълүматлар, киңәшләр, фикерләр урын алган. Бигрәк тә, мәдрәсәләр өчен аның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Ризаэтдин Фәхретдин максат итеп нәкъ менә, беренче чиратта, шәкертләргә дәреслек буларак хезмәт язуны күздә тоткан һәм аны Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерләренә юллаган.*

*Хезмәт хәдис гыйлеменә карый. Анда хәдис терминологиясе тулысынча аңлатыла, хәдис төрләре, үзенчәлекләре билгеләнә, шулай ук хәдисләрне җыеп җыентыклар төзегән шәхесләрнең кыскача тәрҗемәи хәлләре, эшчәнлекләре, хезмәтләре яктыртыла. Нигездә, ислам дөньясында мәшһүр алты хәдис җыентыгы яки китабы турында сөйләгәнлектән, хезмәтнең исеме нәкъ шулай «Көтебе ситтә вә мөәллифләре. Гыйльме хәдистән», ягъни гарәп теленнән сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә, «Алты китап һәм төзүчеләре. Хәдис гыйлеменнән» дип атала. Хәдис китаплары, җыентыклары алар язылмый, ә төзелә, чөнки хәдисләрнең авторы Мөхәммәд пәйгамбәр үзе булганлыктан, аның шул сүзләрен, гамәлләрен сөйләгән сәхабәләр сүзләрен хәдис җыючылар язып алып, шул рәвешле җыентыкларын төзегәннәр. Шуңа күрә бу очракта «мөәллиф» сүзен «автор» яки «язучы» дип түгел, ә «төзүче» дип аңларга кирәк.*

*Галим Ризаэтдин Фәхретдин хәдис гыйлеменә зур игътибар бирү тиешле икәнен байтак хезмәтләрендә ассызыклый, чөнки, ислам дине өйрәтмәләре нигезендә,, Коръәннән кала икенче урында хәдисләр килә. Боларның икесен дә белгән мөселман үзе үк галим-мөҗтәһидкә әйләнә һәм шәригать мәсьәләләрен үзлегеннән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртә, нәтиҗә ясый ала. Ризаэтдин хәзрәт фикеренчә, нәкъ менә шундый дәрәҗәдәге кешеләр күбрәк булса, безнең халык, схоластикадан, тәкълидтән, ягъни төрле дини мәзһәбләргә сукырларча иярүдән арынып, рухи яктан нык үсеш алыр иде. Галим дөрес хәдисләргә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, фикерләп, нәтиҗәләр чыгарып, алар белән гамәл кылырга чакыра; пәйгамбәр сүзләрен фикыһ галимнәреннән башка аңлый алмыйм, дип әйтүчеләрне нык шелтәли һәм тәнкыйтьли. Шулай ук Р.Фәхретдин, зәгыйфь һәм ялган хәдисләр проблемасын күтәреп чыгып, ислам динен төрле «әкиятләр»дән, хорафатлардан, бидгатьләрдән арындырырга омтыла, хәдисләр уйлап чыгаручыларны фаш итә. Аның бу фикерләре «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр», «Җәвамигыль-кәлим шәрехе» һ.б. хезмәтләрендә дә урын алып, бүгенге көндә гаять актуаль булып кала бирә.*

*Бүгенге мәдрәсәләрдә һәм башка дини уку йортларында, нигездә, чит телләрдән тәрҗемә ителгән, чит ил галимнәре язган дәреслекләр белән укыталар, шул ук вакытта исә үзебезнең җирлектә бөек татар мәгърифәтчеләре тарафыннан язылган дәреслекләр читтә кала. Иманыбыз камил, әгәр дә фәкать данлыклы җәдидче галимнәребезнең хезмәтләрен тупласак һәм алар белән генә дини мәгарифебезне үстерсәк, тиз вакыт эчендә безнең арадан да Ризаэтдин Фәхретдин кебек зур дин галимнәре үсеп чыгар иде.*

*Кызганыч ки, хәзерге көндә үзебезнең бөек галимнәребездән калган дини мирасыбызның әле күп өлеше халкыбызга таныш түгел. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, алар гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән шактый аерыла торган телдә язылган. Шуларны истә тотып, без мәшһүр галим Р. Фәхретдиннең хәдисләр гыйлеменә караган әсәрен кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып эшләргә булдык. Моңа хәтле галимнең хәтта кириллицада чыккан кайбер хезмәтләрен хәзерге заман кешесенә аңлавы кыен, чөнки теле бик авыр һәм шактый күп гарәп-фарсы алынмалары, борынгы төрки сүзләр белән чуарланган. Без исә нәкъ менә гади халык укысын, аңласын өчен «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» текстын хәзерге телгә яраклаштырып бирдек, ягъни максималь дәрәҗәдә хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Шулай ук хезмәттә очраган гарәп телендәге җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде, аңлашылмаган сүзләр яки терминнарга җәяләр эчендә кыскача аңлатмалар бирелде. Кадерле укучылар әлеге китаптан файда алырлар, гыйлем тупларлар, дигән теләктә калабыз.*

***Айдар Гайнетдинов,***
*филология фәннәре кандидаты*

# Бүләгем

«Хөсәения» мәдрәсәсенең шәкертләренә, хәдис гыйлеменнән дәрес укыткан вакытта, бу фәнгә караган кайбер мәгълүматны җыеп, бер китап төзү хакында вәгъдә биргән идем. Фәкать бу җирдә сөйләргә тиеш булмаган сәбәп белән, телгә алынган хезмәттән мин аерылдым һәм вакыт үтү белән шәкертләр дә мәдрәсәдән чыктылар яки чыгарылдылар һәм төрле җирләргә теләсә ничек таралып киттеләр. Шулай булса да, вәгъдәмне үтәү максаты белән язган китапны «Көтебе систтә һәм төзүчеләре» исеме белән төзедем һәм телгә алынган шәкертләргә бүләк иттем.

Аллаһ Тәгаләнең рәхмәт капкалары бикләнмәгән сурәттә, башка капкаларның бикләнүләренең карары юк. «Әгәр Аллаһның елгасы акса, башка елгаларның кирәге калмас». Шуның өчен өметем ки, мәҗбүри рәвештә мәдрәсәдән аерылган шәкертләрдән күбесе Хак Сөбханә вә Тәгалә хәзрәтләренең рәхмәте күләгәсендә, киләчәк заманда хөрмәтле адәмнәрдән һәм гыйлем, әдәп әһелләреннән булырлар. Бу көндә нинди җирләрдә булсалар да, булсыннар, минем ахирәт капиталым һәм соңгы запасым булу ышанычым белән мәшгульлегем бу хезмәтемне бүләк рәвешендә кабул итәрләр. Моның белән беррәттән, гамәл дәфтәремә язылганнан соң хәер-дога белән рухымны шат кылырлар. «Кеше үлү белән, фәкать өч нәрсәдән башка, аның гамәлләре аннан киселер: агып торучы сәдака (кешеләргә файда китерүче эшләре), файдалы гыйлеме һәм дога кылучы изге баласы» (Мөслим).

Ризаэтдин бине Фәхретдин,<br>
1327 елның 12 рабигыль-әүвәле [1909 елның 2 апреле],<br>
Оренбург

# Кереш

«Көтебе ситтә (алты китап) һәм төзүчеләре» хакында сүз сөйләргә керешмәстән элек, кыскалык белән булса да, гомуми сурәттә хәдис гыйлеме хакында бераз сөйләргә кирәк. Чөнки хәдис гыйлеме турында булган бу нәрсәләр белән таныш булмыйча, «Көтебе ситтә (алты китап) һәм төзүчеләре» хакында язылган нәрсәләрдән өмет итәрлек дәрәҗәдә файда күренмәс. Шуның өчен бу җирдә, берничә бүлекләргә аерып, хәдис гыйлеме хакында, кыскача булса да, беркадәр бәхәсләр язылачак.

Гасры сәгадәттән [сәхабәләр яшәгән бәхетле гасырдан] аз көннәрдән соң үзенең махсус галимнәре тарафыннан хәдис китаплары төзелде һәм хәдисләрнең иснадлары [чылбырлары] тикшерелде. Сәнәдләр [чылбырлар] һәм равиләр [хәдис риваять итүчеләр] хакында «җәрх вә тәгъдил»ләр [хәдис сөйләүчене гаепләү яки мактау] игълан ителде, зәгыйфь һәм асылсыз булган хәдисләр ачык күрсәтелде; хәтта мәүдуг [ялган] булганнары махсус китапларда җыелып бәян кылынды. Нәтиҗәдә, бу турыда булган хезмәтләрнең һәрберсе үтәлде. Инде хәдис галимнәре каршында сахих дөрес булганнарын «сахих» [дөрес] дип әйтү һәм шуларның фәтваләре белән гамәл кылудан башка чарага ихтыяҗ калмады. Аерым алганда, чаралар күбәеп, гасырлар ерак китү сәбәпле, равиләрнең хәлләрен бүген янәдән тикшерү яки мәйданда булган хәдис китапларында язылган иснадларда башка бер иснадлар табып чыгару мөмкин түгел.

Моның өстенә, хәдис китаплары, махсус адәмнәр тарафыннан төзәтелде һәм хәдис гыйлеменә караган затлар тарафыннан шәрехләр [аңлатмалар] язылды. Ниһаять, болар, заманының көчле булган адәмнәре төзәтүләре белән төрле матбагаларда басылып, дөньяның дүрт ягына нәшер ителде. Инде бу хезмәтләр гыйлем әһелләре кулларында кулланылып торалар. Фәкать әлеге нәрсәләр безнең бу китабыбызны төзүдән тыю түгел. Бәлки, киресенчә, китабыбыз боларга бәйле булганлыктан, гыйлем алу юлында булган кайбер шәкертләр, ихтимал ки, файда алырлар. Өметебез шул. «Дөреслектә, гамәлләр нияткә карап хисапланыр һәм, чынлыкта, һәркемгә ниятләгән нәрсәсе генә булыр».

# I

## Хәдис һәм сөннәт, аларның сөйләнүләре

Хәдис дин әмерләренә караган, галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез Мөхәммәд саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәзрәтләреннән чыккан сүзләр, эшләр, тәкърирләрдән[1] гыйбарәт булыр[2]. «Сөннәт» тә шул ук нәрсә[3].

Кешеләр эшләрен һәм дөньяви мөгамәләләрен дөрес акыл, тәҗрибә һәм фаразлар белән белсәләр дә, шәригать хөкемнәрен рәсүлүллаһ хәбәреннән башка бүтән юл белән белергә көчләре юк. Моның өчен ислам шәригатебезнең бөек мәртәбәле Коръәннән соң икенче дәрәҗәдә булган дәлиле һәм нигезе – хәдис һәм сөннәт. Хөрмәтле рәсүлнең эш һәм тәкърирләре «сөннәт фигълия» һәм «сөннәт гамәлия» дип, сүзләре «сөннәт каулия» дип билгеле булган.

Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең хәдис һәм сөннәтләрен сәхабәләр күреп һәм ишетеп риваять иткәннәр; алардан табигыйннар һәм болардан да тәбгы-табигыйннар. Нәтиҗәдә, сәләфләрдән [борынгы изге мөселман кешеләр] хәләфләр [сәләфләрдән соң килүче буыннар] риваять итеп торганнар.

---

[1] Бер нәрсә эшләнгәнлекне күреп торган хәлдә хөрмәтле рәсүл тарафыннан тыелмаган икән, моңа «тәкърир» дип әйтәләр (үзгәртмәде, тыймады, бәлки, шул көе калдырды).

[2] Кайберәүләр «хәдис»не фәкать пәйгамбәрнең сүзләренә генә кайтарып калдыралар.

[3] «Сөннәт» сүзе түбәндәге мәгънәләргә ия: 1) Капма-каршысы бидгать. Әгәр дә хөрмәтле рәсүл юлына туры килә торган гамәл булса, фәлән кеше сөннәт белән гамәл кыла, дип әйтәләр. Бу юл Коръән һәм хәдис белән ныгытылган булсын. Моның капма-каршысы булганнарга бидгать әһеле дип әйтәләр. 2) Сәхабәләр гамәле. Бер гамәлнең асылы кирәк китапта (Коръәндә) һәм сөннәттә булсын яки булмасын. Әгәр дә сәхабәләр тарафыннан риваять ителгән икән, моңа «сөннәт» дип әйтәләр. Җыелган китап кебек. 3) Фарыз һәм важипнең капма-каршысы. Бу мәгънә белән сөннәт күбрәк фикыһ китапларында кулланыла.

Хәдис гыйлеме элекке вакытларда фәкать күңелләрдә генә саклана иде. Хәдис галимнәре аны ишетер өчен шәһәрләрдән шәһәрләргә һәм илләрдән илләргә йөриләр иде. Соңра, хәдис гыйлемен белгән затлар бер-бер артлы вафат булганнан соң, бу гыйлемне ятлау максаты белән җыентыклар төзергә керештеләр һәм күп китапларны мәйданга чыгардылар.

Хәдис белгечләре тарафыннан мондый хәдис китаплары да тәнкыйтьләнде, төзүчеләрнең равиләре хакында булган өйрәнүләре һәм тырышуларына караган китаплар берничә дәрәҗәләргә аерылды, яхшылары белән яманнары бүленде.

Рәсүлүллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренең үзеннән турыдан-туры ишеткән кемсәләргә бәйле хәдис-шәрифләр бу, ягъни хәбәр мөтәватир, хәбәр мәшһүр, хәбәр вахид дип йөртелгән өч төрле юлның берсе белән ирешергә мөмкин.

**Хәбәр мөтәватир** – шундый хәбәр ки, акыл белән фикер йөрткәндә, ялганлаулары мөмкин булмаган; күп һәм төрле кешеләр тарафыннан риваять ителә[4].

**Хәбәр мәшһүр** – шундый хәбәр ки, беренче гасырда аз кешеләр тарафыннан сөйләнелгән хәлдә, икенче һәм аннан соңгы гасырларда мөтаватир дәрәҗәсенә ирешә.

**Хәбәр вахид** – шундый хәбәр ки, беренче һәм аннан соңгы гасырларда мөтәватир дәрәҗәсенә ирешә алмый.

Хәбәр мөтәватир белән бәйләнгән нәрсәләр хис белән (күреп һәм ишетеп) бәйләнгән нәрсәләр шикелле, «гыйлем якыйни» (асылда, шик төшми һәм үзгәрми торган гыйлем) була. Үзләре барып күрмәсәләр дә, фәкать бер хәбәр белән Мәккә, Истамбул, Петербург, Искәндәрия шәһәрләренең барлыгын белү шикелле. Әгәр дә мөтәватир юлы белән бер хәдис сөйләнелсә, ул хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең үз авызыннан ишетелгән дәрәҗәдә була.

Мөтәватир дәрәҗәсенә ирешмәгән бик күп хәбәр вәхидләрнең, моңа тиеш булса да, уртак бер мәгънәгә ишарә итүләре [сәбәпле], бу ишарә иткән ноктада, «мөтаватир мәгънәви» була.

[4] «Хәбәр мөтаватир» равиләренең галел кеше булулары шарт түгел.

Хатим исемле кемсәнең юмартлыгына ишарә иткән хәбәрләр кебек[5]. Бу да мөтәватир сүзе шикелле «гыйлем якыйни» тапшыра.

Мөтәватир юлы белән сөйләнелгән нәрсәләр «сөннәт фигълия»дә күп булган хәлдә, «сөннәт каулия»дә булуында каршылыклар бар. Кайберәүләр: «Бар», – дип хәтта мисаллар күрсәткән хәлдә, күп кешеләр моны инкяр итәләр. Һәрхәлдә, гамәлләр һәм игътикадлар [ышанулар] хакында бер караштa булган мөтәватир хәдис юк[6].

Хәбәр мәшһүрдән «гыйлем якыйни» белән «зан» [уй] арасында бер гыйлем һәм, икенче төрле әйткәндә, «гыйлем якыйнигә якын зан» яки «занга якын гыйлем якыйни» хасил була. Бу нәрсәне «гыйлем таманинә» дип атыйлар[7].

Хәбәр вахид белән фәкать «зан» гына хасил була. Хәбәр мәшһүр һәм хәбәр вахид белән гамәл дөрес булган хәлдә (чөнки гамәл өчен уй да җитә), дәлилләре «якыйни» һәм катгый булу белән шарт ителгән игътикадлар [ышанулар] дөрес булмый.

Хәбәр вахидтә булган сәнәдләр һәр буында берәр генә заттан гыйбарәт булса, «гариб», икешәрдән гыйбарәт булса, «газиз» дип атала. «Сахих» дип аталыр өчен хәдисләрнең «газиз» булуы шарт түгел. Бәлки, «гариб» хәдисләр дә «сахих» була

---

[5] Сүзләр я берләшкән булсын, я башка булсын, ике мәгънә берләшкән хәбәрләр «тәватүр ләфзый» дип атала. Әмма сүзләр һәм мәгънәләр башка булып та, барысыннан бер уртак мәгънә аңлашылса, моның турында «тәватүр мәгънәви» дип әйтәләр. Мәсәлән, берәү Хатимнең ат бирүен, икенче кеше дөя бирүен, өченчесе акча бирүен сөйли. Башка берәүләр сыйфатлары хакында хәбәр итәләр. Бу төрле хәбәрләрнең барысыннан бер «бирү» мәгънәсе аңлашыла. Бу – юмартлык дигән төшенчә. Шул төрле хәбәрләр Хатимнең юмартлыгы хакында «мөтәватир» була.

[6] Кайберәүләр: «Иннәмәл-әгъмәлү бин-ният» хәдисен һәм: «Мән кәззәбә галәйя мүтәгаммидән...» хәдисен «тәватүр ләфзый» итеп күрсәтәләр. «Тәдриб әр-рави»га мөраҗәгать ителә. Б. 190–191.

[7] Кайбер фәкыйһләр «хәбәр мәшһүр»не «хәбәр мөтаватир» дәрәҗәсендә саныйлар. Мөхәддисләр дә юллар бер-берсенә капма-каршы булу, зәгыйфь равиләрдән һәм кимчелекләрдән сәламәт булу шартлары белән бу фикердә. Фәкать мөтаватир заручи гыйлемне тапшырган хәлдә, мондый хәбәр мәшһүрләр теоретик гыйлемне тапшыра, диләр.

алалар. Имам Бохари да үзенең җыентыгында булган хәдисләрнең «газиз» булуын мәҗбүри санамаган.

Хөрмәтле рәсүлдән турыдан-туры ишеткән кемсәләргә карата хәдисләрнең һәрберсе «мөтәватир» хөкемендә булган хәлдә, «гыйлем якыйни»ны тапшыра. Шул сәбәпле, сәхабәләр заманында бердәм рәвештә кылынган гамәлләр рәсүлүллаһның әмере һәм сүзе белән йөкләнелгәнлектән, бөтен мөселманнар өчен шул рәвешле гамәл кылу тиешле була. Гәрчә, сәнәдләре һәм дәлилләре хакында кирәкле башка бер дәлил күренмәсә дә. Фарыз намазларының вакытлары һәм рәкәгатьләре, зәкят микъдарлары моңа мисал булса кирәк.

# II

# Хәдис гыйлеменең фазыйләте. Риваять һәм дираять хәдис. Хәдис нигезләре хакында басылган хезмәтләр

Хәдис гыйлеменең ислам әһелләре өчен иң фазыйләтле бер гыйлем булуын күп язарга хаҗәт булмас. Ислам диненең, Коръән-шәрифтән соң, икенче дәрәҗәдәге нигезе һәм бинасы хәдис-шәриф булса, бу гыйлемнең никадәр бөек һәм [хәдис] галимнәренең дә хөрмәтле булырга тиешлеге мәгълүм булса кирәк. Галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез [Мөхәммәд пәйгамбәр] хәзрәтләренең: «Бездән нәрсә дә булса ишетеп һәм аны ничек ишеткән, шул рәвешле башкага әйтеп ирештергән кешене Аллаһ сөендерсен, әйтеп ирештерелгән кеше теге беренче ишеткән кешегә караганда яхшырак аңларга мөмкин бит»[8], дигән сүзләрендә булган хәер-догасы һәм кешеләрне хәдисләрне башкаларга ирештерергә чакыруы белән моның хөрмәтле эш булуына дәлил буларак җитә. Хөрмәтле сәхабәләр

[8] Җамигъ Тирмизи. – Т. 2. – Б. 90.

һәм табигыйннар Коръән һәм сөннәт гыйлемнәренә гаять игътибар иттеләр, хәтта ки бер хәдисне үзенең равиеннән турыдан-туры ишетү өчен айлык сәфәрләрдә йөриләр иде[9]. Мөхйетдин бине Гарәби хәзрәтләре: «Хәдис әһелләре кыямәт көнендә пәйгамбәрләр белән бергә кубарылачаклар. Өммәттә аларның һәрберсе чылбыр белән пәйгамбәрләргә тоташкан хәлдә вәхине ирештерүчеләр һәм бу эштә пәйгамбәрләрнең варислары булып торалар. Әгәр дә фәкыйһлар [фикыһ галимнәре] хәдисләр риваяте белән шөгыльләнмәгән булсалар, аларга андый дәрәҗә юк һәм пәйгамбәрләр белән түгел, ә, бәлки, гади кешеләр белән кубарылачаклар. Галимнәр исемен хәдис галимнәренә карата кулланалар, чынлыкта, алар имамнар», – дип әйтә[10].

Хәдис фәнен иң элек «риваять гыйлеме» һәм «дираять гыйлеме» дигән ике бүлеккә аералар. Хәдис нигезләренә һәм терминнарына караган бәхәсләр «риваять хәдис» исемле бүлегенә керә.

Хәдисләрнең рәсүл әфәндебезгә тоташкан иснадларын, равиләрнең гаделлеген һәм кабул ителмәү сәбәпләрен тикшерү, аларның тормыш юллары, эшчәнлекләре белән таныш булу беренче бүлеге булган «риваять гыйлеме»нә керә. «Риваять гыйлеме» буенча хәдисләр: сахих, зәгыйфь, мөнкәр, мәүдуг, шулай ук мөтәватир, мәшһүр, хәбәр вәхид һәм дә болардан башка бик күп төрләргә аерылырга мөмкин.

Иснадлары сәламәт булып җиткәннән соң, шул хәдисләр белән гамәл кылу мөмкин булу-булмавын, аның буенча гамәл кылу итеп тотылудан берәр тыю очравы-очрамавын тикшерү – «дираять гыйлеме».

Рәсүлүллаһ әфәндебез хәзрәтләреннән сөйләнелгән хәдис белән гамәл кылу өчен аның дөрес булуын, кимчелекләрдән азат булуын белергә кирәк булган кебек, эчтәлеге белән гамәл кылмастан [элек], я шәригать, я акыл ягыннан тыелмавын белергә дә күп вакыт ихтыяҗ була. Һәрбер «Калә ән-нәби галәйһис-сәләм» [«Пәйгамбәр галәйһис-сәләм әйтте»] астында язылган гыйбарә хәдис булмаган кебек, һәрбер хәдис тә аның

[9] Ибне Габделбәр. Мохтасар җамигъ бәян әл-гыйлем. – Б. 46–47.
[10] Әл-фүтухат әл-мәккийййә. – Т. 3. – Б. 56.

буенча гамәл кылу хөкемен алмый. Бу нәрсәләрне тикшерү «дираять хәдис» бүлеген тәшкил итә.

Шул сәбәпледер, иң бөек хәдис китапларыннан булган Бохари һәм Мөслим җыентыкларында булган хәдисләрне ислам галимнәре шул хәленчә кабул итми, бәлки, һәрвакыт тикшерәләр. Хәтта ки кайбер урында мәтенендә [текстында] хата барлыгын исбат итәләр.

Хәдис нигезләре хакында басылган хезмәтләр болар:

1. «Әлфииййәтү фи усул әл-хәдис». Шигъри формада язылган бу китап Зәйнеддин әл-Гыйракый ([һиҗри] 805 [ел]) хезмәте булып, үзе Сәхави ([һиҗри] 902) тарафыннан язылган ике данә шәрехе белән бергә [һиҗри] 1303 елда Ләкнәүдә басылган.
2. «Әр-рисаләт әл-мохтасара». Сәййид Шәриф (816) тарафыннан язылган бу хезмәт 4 биттә «Җамигъ Тирмизи» белән бергә басылган.
3. «Әл-мәнзумәт әл-бәйкунииййә». Шигырь формада булган бу хезмәт Зәркани (1122) шәрехе белән бергә 1310 елда Мисырда басылган.
4. «Мөкаддимәт Ибне Салах». Төзүчесе Әбү Гамру бине Салах (643) булган бу китап 1326 елда Мисырда басылган.
5. «Тәкърибән-Нәвави». Имам Нәвави (676) хезмәте булган бу китап имам Сөютыйның (911) «Тәдриб әр-рави» шәрехе белән бергә 1307 елда Мисырда басылган.
6. «Нөзһәт ән-нәзар фи тәүдыйхи нөхбәт әл-фикер». 1295 елда Канбурда басылды. Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852) хезмәте. Китап читендә язылган Муса әфәнде [хезмәте] белән 1328 елда Оренбург шәһәрендә басылды.
7. «Мөкаддимәт әш-шәйхи Габделхак». Габделхак әд-Дәһләви хезмәте булган бу китап «Мишкят әл-мәсабих» тарафларында басылды.

# III

## Хәдис, хөрмәтле сәхабәләр һәм табигыйннар

Хөрмәтле рәсүл вафатында сәхабәләр 124 мең микъдарында булган, дип санала[11]. Болар арасында кайберләре бик күп хәдис риваять иткән хәлдә, кайберләре уртача һәм кайберләре бик аз риваять иткән. Һичбер хәдис риваять итмәгәннәр дә боларның санына кергәнгә күрә дә, шулай күп булса кирәк. Хәдис риваять итү-итмәү хакында кайбер сәбәпләр дә булып, аларның кайберләре хәдис китапларында искә алынган[12].

Габдулла бине Гомәр (аның хәдисе 2630), Әбү Һөрәйра (аның хәдисе 5374), Әнәс бине Мәлик (аның хәдисе 2286), мөэминнәр анасы Гайшә (аның хәдисе 2210), Габдулла бине Габбас (аның хәдисе 2660), Җабир бине Габдулла (аның хәдисе 2540), Әбү Сәгыйд әл-Худри (аның хәдисе 2170) һәм башкалары беренче төркемнән[13].

Тугры хәлифәләр, Габдулла бине Мәсгуд, мөэминнәр анасы Өмме Сәләмә, Бәраи бине Газиб, Гыймран бине Хөсайн, Габдулла бине Гамру бине әл-Гас[14], Мөгыйра бине Шугбә, Сәгъд бине Әбү Вәккас, Әбү Муса әл-Әшгари, Әбүзәр әл-Гаффари, Җабир бине Сәмура, Әбү Катада, Сәмура бине Җүндүб

---

[11] Голүм әл-хәдис лиибни Салах. – Б. 121; Тәкъриб ән-Нәвави. – Б. 206.

[12] Сахих әл-Бохари. – Т. 1. – Б. 35–36.

[13] Иң күп риваять иткән сәхабә Габдулла бине Гомәр бине әл-Хаттаб икәнлеге Әбү Һөрәйраның бер хәдисеннән аңлашылыр. Сахих әл-Бохари. – Т. 1. – Б. 36. Тик Габдулла бине Гомәрдән риваять итүчеләр Әбү Һөрәйрадан риваять итүчеләргә караганда азрак булган булсалар кирәк.

[14] Хөрмәтле сәхабәләр арасында Габдулла исемле булган сәхабәләр, Гыйззеддин Ибнел-Әсирнең «Өсдел-габә»дә язылганча, ике йөз егермегә кадәр. Болар арасында иң күп гыйлем таратучылары «Габәдилә» дип танылганнар («Габәдилә» күплек санда «Габдәл» була). «Габәдилә» дип хәнәфиләр Габдулла бине Гамр, Габдулла бине Габбас, Габдулла бине Мәсгудне саныйлар, хәнәфиләрдән башкалар исә Габдулла бине Мәсгуд урынына Габдулла бине Гамру бине әл-Гасны кую белән Габдулла бине Зөбәерне кушалар. Хәнәфиләрчә өч, башкалар фикеренчә дүрт.

икенчеләрдән. Боларның иң күп билгеле булган хәдисләре 1000 микъдарында була.

Сәгъд бине Зәед бине Гамр[15], мөэминнәр анасы Өмме Хәбибә, Гакыйль бине Әбү Талиб һәм башкалар өченче сыйныфтан булып, Зөбәер бине әл-Гавам һәм башкалар дүртенчеләрдән[16].

Сәхабәләрдән соң, хәдис һәм сөннәт гыйлеме белән шөгыльләнүчеләр хөрмәтле табигыйннар булып, аларның иң бөекләре һәм гыйлем таратулары буенча күп хезмәт иткәннәре шулар: Сәгыйд бине әл-Мөсәййиб, Касыйм бине Мөхәммәд бине Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, Гурвә бине Зөбәер бине әл-Гавам, Хариҗә бине Зәед, Әбү Сәләмә бине Габдрахман бине Гауф, Гобәйдулла бине Габдулла бине Гутбә, Сөләйман бине Йәсар (табигыйннар заманында бер вакытта Мәдинә шәһәрендә булып, шәригать гыйлеме, аеруча хәдис-шәриф һәм сөннәт гыйлеме таратулары белән бу җиде зат «фөкаһаи сәбга» [«җиде фәкыйһ»] дип танылдылар)[17], Сәлим бине Габдулла бине Гомәр бине әл-Хаттаб, Әбүбәкер бине Габдрахман бине әл-Харис, Галкамә, Мәсрук, Кәгъб әл-Әхбар, Шүрәйх, Мотарриф, Хәсән әл-Басри, Ибраһим ән-Нәхәгый, Сәгыйд бине Җабир, Ибне Сирин, Шәгъби, Тавус бине Кәйсан, Гата бине Йәсар, Мөҗаһид, Гыйкримә, Гата бине Әбү Рабах, Нәфигъ, Мәкхуль, Вәһеб бине

---

[15] Кайберәүләр моның ривәяте юк, диләр.

[16] Сахих Бохари. – Т. 1. – Б. 35.

[17] Бу сүз Ибне Салахның «Голүм әл-хәдис» исемле хезмәтеннән алынды. Әбү Сәләмә бине Габдрахман урынына Габдулла бине әл-Мөбарәк, Сәлим бине Габдулла бине Гомәрне һәм Әбү әз-зинәдтә Әбүбәкер бине Габдрахман әл-Харисны саныйлар. Хорафат әһелләре һәм дин сатучылар, гүя, «фөкаһаи сәбга» исемнәре язылган нәрсәләр утларда янмас һәм суда батмас, урланмас, бәлә-казаларга очрамас, дип ялганнар уйлап чыгарып, ислам әһелләренең байлыгын җыю коралы итеп алалар. Рәсүлүллаһ, бәлки, Хак Сөбханәһү вә Тәгалә хәзрәтләре исеме язылган нәрсәләрдә моның белән хасиять булмасын да, гөнаһсыз түгел «фөкаһаи сәбга» исемнәрендә бу табигый булмаган нәрсәләр булсын, имеш. «Фөкаһаи сәбга»ның хасиятьләре исемнәрендә түгел, бәлки, тараткан гыйлемнәрендә.

Мөнәббиһ, Хафса бинте Сирин, Гомрә бинте Габдрахман[18], Зәйнәб бинте Кәгъб, Гайшә бинте Сәгъд бине Әбү Вәккас, Зөһри Мөхәммәд бине Шиһаб, Гомәр бине Габделгазиз, Катада, Һишам бине Гурвә, Ибне Җөрейҗ, Ибне Әбү Ләйлә, Ибне Исхак, Әүзагый, шәйхелислам Шогбә бине әл-Хәҗҗаҗ, Ибне Әбү Зиэб, Мәҗишун, Ләйс бине Сәгъд, Фудайл бине Гыяз, Суфьян бине Гуяйнә, Габдулла бине әл-Мөбарәк[19] һәм башкалар.

# IV

# Хәдис һәм мәшһүр мөҗтәһидләр

Хәдис риваять итүдә мәшһүр мөҗтәһидләрнең хәлләре төрле булып, кайберләре бик күп хәдис риваять иткән хәлдә, кайберләре бик аз риваять иткән. «Мәшһүр мөҗтәһидләр» дигән сүз исә бер җәмгыятьтә махсус кагыйдәләргә нигезләнгән, иярүчеләре булган кемсәләр. Юкса, һиҗрәттән соң беренче, икенче, өченче йөзләрдә гыйлем белән исем чыгарган кемсәләрнең күбесе, иярүчеләре булса-булмаса да, мөҗтәһидлек мәртәбәсендә булалар иде. Моның белән кемсәләрнең үзләренең тормыш юлларын да ятлау, риваять иткән булган хәдисләрне белеп бетерү кеше куәтеннән түгел.

Мәзһәбләре ислам дөньясында билгеле булган, азмы-күпме иярүчеләре булган мәшһүр мөҗтәһидләр болар: Әбү Хәнифә, Мәлик, Суфьян Сәүри, Ибне Әбү Ләйлә, Әүзагый, Суфьян бине Гуяйнә, Ләйс бине Сәгъд, Шафигый, Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя[20], Дауд бине Гали Заһири, Бакый[21] бине Мәхләд

---

[18] Болар икесе «сәййидәт әт-табигыйн» дип танылган. Голүм әл-хәдис. – Б. 124.

[19] Төрек нәселеннән олуг бер галим.

[20] «Раһуя» фарсыча булган «раһ» белән «вия»дән ясалган. Сәфәрдә вакытта тууы сәбәпле, «Раһәвәйһ» дип исемләнгән. Тел һәм әдәбият галимнәре «Раһуя»ны «сибуя» һәм «нәфтуя» кебек «уау»ның һәм аның алдында булган хәрефнең фәтхәсе, «йа»ның сәкене белән, мөхәддисләр

Әндәлүси, Әбү Җәгьфәр Мөхәммәд бине Җәрир Табари, Ибне Хөзәймә, Әбү Сәвүр Ибраһим бине Халид Кәлби, Ибне Хәзем, Әбү Габдулла Җәгьфәр әс-Садыйк бине Мөхәммәд әл-Бакыйр.

Алар арасында башкаларга караганда аз риваять иткән мөҗтәһид – Әбү Хәнифә хәзрәтләре. Соңгы авторлардан берәү[22] аның хәдисләрен 500 белән 1000 арасында булганын якынча билгели. Мөҗтәһидләрнең хәдис риваять итүләре хакында булган бәхәсендә Ибне Хальдун: «Әбү Хәнифә радыяллаһү ганһү 17 хәдис яки шул тирә риваять итте» дисә дә[23], бу гыйбарәдә кайбер сүзләр төшеп калган булса кирәк. Чөнки Әбү Хәнифә башка мөхәддисләр шикелле Хорасан, Мисыр, Йәмән һәм Нисапур кебек урыннарда йөрмәсә дә, бөек галимнәрдән һәм мөҗтәһидләрнең берсе булуына шөбһә юк. Шундый бер мөҗтәһид өчен унҗиде хәдис бик аз булса кирәк. Әбү Хәнифә хакында Хафиз Зәһәби: «Әбү Хәнифә Гата, Нәфигъ, Габдрахман бине Һүрмүз әл-Әгъръҗ, Гади бине Сабит, Сәләмә бине Көһәйл, Әбү Җәгьфәр Мөхәммәд бине Гали, Катәдә, Гамру бине Динар һәм Әбү Исхак һәм башка бик күп кешеләрдән риваять итә», – ди[24]. Бу телгә алынган затларның һәрберсе олуг мөхәддисләрдән, шулардан хәдис ишетеп тә, бөтен хәдисе унҗиде генә булу мөмкин түгел. Һәрхәлдә, сүзләре төшеп калуын төгәл белергә куәтебез булмаса да, Ибне Хальдун гыйбарәсендә хата барлыгына шөбһәбез юк[25]. Бу хата Ибне

---

«уау»ның сәкене һәм «һа»ның даммәсе, «йа»ның фәтхәсе белән укыйлар.

[21] Бу кемсәнең исеме төзүченең хатасыннан булса кирәк, «Мөкаддәмә вәфият әл-исляф»тә «Тәкый» дип басылган.

[22] Зәрканиның «Әл-мөватта» шәрехендә.

[23] Т. 1 – Б. 217.

[24] Тәзкирәт әл-хөффаз. Т. 1. – Б. 151.

[25] Ибне Хальдун гыйбарәләрендә башка урыннарда ялгышлары барлыгы мәгълүм булганлыктан, бу җирдә ялгыш булачагында икеләнүебез булмады. Хәтта телгә алынган гыйбарә белән бергә килгән: «Мәлик рәхимәһуллаһның да «Мөватта» китабында булган.300 тирәсе хәдис дөрес дип саналды» җөмләсе дә дөрес түгел. Чөнки имам Мәликнең «Мөватта»сында булган хәдисләрнең мөснәдләре генә дә моннан бик күпкә артыграк.

Хальдунның үзендә түгел, бәлки, күчереп язучылар тарафыннан ясалган. Әбү Хәнифәнең риваяте аз булуы – башкаларга караганда гына. Бу да сөннәт һәм хәдис гыйлемнәренә әһәмият бирмәүдән яки аларның кыйммәте аз булуыннан түгел, бәлки, шуны таләп иткән башка бер сәбәпләргә күрә.

Ниятләренең һәм максатларының хаҗәтенә, табигать һәм вөҗданнарының мәҗбүр итүенә күрә, кайбер сәләф [борынгы изге] галимнәр төзегән китапларын һәм җыелган хәдисләрен хәтта яндырганнар[26]. Шул сәбәпле, кайберләре үзләренең мисаллары белән аз риваять иткән булса да, гаҗәп булмас. Заманыбызда галим һәм куәтле мөселман булган шәех Җәмаледдин әл-Әфганиның бөтен хезмәтләре гәҗитләрдә язылган булганга, кайбер мәкаләләре белән бер-ике сан кыска китапчыклардан гыйбарәт. Бу нәрсә исә югарыда күрсәтелгән хәзрәтләренең язу өлкәсендә көчсезлегенә, каләменең зәгыйфьлегенә юрау булмый. Шуңа карамастан, Әбү Хәнифә хәзрәтләре тарафыннан риваять ителгән хәдисләр соңгы галимнәр тарафыннан «Мөснәд Әби Хәнифә» исеме белән китап рәвешендә төзелгән һәм кайбер нөсхәләре бастырылган. Күргәнебезчә, бер нөсхәсендә булган хәдисләр унҗиде микъдарында гына түгел, бәлки, йөзләрчә.

Кайбер кемсәләр: «Хәдис риваять итүдә Әбү Хәнифәнең шартлары бик авыр иде, шуның өчен башкаларга караганда хәдисе аз булды» – дисәләр дә, моңа каршы: «Әбү Хәнифәнең шартлары никадәр авыр булса да, булыр, имам Бохари шартларына караганда җиңел иде» – дип бәхәсләшүчеләр бар. Нәрсә генә булмасын, бу мәсьәлә ул кадәр әһәмиятле түгел. Мөҗтәһид өчен, үзенә кирәк кадәр хәдис риваять итсә, җитәр, артыграк риваять итү-итмәү үзенең ихтыярында. «Әгәр белмәсәгез, белгән кешеләрдән сорагыз!» [Коръән, 21:7].

---

[26] «Куррау сәбга»тән булган Әбү Гамру бине әл-Галәи әл-Мазәни әл-Басри җирдән өй түбәсенә кадәр тезелеп торган китапларын яндырганы риваять ителә. Вәфият әл-әгъян. Т. 1. – Б. 386.

# V

# Хәдисләрне язу хакында рөхсәт һәм тыюлар

Олуг дәрәҗәле Коръән пәйгамбәрләрнең солтаны – хөрмәтле рәсүл әфәндебез хәзрәтләре заманында һәм аның әмере белән язылып торган хәлдә, хәдисләрне язу хакында рәсүл саллаллаһү галәйһи вә сәлләм тарафыннан тыюлар булды. Моның белән беррәттән, хәдисләрне язу хакында рөхсәт итүне белдергән хәдисләр дә бар. Рөхсәт хәдисе буларак Мәккәне алган көндә: «Фәләнгә язып бирегез» хәдисе[27] һәм тыю хәдисе буларак «Минем сүзләрне язмагыз һәм кем миннән Корәннән башка нәрсәне язды, бетерсен» хәдисе[28] дәлил итеп китерелә. Фәкать рөхсәт хәдисләре белән тыю хәдисләре бер җиргә китерелгәндә, тыю хәдисләре куәтле булачагы мәгълүм. Чөнки рөхсәт хәдисләре кайбер шәхесләргә һәм кайбер вакытларга багышланган булган, ә тыю хәдисләре гомуми [мәгънәдә]. Гасры сәгадәттә Коръән-шәриф язылган, хәдисләр язылмаган. Язу түгел, хәтта риваять итүдән дә кайбер әмирләр тарафыннан тыелуы риваять ителә. Хәзрәти Әбү Һөрайра : «Мин сезгә хәдисләр сөйләдем. Әгәр Гомәр бине Хаттаб заманында сөйләгән булсам, ул мине таяк белән суктырган булыр иде» – дигән[29]. Шулай ук Караза бине Кәгъб: «Гомәр бине Хаттаб безне Куфа шәһәренә җибәргәч, шәхсән үзе безне Саррар дигән җиргә кадәр озатты һәм шунда сорады: «Нәрсә өчен мин монда сезнең белән килгәнемне беләсезме?» Без җавап бирдек: «Аллаһ

[27] Сахих әл-Бохари. – Т. 1. – Б. 36.

[28] Сахих Мөслим. – Т. 2. – Б. 393. Бу хәдис-шәриф шәрехендә имам Нәвави: «Әйтелде ки: чынлыкта, бергә кушылып, укучы буталмасын өчен, хәдисне Коръән белән бергә бер биткә язу тыелды. Аллаһ белүчерәк», – дип бер сүз сөйли. Т. 12. – Б. 412.

[29] Мохтасар җәмигъ бәян әл-гыйлем. – Б. 175. Шуңа мөнәсәбәт белән замандашы булган бер зат: «Әгәрдә Әбү Һөрәйра вафаты көненә кадәр хәзрәти Гомәр яшәгән булса иде, хәдисләрнең бик күбесен риваять итмәячәк, имеш», – ди.

илчесенең иярчене буларак һәм әнсарлар хакы өчен». Ул әйтте: «Ләкин мин шушы сөйләшү исегездә калсын өчен сезнең белән килдем. Анда сез Коръәнгә карата нәфрәттән йөрәкләре кайнап торган казан шикелле шаулап торучы халык янына килерсез. Алар сезне күргәч, муеннарын сезнең тарафка сузып, әйтерләр: «Мөхәммәд иярченнәре!» Шуңа күрә анда рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәдисләрен азрак сөйләгез. Моннан тыш, мин сезнең белән аз гына булса да сәфәрдә катнаштым»»», – дип риваять итә[30].

Рөхсәт белән тыю хәдисләрен куллану хакында имам Нәвави: «Рөхсәт – онытырга курыккан кеше өчен, ә тыю – бу нәрсәдән курыкмаган һәм язуына таянган кеше өчен. Яки Коръән белән кушылудан курыккан вакытта тыелды һәм ул куркудан имин булганда рөхсәт ителде», – дип мөрәҗәгать итә[31].

Пәйгамбәрләр горурлыгы булган әфәндебез хәзрәтләре Коръән-шәриф кебек хәдисләрне дә гыйбарәләре, сүзләре белән ятлау һәм Коръән-шәриф кебек, ләкин Коръәннән аерым рәвештә, язу хакында әмер итә иде. Шөбһә юктыр ки, хөрмәтле сәхабәләр хәдисләрне дә үзенә [күрә] башка рәвештә, гаять диккать белән ничек ишеткән, шул сүзләр белән ятлаганнар, арттыру һәм киметү ихтималларын калдырмыйча кәгазьләргә язган булырлар иде, шул сәбәпле, өммәттә таралып, ике китап кушылган булыр иде. Гасры сәгадәттән башлап, бер-берсеннән аерым рәвештә язылулары сәбәпле, олуг дәрәҗәле Коръән белән хәдисләрне катыштырмау һәм халыкларны да шөбһәләндерү ихтималы юк иде. Моннан тыш, Коръән-шәрифнең теле гаҗәп булу сәбәбле, сүзендә гаҗәплелек булмаган хәдисләр белән катышуы шөбһәләнү китереп чыгармый иде. Шуңа күрә рәсүл хәзрәтләреннән ни кадәр хәдис чыкса, һәммәсе мәгълүм һәм саналган була, мәүдуг [уйлап чыгарылган], ялган хәдисләр булу ихтималына, хәдис буенча каршылыкларга, яла ягуга, ялган сүзләргә юллар калмый иде. Шул сәбәпле, хәдис гыйлеме һәркем өчен көн кебек ачык була, җәрех вә тәгъдилләр

[30] Сөнән Ибне Маҗә. Т. 1. – Б. 9. Хәдистә булган «һәзиз» тавыш мәгънәсендә, «мәрҗәл», якынча, казан мәгънәсендә.
[31] Тәкъриб. – Б. 150.

өчен кагыйдәләр төзүгә, иснадлар тикшереп, тоташкан яки киселгән, кабул ителгән яки кабул ителмәгән һәм башка моның кебек бәхәсләргә керергә юл калмый, хаҗәт төшми иде. Фәкать мондый бер хәл булмаган, бәлки, хәдисләр таркау һәм фәкать күңелләрдә генә һәркемгә мәгълүм булган рәвештә калган. Бу турыда безгә мәгълүм булмаган олуг сәбәпләр [дә] булуында шөбһә юк, безгә мәгълүм булганнары болар:

1) Аерым-аерым буларак ике бөек китап язу мөмкин булса да, бу хәл гасры сәгадәттән күпкә соң булган мәдәният гасырларына караганда [шулай]. Кәгазь булмаган һәм язучылар да сирәк булган гасры сәгадәткә нисбәт белән бу эш мөмкин булмас иде. Хәтта ки Коръән-шәрифнең дә Мәккәдә иңгән өлешләренең күбесе күңелләрдә сакланып, бары тик Мәдинәгә һиҗрәттән соң гына язылган. Моның сәбәбе – Мәккәдә булган хәлләрнең моңа ирек бирмәве булган.

2) Коръән-шәрифнең теле гаҗәп булса, бу нәрсә бары тик төзеклек һәм ятышлылык кагыйдәләре белән таныш булган аерым адәмнәргә һәм биек дәрәҗәләргә караган, бу да өч аять микъдары булу белән шарт ителгән. Әгәр дә Коръән-шәриф рәвешендә хәдисләр дә язылып барылса, әйткәнебезчә, адәмнәрдән башкалар да өч аятьтән аз булган хәдисләрдә һәрвакыт буталану һәм катышу ихтималы мәңге булыр иде. Моннан саклану йөзеннән хәдисләрне язудан тыю булган.

3) Хөрмәтле рәсүл үзе ширек бишегендә барлыкка килеп, мөшрикләрнең рухи хәлләре белән камил таныш булганлыктан, бөтен гайрәтен шуның орлыгын өзәр [бетерү] өчен сарыф итә иде һәм мөселманнарның бу адашуына кире кайтуларына сәбәп булачак нәрсәләрдән һәрвакыт саклау чараларын күргән. Әгәр дә Коръән белән бергә таралган рәвештә икенче бер китап буларак хәдис калган булса, кешеләрнең аны Коръән-шәрифкә тигез дәрәҗәдә тотачакларыннан һәм күпләрнең хәтта ике китапның ияләре арасында, Аллаһ сакласын, кайбер нәрсәләрдә тигез, дип уйлаулары ихтималыннан куркып, зарарсызрак әмерләрдән булган тарафны өстен күреп, хәдисләрне яздырмаган булса кирәк. Ислам дине камил җиткереләчәге [Аллаһ тарафыннан] тәэмин ителгәнлектән шулай уйлап эш итүдән тыю

күрелмәгән. Хәдисләр, кирәк булса, язылсын, кирәк булса, язылмасын, өммәткә тәмам ирешүенә шөбһә юк.

Хәдисләрне язуда, риваять итүдә булган тыю дәлилләренең ятлау мәсьәләсенә катнашы юк һәм ятлаудан тыю барлыгы риваять ителми. Ихтимал ки, хәдисләрне язудан тыю, кешеләр язуларга таянып, ятлауга әһәмият бирмәсләр, дигән сәбәпкә нигезләнгәндер.

## VI

## Хәдис һәм тарих

Ислам дөньясында тарих гыйлеменең барлыкка килүенә берничә сәбәп бар. Хәдис гыйлеме буларак бу фәнгә нигез салучылар мөхтәрәм мөхәддисләр булган. Чөнки алар өчен вакыйгаларның вакытларын белү, вакыйгалар арасында булган табигый хәлләрне язу, хәдисләрдән гыйбарәт булган нәрсәләргә һәм хәдис гыйбарәләренең дәлилләренә юл хәзерләү кирәк иде. Моннан тыш, исемнәрдә һәм күньяләрдә [баласы исеменнән ясалган кушаматларда] уртак равиләр яки вакыйгаларда катнашучыларның күп булуыннан, аларның арасын аеру өчен фамилияләрен, кабиләләрен белү тиеш иде. Шулай ук «җәрх вә тәгъдил» [хәдис сөйләүчене гаепләү яки мактау] кагыйдәләрен йөртү өчен мондый кемсәләрнең аерым һәм гомуми хәлләрен, кайберләренә бирелгән кушаматларның сәбәпләрен өйрәнергә мәҗбүр булалар иде.

Бу хезмәтләрнең нәтиҗәсе буларак, мөхәддисләр күп кавемнәрнең, кабиләләрнең иҗтимагый, сәяси, икътисади хәлләрен аңларга ирешә алганнар һәм бу кавемнәр арасында дәвам иткән вакыйгалар, хәлләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклап торганнар. Коръән-шәрифнең кайбер аятьләре Мәкки [һиҗрәткә хәтле иңгән], кайберләре Мәдәни [һиҗрәттән соң иңгән] булуын тикшергәннәре кебек өйдә һәм сәфәрдә, төнлә һәм көндез иңүләренә кадәр, шулай ук иң элек иңгән һәм иң соңгы иңгән булган аятьләрне һәм башка моның кебек хәлләрне

берәм-берәм җентекләп тикшергәннәр. Шул тырышлыклары сәбәпле, хәтта сәләфләр гасырыннан башлап, Коръән һәм сөннәт гыйлемнәре белән бергә тарих гыйлеме килеп чыккан һәм беренче тапкыр тарих китаплары хәдис әһелләре тарафыннан язылган. Бохари, Табари, Зәһәби, Кәлби, Ибне Гасакир[32], Ибне Хатыйб, Бәлазүри, Ибне әл-Әсир, Әбү Нөгайм, Вакыйди, Гайни, Сөютый, Әбү Хатим әс-Сиҗистани, Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани[33] һәм башкалар бу җөмләдән.

Мөхәддисләрнең остазы булган имам Шафигый хәзрәтләренең егерме елга кадәр тарих гыйлеме белән мәшгуль булуы һәм «Фикъһе гыйлеме белер өчен тарих белү зарур» – дип әйтүе риваять ителә. Суфьян Сәүри: «Риваять итүчеләр ялганлый башлагач, без аларга каршы тарихны кулландык», – дигән[34]. Әл-Хәмиди дә хәдис шәехләренең тормыш юлларын өйрәнүне хәдис гыйлеменнән санаган[35].

## VII

## Сәнәд һәм мәтеннәр, бу турыда булган вазыйфалар

«Мәтен» дип рәсүл әфәндебез хәзрәтләреннән чыккан гыйбарәләргә һәм «сәнәд» дип «хәдисләрне фәләннән фәләнгә» дигән кебек шул мәтенне сөйләүдә булган равиләргә әйтәләр. Сәнәдсез әйтелгән хәдисләр «мөрсәл» исемле булалар.

---

[32] Әбү әл-Хәсән Гали бине Хәсән бине Гасакир олуг мөхәддисләрдән иде. Фәкать Димәшкъ (Дамаск) шәһәрендә булган галимнәрнең тәрҗемәләре хакында язган булган тарихы үз каләме белән сиксән том. Бу хезмәт төзүче нөсхәсеме яки башкамы, бер нөсхә Димәшкъ шәһәрендә булуы риваять ителә. Ибне Гасакир 571 дә вафат булган.

[33] Бу көннәрдә Әбү Хатим әл-Сиҗистаниның «Китаб әл-мөгаммәрин» исемле хезмәте һәм Ибне Хәҗәр әл-Гаскаланинең дә «Табакат әл-мөдәллисин» исемле китабы Мисырда басылды.

[34] Голүм әл-хәдис. – Б. 154.

[35] Тәдриб әр-рави. – Б. 254.

Хәдис риваять итүчеләрнең мөселман, акыллы, гадел, балигъ булулары шарт. Боларның шарт булуы күбрәк галимнәргә карата булып, хакыйкаттә, һәрбер шарт хакында низаглашучылар булганлыктан, [бу эштә] бердәмлек булмаган. Моннан тыш, кайбер мөхәддисләр үзләреннән аерым шартлар да тәкъдим иткән. Бу аерым шартлар күп вакытта бер рәвештә булмаганлыктан һәркемнең шарты үзенә карата була. Шулай ук акыл белән гаделлек аршин һәм ташлар белән үлчәнә торган нәрсәләрдән булмаганлыктан, кайбер маддәләрдә каршылыклар чыккан. Бер кемсәнең моның [берәр кешене] «гадел» дип белүе икенче берсе тарафыннан «җәрх» ителә [тәнкыйтьләнә, кире кагыла] һәм бер мөхәддис тарафыннан «акыллы» дип уйланылган кемсә икенчесе янында акылына зәгыйфьлек килгән, дип хөкем ителенә. Бик күп мөхәддисләр тарафыннан «ышанычлы имам хафиз» дип шәһадәт бирелгән һәм хәдисләре дә имам Бохари тарафыннан кабул ителгән Әхмәд бине Салих Әбү Җәгьфәр әт-Табари әл-Мисри хакында имам Нәсаи: «ышанычсыз», дигән[36]. Моның мисалларын язар булсак, сүз озаер. Хәдисләрнең сахих булу-булмаулары хакында булган күп дәгъваларның чыгуы бу сәбәпләрдән була. Һәрбер мөхәддис үз фикерендә калуыннан, гомуми алганда, күп низаглар хәл ителми, бәлки: «Бу хәдис фәлән мөхәддис фикере буенча, сахих һәм фәлән мөхәддис буенча, сахих түгел яки зәгыйфь», – дип аңлатырга мәҗбүр булабыз. Имам Мәлик каршында «Әлмөватта»да булган хәдисләр генә сахих булуы риваять ителә. Хәлбуки, «Көтебе ситтә» [«Алты китап»] һәм «Мөснәд»ләр белән чагыштырганда, анда булган хәдисләр бик аз. Имам Мәлик хәзрәтләренең бу фикерләре буенча, кыямәт көне билгеләре хакында булган хәдисләрнең хәлләре ничек булачактыр?

Мөтәватир булмаган бер хәдиснең сахих булуы хакында мөхәддисләр тарафыннан низаг булмаса, моңа карап та: «Бу хәдис якыйни (ышанычлы) рәвешендә рәсүлүллаһтан чыккан», дип хөкем итү мөмкин булмый. Чөнки сәхабәләр катнашканлыктан, пәйгамбәрләрдән кала башка кешеләр кимчелексез булмауларыннан, бу турыда ялгышулары яки онытулары, бер

[36] Тәдриб әр-рави. – Б. 262, Тәзкират әл-хөффаз. – Т. 2. – Б. 79.

хәдис урынына икенчесен сөйләүләре яки хөрмәтле рәсүлдән чыккан мөбарәк сүзләр урынына фәкать мәгънәне генә сөйләүләре мөмкин. Бу хикмәткә нигезләнгән ки: мөтәватирдән башка хәдисләр белән якыйн [ышаныч] хасил булмас», диләр. Якыйн [ышаныч] хасил булмаган хәдисләр белән, әлбәттә, игътикадлар [ышанулар] нык булмас. Кайбер гакыйдә китапларында кыямәт көне билгеләре хакында булган хәдисләргә нигез итеп Дәҗҗал һәм Мәһди чыгуы, Гайсә иңүе кебек бер төркем нәрсәләр телгә алынса да, күбесенчә, болар китапларын фәкать катгый рәвештә нык булган игътикадларга [ышануларга] кайтарып калдырмаганнар, бәлки, чакырылмаган кунак буларак уйлауны да керткәннәр. Бик күпләренең икенчел дәрәҗәдә булган имамлык бәхәсләре гакыйдә китапларына кертелүләре безнең фикеребезне куәтли булса кирәк.

Беренче гасырда хәбәр вахид дәрәҗәсендә булуыннан, монда телгә алган ихтималлардан хәбәр мәшһүрләр дә сәламәт түгел. Чөнки хәдисләрдә фәкать мәгънәне сөйләү дөрес булып, мәгънәне исә һәркем үзенең аңына һәм аңлавына күрә сөйләве табигый. Шуңа күрә якыйн [ышаныч] һәм катгый хөкемнәр нык булмый. «Хәбәр мәшһүрләрне кире кагу – бидгать» диелгән сүзләр әгәр дә хөрмәтле һәм ышанычлы затлардан чыкса, шөбһә юк, бу сүз игътикадка [ышануга] карата түгел, бәлки, фәнгә карата [әйтелгән].

Гаделлек хакында булган низагларга нигезләнгән ки, матгун [шелтәләнгән] хәдис сөйләүдә гаепләүләрдән хәдис имамнары сәламәт калмаганнар. Иң бөек, хөрмәтле мөхәддисләрдән булган Бохари белән Мөслим мөрҗиә, нәвасыйб, шигый, кадәри, җәһми, әбадый һәм башка болар кебек бидгать мәзһәбләргә караган кешеләрдән хәдис сөйләү белән гаепләнәләр[37].

[37] Имам Нәвави бу кемсәләрне «Тәдриб әр-рави» исемле хезмәтендә (Б. 120–121) исемнәре, куньяләре (кушаматлары) һәм башка мәгълүматлары белән бәян иткән. Һәркем каршында мәгълүм булган Гыйкримә Мәүлә бине Габбас хәзрәтләре абадый [адашкан фиркаларның берсе] булганлыгы һәм Ваһеб бине Мөнәббиһ хәзрәтләре дә кадәри [адашкан фиркаларның берсе] булганлыгы күрсәтелә.

Мөхәддисләрнең хезмәтләре иснад тикшерү булып, бер хәдиснең сәнәде үзләре төзегән кагыйдәләргә муафыйк булса, хәдиснең сихәте белән, киресе булса, киресе белән хөкем кылалар. Фәкать моның белән хәдис гыйлеме алдында булган вазыйфалар тәмам булмый, бәлки, иң бөек хезмәт «мәтен»не тикшерүдән гыйбарәт. Мәтенне тикшерү үзенең белгеч галимнәренә махсус бер вазыйфа булып, алардан башкалар моңа керә белми. Кайвакыт мөхәддисләр игътибарында сахих дип табылган хәдисләр, Коръән-шәрифкә каршы булу, бәлки, акыл дәлилләренә каршы күренү сылтавы белән белгеч галимнәр тарафыннан калдырыла яки ялгыш аңлатыла. Мәсәлән, хәзрәти Гомәр һәм улы Габдулла риваять иткән булган «Чынлыкта, туганнарының кычкырып елаулары сәбәпле, мәет газаплана» дигән хәдисне[38] хәзрәти Гайшә: «Безгә Коръән җитә, «һәрбер кеше ни кылса да, үзе өчен генә кыладыр һәм гөнаһ йөген йөкләүче кеше башка һичбер кешенең гөнаһ йөген йөкләп алмас» [Коръән, 6:164]», – дип Коръән-шәрифкә туры килмәвен сәбәп итеп күрсәтеп, кире кагуы риваять итеlә.

## VIII

## Мөхәддисләр һәм ятлаулары, сахих хәдисләр

Мөхәддис дип хәдис гыйлеме белән мәшгуль һәм бу фәндә белгеч булган затларга әйтәләр. Мөхәддисләр һәм хафизләр [Коръәнне, хәдисләрне яттан белүчеләр] үзләре ятлаган хәдисләре, хәдисләрнең сәнәдләре белән шул дәрәҗәдә таныш булдылар ки, әгәр дә ике хәдиснең сәнәдләре алмаштырылса, моны аңлап, һәрбер хәдисне үзенең сәнәденә ялгыйлар иде. Моның бер мисалы имам Бохари тормыш юлында телгә алынса кирәк.

[38] Сахих Бохари. – Т. 2. – Б. 81; Сахих Мөслим. – Т. 1. – Б. 454.

Хәдис әһелләренә караган дәрәҗә һәм тормыш юллары [турында] китапларына күз салсак, аларның хәтере куәтле, ятлаган нәрсәләре күп булганлыгы хакында хәбәрләр бик гаҗәпләндерә. Бу хезмәтләрне укыган шәкертләр читләшмәсеннәр өчен темадан читкә китеп, бу җирдә бер ике җөмлә язып китсәк, зарар булмас – «Бәлки, алар туры юлдан китәрләр».

Бөек хикмәт ияләре хәбәренә күрә, ятлау хисе башка хисләрдән аерым буларак үзенә [күрә] мөстәкыйль бер хис булса да, хакыйкате бу көнгә кадәр һаман мәгълүм түгел. Кешеләрдә булган бу куәт гаять төрле булып, кайберәүләрдә бик зәгыйфь һәм кайберәүләрдә чамадан тыш көчле була.

Кече Азиянең көнбатыш тарафында идарә итеп, милади буенча, 123 ел әүвәл вафат булган Митридат исемле кемсәнең егерме ике төрле тел белән сөйләшкәнлеге, төрле кавемнәр белән идарә итеп, һәрбер кавем алдында үз телләрендә хөтбә сөйләве, никадәр хәрбие булса, һәрберсенең исемнәрен һәм фамилияләрен белгәнлеге риваять ителә.

Милади белән 1606да вафат булган Бәлҗика [Бельгия] галиме Либес тарихчы Тасиятьнең латинча тарих китабын ятлап, бер сүзендә ялгышмыйча укый иде, хәтта ки бер хәрефендә ялгышса, башын кисүне шарт итеп бәхәскә керергә торган.

Хәзрәти Ибне Габбас кораеш шагыйре булган Гомәр бине Рабиганың сиксән юлдан гыйбарәт булган бер поэмасын бер тапкыр ишетү белән ятлап, бер мәртәбә югарыдан түбәнгә [өстән аска] һәм икенче мәртәбә түбәннән югарыга [астан өскә] таба укып чыкканлыгы риваять ителә[39].

Бәдигъ әл-Һәмәзани җиңел генә бер уку белән ничә кагыйдәләрдән гыйбарәт булган китапларны һәм бер мәртәбә уку белән 50 юлдан торган поэмаларны ятлый иде. Мәгаринең зиһене ни кадәр булганлыгы «Әбү әл-Галәэ әл-Мәгари» китабында телгә алынды.

Хәммад әр-Равия бертоташтан, алфавит буенча, ике мең туксан поэма укыган, кешеләр чират белән тыңлаганнар. Бервакыт Әндәлүс мәмләкәтендә «Сибәвәйһ» китабын ятлау

---

[39] Әгани. – Т. 1. – Б. 33; Камил әл-Мөбәррад. – Т. 2. – Б. 145.

белән [генә] канәгать булганнарны ялкауга санаганнар һәм кайберләре хәтта «Әгани» китабын беләләр иде (һәр битендә 25 юл булган «Сибуя» китабының басма нөсхәсе 621 бит, «Әгани»нең һәр бите 31 юл булып, барлыгы 3760 бит).

Әндәлүс әдипләренең берсе үзенең зиһенен сынап карау теләгендә булганнар өчен кичтән «каф» рифмасыннан шигырь укый башлаган, таң аткан вакыттан әүвәл бу рифма тәмам булмаган. Аның кебек адәмнәр күп булганлыктан, шуннан артыкны язу мөмкин түгел.

Бүгенге көндә адәм баласында ятлау көче гаять зәгыйфьләнгән. Моңа исә ике төрле бөек үзгәрү казанышы сәбәп булган. Моның берсе китаплар төзелә башлау һәм икенчесе дә басмачылык һөнәре барлыкка килү. Кулланылмаганнан эшкә яраксызланган кораллар тутыгып, бозылган кебек, кешеләрдә булган куәтләр гамәлсез тору сәбәпле, зәгыйфьләнәләр. Кешеләр бер мәртәбә дә китапларга ышанып ятлау эшләренә әһәмият бирмиләр иде, соңра, бастыру сәнәгате барлыкка килгәч, иң әһәмиятсез нәрсәләргә кадәр язып бастырдылар һәм шуларга ышанып тордылар. Шул сәбәпле, ятлау куәтенә бөек бер зарар килде, хәтта борынгыларның хәбәрләрен укыган вакытта ышанмаслык дәрәҗәгә төштек.

Мөхәддисләр хәдисләрнең сәнәдләрен тикшереп, асылсыз яки иснадлы булганнарын җентекләп тикшереп, үзләренең китапларына язганнар. Шуның өчен бу көннәрдә хәдисләрнең иснадлары, мәҗрух [яраланган] яки мәтгун [шелтәләнгән] булуын тикшерергә кирәклек калмаган. Бәлки, телләрдә булган ышанычлы хезмәтләргә таяну җитәрлек була. Моның өчен «Көтебе ситтә»нең [«Алты китап»ның] берсендә булган хәдис гүя рәсүлүллаһ хәзрәтләренең үзеннән чыккан кебек», – диләр.

Хәдис риваять итәр өчен сүздә бертоташ сәнәд булу да шарт түгел. Нөсхәсенең дөреслегендә шөбһә булмау шарты белән «Көтебе ситтә», яки танылган «Мөснәд»ләрдә булган хәдисләрне сөйләү, тоташ бер сәнәде булсын яисә булмасын – дөрес. Тоташ чылбыр хасил итү фәкать тәбрикләнү кебек бер нәрсә[40].

---

[40] Шәрхү сахих Мөслим ли эн-Нәвави. – Т. 1. – Б. 24. Тәдриб әр-рави. – Б. 49.

«Көтебе ситтә»дә булган хәдисләрдән, мөхәддисләр тарафыннан искәрмә буларак, биш-ун хәдистән башкалары «сахих» һәм сахих хәдисләргә карата Бохари белән Мөслим сахих дип бер фикердә булганнарына «мөттәфыйк галәйһи» дип әйтү гадәте һәркемгә билгеле.

«Мөттәфыйк галәйһи» дип йөртелгән хәдисләр хакында мөттәсыйль [тоташ] һәм мәрфуг [пәйгамбәргә күтәрелгән] булу шарты белән Ибне Салах: «Бохари һәм Мөслим берәр хәдисне сахих [дөрес] дип танысалар, ул хәдиснең, һичшиксез, хак, дөрес икәнлегендә ислам өммәте килеште», – дигән[41]. Фәкать Ибне Салахның бу дәгъвасына бер төркем затлар, аерым алганда, Ибне әл-Һөмам белән хәнәфиләрнең соңгы галимнәре риза булмаганнар һәм: «Өммәтнең аларның хәдисләрен бердәм рәвештә кабул итүләре, башкалар белән чагыштырганда, сәнәдләре ышанычлы булганлыгыннан. Иснады мөхкәм [дөрес] булган һәрбер хәбәр вахид бу хөкемдә була, [берәр] гамәлне важиб итүгә «мөттәфыйк галәйһи» булган хәдисләрнең аерым бер өстенлеге юк», – диләр. [Ничек икәнен] бер Аллаһ кына белә!

# IX

## Тормыш һәм күренми торган нәрсәләргә караган хәдисләр

Әхлак, гамәлләр, гомумән, дин һәм шәригать әмерләре хакында булган хәдисләрдән башка, тагын хәдисләрнең күренми торган нәрсәләргә, дөньяви гыйлемгә караган өлешләре дә бар. Үзенең керү юлын юкка чыгармасын өчен һәм игътикадының [ышануының] тетрәүгә очравыннан имин булсын өчен, хәдис гыйлемен алырга керешкән шәкертләр хәдисләрнең бу өлешләрен дә белергә тиеш.

[41] Голүм әл-хәдис. – Б. 12.

Пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгалә хәзрәтләреннән пәйгамбәрлек миссиясен ирештерү, шулай ук күренми торган нәрсәләрдән хәбәр бирү хакында, белә торып булсын яисә онытып булсын, хаталы, гөнаһлы булудан пакь. Әмма шулардан башка [эшләрдә] гади кешеләр кебек ялгышлык һәм хата кылулары да мөмкин. Чөнки пәйгамбәрлек миссиясен ирештерүдән яки күренми торган нәрсәләр хакында бирелгән хәбәрләрдән башка нәрсәләрнең пәйгамбәрлеккә катнашы булмаганлыктан, аларда булган кимчелек пәйгамбәрлек миссиясенә карамый. Бер пәйгамбәр өчен сәнәгать гыйлеменнән хәбәрсез, язу сәнгате һөнәреннән мәгълүматсыз булу гаеп булмаган кебек, табигый хәл, гомумән, дөньяви гыйлемнәр белән таныш булмау да гаеп булмас. Шуңа карамастан, акыллары камил, аңлаулары яхшы булганлыктан, пәйгамбәрлек миссиясен ирештерүдән башка җирләрдә булган ялгышу һәм хаталары да бик сирәк була.

Имам Мөслим тарафыннан: «Пәйгамбәр саллаллаһү галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килде. Андагы кешеләр пальмаларны серкәләндерәләр һәм әйтәләр иде: «Пальманы аталандырабыз». Ул алардан сорады: «Сез нишлисез?» Алар җавап бирделәр: «Без шулай эшли идек». Ул әйтте: «Бәлки, сез болай эшләмәсәгез, хәерлерәк булыр». Тегеләр бу эштән туктадылар һәм уңышлары очып бетте яки начар булды. Аннан алар бу турыда пәйгамбәрнең исенә төшергәч, ул әйтте: «Чынлыкта, мин кеше генә, әгәр мин сезгә диннән булган берәр нәрсә хакында боерган булсам, аны алыгыз! Әгәр дә үземнең шәхси фикерем буенча берәр нәрсә боерсам, чынлыкта, мин кеше генә»[42], – дип риваять ителгән хәдис-шәриф шәрехендә [аңлатуында] Имам Нәвави: «Рәсүлүллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнең, үз күрүе белән дөнья тормышына карата әйтелгән сүзләреннән тыш, шәригать буенча әйткән нәрсәләренә буйсыну бабы», – дип сүз башы куйган һәм дөньяви гыйлем хакында рәсүлүллаһ хәзрәтләре үз фикере белән сөйләгән сүзләрендә кайбер ялгышлыклар булса, аны чит күрү юк», – дигән[43].

[42] Сахих Мөслим. – Т. 1. – Б. 223.
[43] Шәрх Нәвави. – Т. 11. – Б. 152.

Шуңа күрә фәнгә, соңгы тәҗрибәләргә каршы булган, дөньяви гыйлемгә караган хәдисләр булса яки медицина кагыйдәләренә каршы булган кайбер дәвалар бәян ителгән хезмәтләр күренсә, хәдисләрне нигез итеп алып, тәҗрибә белән мәгълүм булган, фән белән исбат ителгән нәрсәләрне ислам дине һәм хәдис исеменнән инкяр итү дөрес булмый. Шулай итү, ислам диненең нигезе булган бер нәрсәне гыйлемгә һәм хакыйкатькә каршы итеп күрсәтү, хакыйкатьтә, ислам диненә җинаять була. Хәдискә һәм рәсүлүллаһ хәзрәтләренә хезмәт итү бу түгел, бәлки, бу нәрсә дин дошманнары кулына хурлау кораллары әзерләп бирүдән башка [нәрсә] булмас. «Юлсыз дуслык күрсәтүченең зарары юлы белән дошманлык итүче зарарыннан күбрәк булыр», – диләр.

Әгәр дә хәдис иҗтимагый тормышка, мәдәнияткә караган кануннар, һәртөрле сәнәгатьләр, һөнәрләр, медицина, анатомия, астрономия, география, алгебра, химия кебек гыйлемнәр пәйгамбәрлек миссиясеннән бер өлеш булып та, аларны өйрәтү пәйгамбәрләр өстендә булса иде, кешеләрнең Аллаһы Тәгалә хәзрәтләреннән бирелгән акыллары, зиһеннәре, фикерләре эшсез буларак кулланылмый калуы һәм кешеләрнең һәрнәрсәдә пәйгамбәрләргә салышып, ялкауланып торулары тиеш булыр иде. Моның исә дөнья тәртибенә һәм тормыш кануныңа муафикъ булмаячагы мәгълүм. Шуңа карамастан, Коръән-шәрифтә акылларны эшләтү һәм гаҗәеп эшләргә гыйбрәт күзе салу хакында күп урында искәртелгән. Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең: «Сез дөнья эшләре турында миннән күбрәк беләсез», – дигән сүзләрен дә бу хакта дип санарга була.

Үз вазыйфалары булганлыктан, гамәл хөкемнәре хакындагы хәдисләрнең мәтеннәре мөҗтәһидләр тарафыннан тикшерелеп һәм өйрәнелеп, хәлгә карап, кабул ителгән [яки] кире кагылган. Мәсьәләләрне дәлилләре буенча язылган фикыһ китапларында һәм, аерым алганда, ысул фикыһы хакында булган хезмәтләрдә бу нәрсә күренә. Әмма гамәлләр хөкемнәре турында булганнарыннан тыш башка [күренми торган нәрсәләргә һәм дөньяви гыйлемгә караган] хәдисләр, күбесенчә, йозаклары алынмаган сандыклар, куллар җитмәгән хәзинәләр

кебек була. Мәзһәб мөҗтәһидләре үз вазыйфаларына карамаулары сәбәпле, бу төр хәдисләренә кагылуны кирәк дип санамаганнар. Чөнки гамәлләр хөкемнәре турында булганнарыннан тыш башка хәдисләрне өйрәнү фикыһ һәм мәзһәб мөҗтәһидләренә түгел, бәлки, кирәк булган вакытта шул заманның иҗтимагый, мәдәни галимнәре бурычына караган бер вазыйфа.

Игътикад [ышану] өлешендә якыйн [ышаныч] дәлилләр кирәклекне, ике шәех [Бохари һәм Мөслим] хәдисләренең башка сөннәт китапларыннан аермасы булмавын дәгъва иткән хәнәфи мәзһәбенә [дини юнәлешенә] иярүче кайбер галимнәрнең үзләренең гакыйдә [ышану] хакында язылган хезмәтләрендә хәзрәти Гайсәнең иңәчәге, Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ чыгып, кояшның көнбатыштан чыгуын һәм моның кебек башка хәбәрләрне кертүләренең сәбәбе безгә мәгълүм түгел. Ефрат елгасыннан алтын чыгачакны һәм моның кебек бик күп (Бохари һәм Мөслим хәдисләрендә телгә алына) хәдисләрнең хәбәрләрен язмауларының сәбәбе дә мәгълүм түгел. Я һәрберсен язу, яки һичберсен дә язмау тиешле иде.

Шуңа карамастан, кыямәт көне билгеләре хакында булган хәдисләрне ачыклар өчен бүгенге көндә артык кирәге юк, әмма киләчәктә кирәк булмаячагына ышаныч юк. Акылларны хәйран калдырган рәвештә булган фәнни ачышлар һәм уйлап табылган әйберләр аркасында яисә мәдәни һәм иҗтимагый үзгәрешләр булу сәбәпле, болар хакында, ихтимал ки, өйрәнергә мәҗбүр итәчәк көчләр мәйданга чыгар.

«Мәһди» исеме белән мөселманнар арасында шау-шу күбәюен күргәннән соң Ибне Хальдун бу турыда булган хәдисләрне тикшерергә мәҗбүр булган һәм хәҗәт саналырлык рәвештә хәдис табылмавын игълан иткән[44]. Гайсә иңүе һәм Дәҗҗал чыгуы хакында да бу рәвешле эшләргә мәҗбүр булмаячагыбызны һичкем әйтә алмый. Хәтта бу көнгә кадәр килеп киткән галимнәр өчен дә Дәҗҗал чыгуы хорафатка һәм Гайсә иңүе хаклыкка ишарә, диючеләр барлыгы мәгълүм.

Гамәлләр хөкемнәре хакында булган хәдисләр турында, моны сәләфләр [борынгылар] тикшерделәр һәм шундый карар бирделәр,

[44] Т. 1. – Б. 152–160.

дип аларның карарларын алу тиешле булса да, үз заманнарына һәм хәлләренә карап мәҗбүр булмаулары сәбәпле, бер хәдис хакында дәшмичә калган галимнәрнең гамәлләре үзләре шундый хәдис хакында өйрәнергә мәҗбүр булганнарга зарар итмәс.

Элекке заманда яһүд, христиан, зәрдөшт [зороастризм] һәм ислам халкы җирне келәм рәвешендә, дип фараз кылулары сәбәпле, «кояш, баеганнан соң, гареш астына барып сәҗдә кыла» мәгънәсендә булган хәдис-шәриф[45] хакындагы хакыйкатенә таянып, дәшмәүчеләр яки Катәдә, Мөкатил, Зәҗҗаҗ, Кәлби, Ибне Котәйбә кебек элекке заманнар уйлавы ноктасыннан сүз сөйләүчеләрнең галәм хәле турында булган уйлары фәнне алга җибәргән һәм гыйльми җәһәттән инкыйлаб булган заман әһелләренә зарары юк. Тормыш һәм дөньяви әмерләр хакында хөрмәтле рәсүл сүзенә ияргү важип булмаса, Кәлби белән Зәҗҗаҗ сүзенә ияргү нинди дәлил белән важип булыр? Батуы сәбәпле, кояш һичбер җиргә китмәве һәм югалып тормавы бүгенге көндә гыйльми җәһәттән генә түгел, бәлки, хис һәм күз белән күргү юлы белән ачык билгеле.

Шуның өчен, бу көндә хәдис укытучы затлар телгә алынган хәдисләрне дәрес вакытларында бүгенге фәнгә, төгәлрәк әйткәндә, күз белән күреп-тануга каршы булмаган рәвештә мәгънә биреп укытырга тиеш. «Белүчеләр белмәүчеләр белән бертигез булырмы?» [Коръән, 39:9].

# X

## Мәүдуг хәдисләр. Хәдис уйлап чыгаручылар. Мәүдуг хәдисләр хакында басылган хезмәтләр

Хәдис галимнәренең көч сарыф итеп хәдисләрне җыюларының, сәнәдләр тикшереп һәрберсен үлчәү аша үткәрүләренең бөек сәбәпләренең берсе – арада мәүдуг (асылсыз) хәдисләрнең йөрүләре һәм дөрес хәдисләр белән аралашып беркадәр кешеләрнең адашулары булды.

[45] Сахих Бохари. – Т. 4. – Б. 75; Сахих Мөслим – Т. 1. – Б. 55.

Мәүдуг хәдисләрнең төрләре күп булып, аларны таратучыларның максатлары төрле-төрле иде. Кайберләре ислам диненә шөбһә салу нияте белән, кайберләре үз мәзһәбләрен тарату өчен һәм кайберләре үзләренә күрә бертөрле яхшы ният белән хәдис уйлап чыгарганнар. Хәдис уйлап чыгарып, халык арасында тараткан динсезләр әүвәлге төркемнән, бидгать әһелләре белән суфи һәм заһидләр соңгы төркемнән. Динсезләр җөмләсеннән саналган габбасилардан [булган] Мәһди заманында үтерелгән Габделкәрим бине Әбү әл-Гауҗаның берүзе тарафыннан 4000 хәдис уйлап чыгарганлыгы риваять ителә[46].

Сурәләр фазыйләтләре хакында (кайбер сүрәләр хакында булган хәдисләр – искәрмә) тәфсир китапларында булган хәдисләр, гүя, Коръән-шәриф укырга кызыктыру өчен Нух бине Әбү Мәрьям, Мәйсәрә бине Габдераббиһ кебек заһидләр тарафыннан уйлап чыгарылганнар.

Ибне Әбү Яхъя, Вакыйди, Мөкатил һәм Мөхәммәд бине Сәгыйд әл-Мәслуб исемле мәшһүр галимнәр хәдис уйлап чыгару белән билгеле булганлыктан, мөхәддисләр аларга «әл-кәззабун» [ялганчылар] диләр. Фәкать нинди максат белән уйлап чыгарылса да, чыгарылсын, мәүдуг хәдисләр үз әһелләре тарафыннан булган тәнкыйть белән башкалардан аерылганнар.

Соңгы заман авторларыннан берсе мәүдуг хәдисләргә карата шундый мәгълүмат бирә: «Кәлби тәфсире[47] белән Мөкатил бине Сөләйман китабы, Вакыйди «Мәгази»се – асылсыз. Әбү Ләйс Сәмәркандиның «Тәнбиһ әл-гафилин» исемле китабында, Газалинең «Ихья»сында, Хәким Тирмизи хезмәтләрендә, гомумән, тәсаувыф [суфичылык] китапларында булган хәдисләргә (әгәр башка юл белән нык булмасалар) ышанып булмый. «Я, Гали!» һәм «Я, Фатыйма!» дип килгән васыятьләр, акыл хакында, Рәҗәб һәм Гашура көннәре фазыйләтләре, шул Гашура көнендә бер төркем пәйгамбәрләргә хөрмәт күрсәтү турында

---

[46] Бу кемсә Мәгыйн бине Заидәнең анасының бертуганы булып, Басра әмире Мөхәммәд бине Сөләйман бине әл-Габбаси тарафыннан 160 елда үтерелде. «Тәүхид Мөфаддал Ибне Гомәр» исемле китап кереш сүзендә телгә алынган булган Ибне Әбү әл-Гауҗа – шул зат.

[47] Ибне Хәзем хәзрәтләренең «Әл-фасыл» исемле хезмәтенә мөрәҗәгать ителә. – Т. 2. – Б. 93, 94, 96.

булган хәдисләр – мәүдуг. Котыб, Гавәс, Нөкабәэ, Әүтәд, Мәһди хакында булган хәбәрләр ышанычсыз. Багдад, Басра, Куфә, Казвин, Мәру, Насыйбин, Шам, Әнтәкыя, Гаскалан, Искәндәрия, Бохара һәм Мисыр фазыйләтләре турында булган хәдисләр – ялган. Кавын һәм кына [хна], ахак (гакыйк), йөзек кию, итне пычак белән кисүдән тыю хакында булган хәдисләр дөрес түгел. Хәзрәти Билалның Шамга барып, хәзрәти рәсүлнең вафатыннан соң Мәдинәгә кайтуы һәм бу вакытта азан әйтүеннән бөтен Мәдинә халкының агылуы хәбәре, Җабирның бер баласы икенчесен үтереп, соңра, рәсүлүллаһ догасы белән терелүе кыйссасы, хәзрәти Гомәрнең үз улы Әбү Шәхмәгә җәза биреп сугуы, Ибраһим пәйгамбәр хатыны Сараны мәҗбүр итеп, Фиргавен аулак бүлмәгә алып керүе һәм Ибраһим пәйгамбәр суяр өчен дип улы Исмәгыйль муенына пычак куюы, Әюп пәйгамбәрне Иблис котырткач, авыруы һәм, шул сәбәпле, тәне кортлавы, Давыт пәйгамбәрнең Урия хатынына гашыйк булуы, хөрмәтле рәсүл аягына иярүе сәбәпле, Бәйтел-мәкъдис сахрасының һавада калуы, ярылган ай кисәкләренең рәсүлүллаһның изүеннән кереп, җиңеннән чыгуы, рәсүлүллаһ белән дөяләр, ишәк һәм бүреләр сөйләшүе хакында булган хәбәрләр дөрес түгел. Муса пәйгамбәрнең Йосыф пәйгамбәр табутын Мисырдан алып чыгуы, Гад кавеменең җәннәте, Каф тавының башы зөбәрҗәт булып, бөтен дөньяны яктыртуы, хөрмәтле рәсүл әфәндебездән башка пәйгамбәрләрнең каберләре мәгълүм булмавы турында булган хәдисләр – ышанычсыз.

Бу автор китабыннан сайлап алынган нәрсәләр шулар. Фәкать мәүдуг хәдисләр болар белән чикләнмәгән, бәлки, гаять күп булып, аларны белдертү өчен хәдис гыйлеме белгечләре тарафыннан хәтта кайбер кагыйдәләр дә уйлап табылган. Монда гына бөтенесен бирү мөмкин булмаганлыктан, [бер җөмлә белән әйткәндә] хәдисләрнең, Коръән-шәриф, яки диндә булган катгый мәсьәләләр, яисә хискә һәм акылга таянган ышануга каршы булганнары [мәүдуг була].

Мәүдуг икәннәре мәгълүм булган хәдисләрне белә торып сөйләү һәм риваять итү – хәрам, дигәннәр[48]. Шуңа күрә элекке

[48] Голум әл-хәдис лиибн әс-Салах. – Б. 38.

заманнарда Казан шәһәрендә бик күп нөсхәләр белән күп мәртәбә басылган «Кырык хәдис», «Әл-лөбаб» исемле китапларның зур өлешләре мәүдуг хәдисләрдән гыйбарәт булуы өчен дәреслек итеп балаларга укытырга яраклы булмаса кирәк.

Мәүдуг хәдисләр хакында безгә мәгълүм булган басылган хезмәтләр шулар: 1) «Әснә әл-мөталлиби фи әхадис мөхтәлифәт әл-мәратиб», Мөхәммәд әл-Хут хезмәте (1276). 2) «Әл-игътибару фи бәяниән-насих вә әл- мәнсухый мин әл-әхбар». 3) «Таэвилү мөхтәлиф әл-хәдис», Ибне Көтәйбә әд-Динәвәри хезмәте (276). 4) «Тәхзир әл-мөслимин мин әл-әхадис әл-мәүдугат», Зафир Мөхәммәд Бәшир әл-Әзһари хезмәте. 5) «Тәзкират әл-мәүдугат», Әбү әл-Фадыл әл-Мәкъдиси хезмәте. 6) «Әт-тәгъкыйбат галә әл-мәүдугат», Сөютый хезмәте (911). 7) «Әл-фәваид әл-мәҗмугатү фи әл-әхадис әл-мәүдугат», Мөхәммәд бине Гали Шәүкяни хезмәте (1250). 8) «Әл-ләали әл-мәүдугатү фи әл-әхадис әл-мәүдугат», Сөютый хезмәте. 9) «Әл-мәүдугат әл-күбра», Гали әл-Кари хезмәте.

Бу китапларның беренчесе Бейрутта, икенчесе Хәйдәрабад әд-дәкәндә, тугызынчысы Истамбулда, калганнары Мисырда басылган.

## XI

## Хәдис китаплары язылуы. Нигезләре һәм мөснәдләр. Хәдис теле

Сирәк кенә кайбер сәхабәләр, үзләре өчен кайбер хәдисләрне язулары мәгълүм булса да[49], гомумән, хәдисләр күңелләрдә саклана һәм телдән риваять ителә иде. Соңра, [башка илләрне] яулап алулар күбәйде, ислам мәмләкәте зурайды, сәхабәләр, табигыйннар вилаятьләргә таралып, кайберләре Хиҗазда калды һәм кайберләре Шам, Мисыр, Куфа, Гыйрак

[49] Сахих әл-Бохари. – Т. 1. – Б. 36. Мәлик әйтә «Алар язмыйлар, ә, бәлки, ятлыйлар иде. Аларның язучылары да ятлау өчен генә язды, ятлагач, бетерделәр». Фәтех әл-мөгыйс. – Б. 238.

өлкәләренә күченделәр. Хәдис риваять итүче сәхабәләр үлү белән көннән-көн азаялар, хәдисләр сөйләүдә булган арадашчылар күбәеп, иснадлар озыная. рәсүлүллаһ заманы сәгатьтән сәгатькә ераклаша иде. Бу вакытта хәдис гыйлеме язылырга, кагыйдәләр язу белән югалудан саклап калырга кирәклеге чыккан һәм мөхәддисләр тарафыннан бу вазыйфа үтәлә башлаган.

Хәдис-шәрифләрне язарга ислам галимнәренә әмер иткән хәлифәләрнең беренчесе өмәвиләрдән Гомәр бине Габделгазиз иде[50].

Иң беренче кайсы галим хәдис китабын язуы ачык мәгълүм булмаса да, Мәккәдә Ибне Җүрәйҗ[51], Мәдинәдә Мәлик белән Ибне Исхак, Басрада Рабигъ бине Сабих белән Сәгыйд бине Әбү Гарубә, Хәммад бин Сәләмә, Куфада Суфьян Сәүри, Шамда Әүзагый,Васитта Һашим, Ямәндә Мәгъмәр бине Рашид, Тәһранда Җәрир бине Габделхәмид, Хорасанда Габдулла бине әл-Мөбарәк язган. Боларның һәрберсе бер заман адәмнәре иде. Мәдинә галимнәреннән Ибне Әбү Зиэб исемле кемсәнең «Әл-мөватта» исемле олуг бер хәдис китабы бар иде. Хәтта ки Имам Мәлик «Әл-мөватта» хезмәтен язарга керешкән вакытта: «Әбү Зиэб «Мөватта»сы булганда тагын бер башка «Мөватта» язуда нинди мәгънә бар?» – дип гәҗәпләнүе риваять ителә[52].

Югарыда телгә алынган затлардан соң хәдис язучылар күбәйде һәм икенче йөз башында Габдулла бине Муса әл-Куфи, Мөсәддәд әл-Басри, Әсәд бине Муса, Нөгайм бине Хәммад һәм башкалар «Мөснәд»ләр төзеделәр. Болардан соң Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя, Госман бине Әбү Шәйбә һәм башкалар тарафыннан «Мөснәд»ләр язылган, болардан соң да мәшһүр «Усул», «Җамигъ», «Сөнән» китаплары мәйданга чыккан.

---

[50] Сахих әл-Бохари. – Т. 1. – Б. 33; Мөватта әл-имам Мөхәммәд. – Б. 389.

[51] Габделмәлик бине Габделгазиз бине Җүрәйҗ Әбү Халид әл-Мәкки. Үз гомерендә 70 хатынга вакытлыча өйләнүенә карамастан (моны ярый торган эш дип саный иде), ул галимнәр каршында ышанычлы санала. – Т. 2. – Б. 151.

[52] Тәдриб әр-рави. – Б. 24.

Хәдис китаплары күбрәк ике ысулда язылганнар. Беренчесе: китап бабларга [бүлек] һәм фасылларга ]бүлекчәләргә] аерылып, һәр фасылда [бүлекчәдә] үзенә караган хәдисләр җыела. Икенчесе: бабларга һәм фасылларга аерылып, һәрбер хәдис үзенең равие булган сәхабәләр исеме астында китерелә. Болардан әүвәлгесе «Асыл», «Өмме», «Сахих», «Сөнән» кебек исемнәр белән телгә алына, соңгысы «Мөснәд» исеме белән кулланыла. Иътибар ителгәнчә, «Мөснәд»ләргә караганда «Асыл»лар борынгырак.

«Мөснәд»ияләренең кайберләре сәхабәләрнең исемнәрен алфавит буенча, кайберләре кабиләләр тәртибе белән, кайберләре ислам кабул итүләре буенча яки Бәдер, Хөдәйбия кебек мәшһүр вакыйгаларда катнашулары тәртибе белән телгә алалар.

«Асыл» һәм «Өмме»ләр киләчәктә телгә алыныр, шуның өчен бу җирдә мәшһүр «Мөснәд»ләр хакында өлешчә бер мәгълүмат бирү кирәк булыр. Хәдис фәнендә танылган булган «Мөснәд»ләр болар:

1) «Мөснәд Ибне Раһуя» – Исхак бине Раһуяныкы (238).

2) «Мөснәд Әби Дауд әт-Таялиси» – (204). Бу китап Әбү Дауд әт-Таялиси тарафыннан түгел, бәлки, үзеннән соң башка бер адәм тарафыннан төзелгән.

3) «Мөснәд әл-Имам» – Әбү Габдрахман Бакый бине Мәхләд әл-Куртубиныкы (276). Бу хезмәттә 1300 сәхабә хәдисе бар.

4) «Мөснәд Әхмәд бине Хәнбәл» – бу хезмәтне Әхмәд бине Хәнбәл үзе 50700 хәдис арасыннан сайлап алып төзегән. 300дән артык хәдис өч кенә арадашчы белән сөйләнелеп, бөтен хәдисе 30000 булып, 700 сәхабә исеме телгә алынган. Бу «Мөснәд»не мөхәддисләр хәдис фәнендә зур бер нигез итеп тоталар. Хәтта кайбер затлар: «Әхмәд бине Хәнбәл «Мөснәд»ендә булмаган хәдисләр кирәк түгел», – дигәннәр. Фәкать моңа Бохариның хәзрәти Гайшәдән риваять ителгән «Өмме зәргъ» хәдисе белән генә бәхәсләшәләр. Чөнки бу хәдис Әхмәд бине Хәнбәл «Мөснәд»ендә юк. Кайбер кемсәләр дә [анда] зәгыйфь, бәлки, мәүдуг хәдисләр барлыгын әйткәннәр. Аның Багдад шәһәреннән «Әл-мөстәнсария» мәдрәсәсенә вакыф (бүләк) ителгән нөсхәсе 24 том булуы риваять ителә. (Басмасы 6 том).

5) «Мөснәд Әби Хәнифә» – бу «Мөснәд» Әбү Хәнифә хәзрәтләре вафатыннан соң төрле адәмнәр тарафыннан төзелгән.

6) «Мөснәд әш-Шафигый – бу «Мөснәд» тә соңыннан башка бер кемсә тарафыннан язылган.

Коръән-шәриф теле хакында мөстәкыйль китаплар язылган кебек хәдис теле турында да мөстәкыйль китапчыклар һәм олуг китаплар язылган. Хәдис теле хакында иң беренче хезмәт язган зат – Әбү Гобәйдә Мөгаммәр бине әл-Мөсәннә әл-Басри ([һиҗри] 210 да вафат) булып, тик аның хезмәте бик кыска китаптан гыйбарәт булган. Аннан соң Надыр бине Шөмәйл әл-Мәзәни ән-Нәхәви (204 тә вафат) бер хезмәт язды, аннан соң Габделмәлик бине Кариб әл-Әсмәгый, Мөхәммәд бине әл-Мөстәнир Котрыб һәм башкалар тарафыннан китаплар язылды. «Гариб әл-хәдис» [хәдис аңлатмасы] хакында булган хезмәтләрнең иң тулысы һәм иң гүзәле бу затлардан соң килгән Әбү Гобәйд әл-Касыйм бине Сәллям китабы. Әлеге зат бу китапны кырык ел гомерен сарыф итеп төзегәнлеге риваять ителә. Аннан соң бу фәндә бик күп китап язылган. Бүгенге халык өчен иң файдалы һәм кирәкле сүзләрне табарга җиңел булган «гариб әл-хәдис» [хәдис аңлатмасы] китабы Әбү әс-Сәгадат Мөбарәк бине Әбү әл-Кәрам Мөхәммәд бине әл-Әсир хәзрәтләренең «Ән-ниһаятү фи гариб әл-хәдис» исемле хезмәте булса кирәк (Ибне әл-Әсир 606да вафат). Бу хезмәт дүрт томда Мисырда басылды, бөтенесе 1270 бит.

# XII

# Хәдис китаплары белән гамәл кылу

Бөек дәрәҗәле Коръәннән соң шәригатебезнең асылы сөннәт булса, сөннәттә иң ышанычлы хезмәтләр бу «Көтебе ситтә» [«Алты китап»] булса, аларда булган хәдис-шәрифләрне һәркем: «Рәсүлүллаһ саллалаһү галәйһи вә сәлләм [шулай] әйткән», – дип сөйли белер. Ачык максаты булу һәм аңларга көче җитү шарты белән бу хезмәтләрдә булган хәдисләр белән

гамәл дә кылыр. Имам Шафигый хәзрәтләре: «Башка бер адәм сүзенә туры килмәүгә сылтап, сөннәт белән мәгълүм булган нәрсәне калдырырга юл юк, бу хакта мөсеманнарның иҗмаглары [бердәм карашы] бар», – дигән[53]. Хәдис-шәрифләр һәркем, һәр заман, һәр җир өчен кирәк булып, кайбер заманнар һәм кайбер кавем, шәхесләр белән чикләнмәгән. Кинәт бер хәдис мәгънәсе Коръән-шәриф яки икенче бер хәдис яки нинди булса да, башка бер куәтле дәлилгә каршы булса, бу вакытта гаделлек, өстенлек, җыю һәм аңлату кагыйдәләре кулланыла. Ләкин мондый рәвештә каршылыклы күренгән хәдисләр уйлаган кадәр күп түгел. Нәтиҗә: хәдисләр белән гәмәл кылудан шәригать исеме белән тыярга һичкемнең хакы юк.

Хәдисләрнең гамәлдән чыккан, эчтәлексез, чикле һәм махсус булу ихтималлары чыгарга, шулай ук кызыктыру өчен булган әмерләрне мәҗбүри дип аңларга яки моның киресен аңларга мөмкин. Ләкин бу нәрсәләрнең, ихтималы гына булганлыктан, зарары юк һәм гамәл кылудан тыймыйлар. Сәләф галимнәре ышанычлы юл белән сөйләнелгән хәдисләр белән гамәл кылыр өчен эшкә керештеләр, аның белән фәлән һәм фәләннәрнең гамәл кылу-кылмауларын аңлауларына кадәр туктап тормаганнар.

Хәдис белән гамәл кылуда, никадәр бөек шөһрәтле затлар булсалар – булсыннар, бер өммәттән булган затларның сүзләре исәпкә алынмас; киресе була икән, ул вакытта хәдисләргә, сөннәтләргә хаҗәт калмас, бәлки, хәдис һәм сөннәт белән шөгыльләнәчәк җирдә сүзләре исәпкә алыначак затларның сүзләрен, уйләрын, фикерләрен тикшерү һәм шуларга яраклы гамәл кылу тиеш булыр иде. Хәлбуки, шәригать галимнәре тарафыннан бу мәгънәдә сөйләүләре риваять ителми.

Хәдисләрдә булган ихтималлар бермә-бер артыгы белән мөҗтәһидләр һәм фәкыйһләр сүзләрендә дә бар. Моннан башка, мөҗтәһидләрдән риваять ителгән сүзләрнең иснадлары «Көтебе ситтә» иснадлары дәрәҗәсендә ышанычлы түгеллеге инкяр ителмәс. Шуңа күрә дә кулында «Мөватта», «Сахих Бохари» һәм «Сахих Мөслим» яки башка бер «Сөнән» китабы булган

[53] Игълям әл-мөвәккыйгыйн. – Т. 1. – Б. 7.

кемсә шул китапта булган хәдисләр белән гәмәл кыла белер. Хәтта бу китаплардан дәрес алучылар да бу ният белән дәрес алырга тиеш. Чөнки гыйлемнең максаты – гамәл.

Коръән һәм хәдисләр белән гамәл кылу өчен мөҗтәһид булу шарт түгел, бәлки, гарәп телен, насих [гамәлдән чыгаручы хәдисләр] һәм мәнсухны ]гамәлдән чыгарылган хәдисләрне] беркадәр белү җитә. Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләре ислам динен һәм аның хөкемнәрен аңлата белүдә мөҗтәһидләрдән артык булуында шөбһә юк. Шуның өчен: «Мин рәсүлүллаһ сүзләрен мөҗтәһид авызыннан ишетмәгәнгә аңлый алмыйм», – дип әйтүче кемсә хөрмәтле рәсүл хакында начар уйлаучы булыр.

Гамәл кылу өчен никадәр хәдис булса, һәрберсен урап алып бетерү мәҗбүри түгел. Хәдисләрне тулысы белән урап алып бетерү мәшһүр мәзһәбләрнең башлыкларына да җиңел булмаганлыгы риваять ителә. Шуның өчен үз каршыңда ачык булганнан соң, ихтимал, моңа каршы икенче бер хәдис яки Коръән [аяте] бардыр, фәлән-төгәндер, дип тукталып тору тиешле булмый. Төрле заманнарга һәм төрле вакытларга йөкләргә мөмкин булган хәдисләрнең һәрберсе белән гамәл кылу дөрес була.

Ислам динендә беренче дәрәҗәдә ышанычлы дәлил бөек дәрәҗәле Коръән булып, аннан соң өммәт тарафыннан бердәмлек белән кабул ителгән «сөннәт гамәлия» [пәйгамбәр гамәлләре] һәм аннан соң риваять яки дәлилләрендә каршылыклар булган «сөннәт каулия» [пәйгамбәр сүзләре]. Бу нәрсәләрнең аңлатмасы исә моннан башка җирләрдә.

Хәдисләрне аңларга ярдәм бирәчәк нәрсәләр: гарәп телен гүзәл белү, аның куллану үзенчәлекләре белән таныш булу, гарәп шигырьләрен һәм гарәп мәсәлләрен ятлау булыр. Хәзрәти Гомәр радыяллаһү ганһү (Аллаһ аннан риза булсын) Афакта булган хезмәткәрләренә ирештергән фәрманнарында фарызлар һәм сөннәтләр хакында булган нәсыйхәтләре белән бергә гарәпчәне өйрәнү хакында нәсыйхәтләре була иде[54].

Хәдис гыйлеме һәм сөннәт белән гамәл кылган затлар өчен хөрмәтле сәхабәләр, табигыйннар арасында дин гыйлемен

[54] Мохтасар җамигый бәян әл-гыйлем. – Б. 207.

тарату белән шөгыльләнгән затларның тормыш юлларын белү, аларның заманнары, мохитлары белән дә таныш булырга кирәк. Бу турыда гүзәл һәм ышанычлы бер төркем хезмәтләр басылып нәшер ителгән. «Изгеләрне искә төшергәндә рәхмәт иңә».

# XIII

## Әсмаи риҗәл [хәдис тапшыручылар исемнәре] һәм бу турыда булган басылган хезмәтләр

Хөрмәтле сәхабәләр, бөек мөхәддисләр хәзрәтләренең исемнәрен, күньяләрен [баласы исеменнән ясалган кушаматларын], кушаматларын, кабиләләрен, заманнарын, шөһрәтләрен, туу һәм вафат булу тарихларын белү хәдис гыйлеме белән шөгыльләнүчеләр өчен һәрнәрсәдән элек зарур. Хәтта: ««Әсмаи риҗәл» [хәдис тапшыручылар исемнәре] хакында җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүмат җыймаган адәмнең үзен хәдис гыйлеме белән бәйләргә хакы юк», – дигәннәр.

«Әсмаи риҗәл» хакында мәгълүматы булмаган адәм хәтта күньяләрен һәм кушаматларын күрмәве белән дә бер җыем ялгышлыкларга юлыгыр, инде башка рәвешле ялгышлыкларга ни кала? Мәсәлән, иң бөек мөхәддисләрдән булган Мөгавия бине Габделкәрим «адашкан» дип, Габдулла бине Мөхәммәд «зәгыйфь» дип һәм Мөхәммәд бине Әбү әл-Фадыл Әбү ән-Ногман бозык мәгнәсендә булган «түләүче» дип танылганнар. Шулай ук иң туры сүзле булган Юныс бине Мөхәммәд «ялганчы» дип, сүзе ышанычсыз булган Юныс Әбү әл-Хәсән бине Язид «көчле» дип билгеле булган.

Хөрмәтле сәхабәләр һиҗрәттән соң йөз елдан вафат булып бетүләре кәрәмәт теләүче затлар белән кайбер суфиларга карышып, мөхтәрәм мөхәддисләр кире какканнар һәм ялганга чыгарганнар, хәтта ки Хафиз Зәһәби: «Аллаһка һәм аның рәсүленә җөрьәт итүче, һичшиксез, ялганчы карт», – дигән[55]. Бу

[55] Мизан әл-игътидаль. – Т. 1. – Б. 327.

кемсәнең уйлап чыгарылган бер адәм булганлыгын сөйләүчеләр бар, кайберәүләр исә аны 632дә вафат булды, диләр[56].

Сәхабәләр хакында мәшһүр һәм бүгенге көндә басылган хезмәтләрдән безгә мәгълүмнәре болар:

1) «Әл-истигабү фи мәгърифәт әл-әсхаб». Ибне Габделбәр (463) хезмәте булып, ике зур томда, 1318дә Хәйдәрабад әддәкәндә басылган. Монда 3000 сәхабә исеме телгә алынган.

2) «Өсд әл-габәти фи мәгърифәт әс-сәхабә». Ибне әл-Әсир (630) хезмәте булып, 5 томда. 1280дә басылган. Анда телгә алынган сәхабәләрнең саны 7500 микъдарында.

3) «Әл-исабәтү фи тәмйизи әсмаи әс-сәхабә». Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852) хезмәте булып, Калкуттада һәм соңыннан да Мисырда 8 томда басылды. Анда булган сәхабәләрнең исемнәре 50000 микъдарында.

4) «Әл-күнә вә әл-әсмаэ». Әбү Бишер Мөхәммәд әд-Дулаби (310) хезмәте булып, 2 томда Хәйдәрабадта 1323тә басылган.

«Әсмаи рижәл» белән таныш адәмнәр хәбәр итүенчә, хөрмәтле сәхабәләр һәм табигыйннар арасында Гәбдерәхим исемле зат юк, шулай ук Габдулла бине Әсма бинте Әбү Бәкер әс-Сиддыйк бине Әбү Кухафә белән Мөхәммәд бине Габдрахман бине Әбү Бәкер әс-Сиддыйк бине Әбү Кухафәдән башка дүрт буынлы сәхабәләр булмас.

Равиләр хакында язылып, бүгенге көндә басылган хезмәтләр болар:

1) «Тәзкират әл-хүффаз». Хафиз Зәһәби (748) хезмәте булып, 8 томда «Хәйдәрабад әддүкәндә басылды.

2) «Хөлясатү тәзһиб әл-кәмал». Сафиеддин әл-Хазражи хезмәте булып, 1322дә Мисырда басылды.

3 ) «Табакат әл-хүффаз». Хафиз Зәһәбинеке (748) булып, милади 1834 елда 3 томда Гутенганда шәрекъчеләр тарафыннан басылды.

4) «Әл-мөштәбә». Хафиз Зәһәби хезмәте (748) булып, шәрекъчеләр тарафыннан 1881дә Лейден шәһәрендә басылды.

[56] Рәтән хакында Ибне Хәҗәр тәфсилләп сөйләгән. Әл-исабә. – Т. 2.

5) «Мизан әл-игътидали фи нәкыд әр-рижәл». Хафиз Зәһәби (748) хезмәте булып, 2 томда 1301дә Ләкнәүдә һәм 3 томда 1325тә Мисырда басылды.

# XIV

## Хәдис гыйлеме һәм Русия мөселманнары

Русия мөселманнарының хәдис гыйлеменә булган мөнәсәбәтләрен белер өчен, гомуми рәвештә булган гыйлем тарихларын күзәтеп чыгу тиешле. Гыйлем тарихлары беленсә, хәдис гыйлеме хакында булган хәлләр үзеннән үзе мәгълүм булыр.

Русия мөселманнарының гыйльми тарихлары безнең тикшерүебезчә, аптырау дәвере, Дагыстан дәвере, схоластика дәвере, уяну дәвере исемле дүрт дәвергә аерыла.

Беренче дәвер «аптырау дәвере» дип исем бирүебез, бу дәвер Казан мәмләкәте Русия кулына кергән көннән башлана. Бу дәвердә мөселманнар дин ирегенә хуҗа түгел иде. Ислам дине, рәсми дин буларак, хөкүмәт тарафыннан танылмаган иде. Моннан башка Волга [Идел] белән Урал арасында Агыйдел белән Чулман буйларында башкорт гаугалары дәвам итеп тора иде. Шул сәбәпле, мөселманнарның хәлләре өметсезлектә һәм аптырауда үткән, гыйлем һәм мәгърифәт юлында бер адәмгә дә йөрергә мөмкин булмаган.

Икенче дәвер – «Дагыстан дәвере» дип исем бирүебез, бу дәвердә мөселманнар үз акылларын башларына җыеп, шулай хиссез һәм хәрәкәтсез торудан гүзәл нәтиҗә чыкмаячагын аңлап, укырга дигән фикергә килгәннәр һәм ничә мәшәкатьләргә дучар булсалар да, Дагыстан тарафларына шәкертләр җибәреп, гыйлем алдырдылар; Дагыстан вилаятеннән кайткан шәкертләр үзләренә күрә мәктәпләр төзеп яки үз йортларына җыеп, милләт балаларын укыта башлаганнар. Бу дәвердә таралган гыйлем, гарәп нәхүе [синтаксисы], сарыфы [морфологиясе] һәм дә фикыһ фәннәреннән гыйбарәт булган. Дагыстаннан килгән шә-

кертләрнең рәсми язулары дөрес, гүзәл булып, мәмләкәтебездә булган иске язма хезмәтләр [шул] буыннар һәм буыннарның шәкертләре тарафыннан язылган булулары мәгълүм. Боларның укыткан нәрсәләре җитди, файдалы булып кешеләрнең әхлак һәм гадәтенә яхшы тәэсир иткән. Бу дәвердә никадәр Коръән һәм хәдис гыйлемнәре укылмаган булса да, кешеләр арасында гүзәл холык, ислам буенча, туганлык, әдәп, инсафлылык таралу җәһәтеннән «алтын дәвер» дип саналган.

Өченче дәвер – «схоластик дәвер» дип исем бирүебез, бу дәвердә башкорт гаугалары басылып, Оренбург шәһәре төзелүеннән алып һиҗри ундүртенче йөз башына кадәр булган аралыктан гыйбарәт. Сахра халыклары Русия гражданлыгын кабул итүләре сәбәпле, Төркестан белән Русия арасында сәүдә юллары ачылып, кәрваннар йөри башлаган, моннан файдаланып, гыйлем алу максаты белән Русия мөселманнары Бохара тарафларына сәфәр кылдылар. Бу вакытта Русия дәүләте дин иреге игълан иткән һәм ислам динен рәсми рәвештә тануыннан, Бохарадан кайткан галимнәр хәтта олы мәдрәсәләр төзеп, тулы ихтиярлары белән укыта башлаганнар. Бохарада рәсми дәресләр юнан [борынгы грек] методлары, китап кереш сүзләре, шәрехләрнең һәм хашияләрнең [аңлатмаларның] бәхәс һәм сүз көрәштерүләр булуыннан, боларны үрнәк итеп тоткан безнең мәдрәсәләребездә Коръән һәм хәдис гыйлемнәре белән җитди рәвештә шөгыльләнә алмаганнар. Гәрчә, Курсави, шәех Гали Түнтәри, Мәрҗани кебек бөекләр кайбер хәдис китапларыннан дәрес бирсәләр дә, бу дәресләр, башкалар фикерендә игътибарсыз калудан куркып, схоластикадан башка дәресләр белән кызыксынмаган шәкертләргә булганлыктан, әһәмиятле саналмас.

Дүртенче дәвер – «уяну дәвере» дип исем бирүебез, бу дәвер һиҗри ундүртенче йөз башыннан соң башлана. «Аң-белем булдырылса, бөтен гыйлемнәр һәм фәннәр ачкычы алдыбызда булыр, дингә нинди юлдан, нинди тарафтан тыкшыну булса да, моның белән каршы тору җиңел булыр» дигән дөрес булмаган фикер белән схоластика яклы булган затлар франк галимнәре тарафыннан исламга каршы китерелгән тыкшынуга җавап бирү түгел, хәтта ки мәсьәлә белән дә ачык рәвештә таныш бул-

маганлыктан, җиңелгәннәрен күреп, хаталарын аңладылар һәм хакыйкый гыйлем юлына керергә кирәклекне таныдылар. Тыкшынуга һәм һөҗүмнәргә җавап бирүдән элек хакыйкый ислам белән таныш булырга кирәк икәнен күрделәр. Моның нәтиҗәсе буларак, Коръән-шәриф һәм хәдис гыйлемнәрен алыр өчен юл ачылды. «Дөяләрне тавыклар базарында сатмыйлар» дигән критерий буенча, бу фәннәрнең урыннары инде Бохара түгел, бәлки, Хиҗаз һәм Мисыр иде. Шуның өчен шәкертләр бу вилаятьләргә сәфәр кылыр булдылар. Бу шәкертләрдән кайберләре, фәннәр һәм яңа белемнәр алгач, бу мәмләкәткә кайтканнан соң, гомуми бер уянуга сәбәп булдылар.

Ислам мәмләкәтләреннән Коръән һәм хәдис гыйлемнәре алып кайтучылар нисбәтендә, схоластика әүвәлге куәтеннән төшеп, моның урынына шәригатебезнең нигезе булган сөннәт гыйлемнәре килде. Схоластика тәэсиреннән таралган булган бозык әхлак, тиз генә бетмәсә дә, иншә Аллаһ [Аллаһ теләсә], киләчәк көннәрдә әкренләп бетәр булса кирәк.

Моннан аңлашылганча, мәмләкәтебездә хәдис гыйлеменең бүгенге көнгә кадәр таралганы яңа бер нәрсә. Кагыйдәләре һәм ысуллары белән шөгыльләнү якынча һиҗри ундүртенче йөз башыннан башланган[57]. Шуның өчендер ки китап [Коръән] һәм сөннәт, рәсүлуллаһ һәм сәхабәләрнең тормыш юллары турында гыйлемнәрдә мәмләкәтебезнең карт галимнәренә караганда яшьләре алда. Моңа шөбһәсе булганнар үзләре тәҗрибә итеп күрерләр яки күренгән тәҗрибәләр белән канәгать булырлар. Яшьләр арасында «Сахих»ны түгел, хәтта тулысынча «Көтебе ситтә»не күреп, укып чыккан затларга очрар.

Мәмләкәтебездә җитди рәвештә хәдис гыйлеменә хезмәт итүчеләрнең остазлары, безнең белүебезчә – Галимҗан Баруди хәзрәтләре булса кирәк. Бу зат «Көтебе ситтә»нең имамы

[57] Мөхтәрәм остазыбыз Габделфәттах Шәлчеле хәзрәтләре 1294 елда хаҗ кылу максаты белән Хиҗазга сәфәр кылган вакытта Мәккә Мөкәррәмәдә Сәййид Мөхәммәд әл-Кәтиби хәзрәтләрендә «Сахих әл-Бохари» дәресләренә [йөрүен] дәвам итеп шәһадәтнамә алган. Китабы булмаганнанмы яки шәкертләрендә кызыксыну булмаганлыктанмы, нигәдер дәрес бирмәде.

булган «Җамигъ әс-сахих» китабын дәрес бирү программасына кертеп, үзе даими рәвештә укыткан, хәтта ки берничә тапкыр укып чыккан һәм гүзәл шәкертләр җитештергән.

Мәдинә Мөнәввәрәдә хәдис-шәриф мөдәррисләреннән булган Сәййид Мөхәммәд Гали әз-Заһири әл-Мәдәни әл-Витри 1314 елда мәмләкәтебезгә килгәч, түгәрәккә утырып биргән дәресенә бик күп шәкертләр, мөгаллимнәр, имамнар, мөдәррисләр җыелып, хәдис-шәриф тыңлыйлар иде һәм бу мөбарәк гыйлемнең ләззәтен хыялый татып калдылар. Югарыда күрсәтелгән хәзрәтләре бу сәфәрендә Бохара шәһәренә дә барып, анда хәдис мәҗлесе булдырыга килешүгә иреште, өмет итмәгән җирдә бер күркәм сөннәт калдырып китте.

Инде бүгенге көнебездә дини мәдрәсәләребезнең күбесендә Коръән-шәриф һәм хәдис гыйлемнәре гомуми бер рәвештә дәрес буларак укытыла. «Һәр нәрсәдә бер генә тыю булса, гыйлемдә [күп] тыюлар», – дигәннәр. Аллаһ Тәгалә күктән булган афәттән һәм җирдәге бәләләрдән сакласын! Халкыбызның белем алуга теләге һәм мәхәббәте көннән көн артсын!

# XV

# Хәдис һәм аның мөгаллиме

Шәкертләр һәм мөгалимнәр хакында гомуми әдәпләр булган кебек, хәдис шәехләрен һәм хәдис тыңлаучыларны хөрмәтләү тиеш булган аерым әдәпләр дә бар. Хәдис өйрәнергә керешкән шәкертләр аларны белергә һәм мөмкин кадәр шуларны гамәлдә кулланырга тиешле. Чөнки агачның максаты җимеш булган кебек, гыйлемнең максаты да гамәл. Хәдис өйрәнү өчен махсус әдәпләр хакында Ибне Салах, Нәвави, Гыйракый, Сөютый, Ибне Хәҗәр һәм Сәхави кебек гыйлем ияләре тарафыннан гүзәл-гүзәл хезмәтләр төзелгән[58]. Без [мин]

[58] Киләчәктә, имам Бохари тормыш юлында югарыда телгә алынган хәзрәтләренең дә бер нәсыйхәте әйтелер.

матди һәм мәгънәви яктан тулысынча гаҗиз булган хәлдә, Хак Сөбханә һәм Тәгалә хәзрәтләренә күп шөкерләр булсын, телгә алынган газиз хезмәтләрне тулы ләззәт белән кабат-кабат өйрәнүгә һәм соңгы чиккә кадәр кулланугa ирештек. Әгәр дә хәлләре яхшы булган адәмнәр боларны өйрәнмәсәләр, фәкать теләкләре һәм тырышлыклары юклыгыннан өйрәнмәсләр, чөнки бу турыда күрсәтәчәк яраклы сылтаулары булмас. Шуның өчен без мәгълүм китапларда бәян ителгән әдәпләр хакында мәгълүмат бирмәячәкбез. Бәлки, иҗтимагый әдәпләргә караган бер-ике сүз әйтәчәкбез.

Бу заманыбызда һәм мәмләкәтебездә хәдис гыйлеменнән дәрес бирүчеләр (алдынгы тәфсир укытучылары белән бергә) тарих, георафия фәннәре белән бергә өммәтләр тормышы, яшәү өчен көрәш мәсьәләләре һәм иҗтимагый гыйлемнәр белән дә таныш булырга тиеш. Чөнки бу нәрсәләрдән хәбәре булмаган бер мөгаллим һәртөрле уйлап табылган нәрсәләрне, фәнни ачышларны ишетеп торган бүгенге шәкертләргә, Коръән һәм хәдис-шәрифләрнең олуг гыйлемнәрен алып, диннең максаты булган адәм баласының ахирәттәге бәхете белән бергә дөньяви бәхетен, ислам дине адәм баласының рәхәт һәм бәхетенә җаваплы булуын аңлата белмәс. Боларны аңлата белмәгән мөгаллимнәр Коръән һәм хәдис укыган шәкертләренә нинди чаралар белән ислам диненә ихласлыкларын һәм мәхәббәтләрен булдырырлар? Коръән һәм хәдис дәресләре белән үз диненә күңелен куярга көче җитмәгән шәкерт «Исагуҗи» һәм «Шәмсия» [логика китаплары] дәресләре аркылы ихласлык куя алмаячагы мәгълүм. «Зыян китерә торган нәрсәне юлдан алып ату – иманның бер өлеше», – дип[59] шәкертләренә дәрес биргәндә бу хәдиснең ишарәте яки алдынгы юллар белән дәлилләнгән пароходлар йөртү, тимер юллар салу, урамнарны киң һәм тратуарларны тәртиптә тоту, сулар агар өчен чокырлар, каналлар ясау, бураннарда адашучыларга ярдәм өчен маяклар кадау, авылларны мөмкин кадәр янгыннардан куркынычсыз

---

[59] Иман җитмештән артык тармактан тора. Аларның иң өстене «Аллаһтан башка табынырлык зат юк», дип әйтү һәм иң түбәне юлдан башкаларга комачаулый торган әйберне алып ату. Сахих әл-Бохари. – Т. 1. – Б. 8.

булган планнар белән кору, урамда тәрәзәләрдән чүп-чарлар, зарарлы нәрсәләр ташлаудан саклану, авыл халкының үз каршыларында булган гореф-гадәтләренә теләктәшлек итү кебек гомумяхшы нәрсәләрне русларга һәм франкларга хас икәнен белеп тә, ислам белән бәйләнешсез нәрсәләр, дип ышанган мөгаллимнең хәдис дәресен укытырга хакы юк. Моның кебек мөгаллимнәрнең хәдис һәм тәфсир укытмауларыннан бер зарар булса, укытуларыннан ун зарар булыр. Ялгыш укытылган шәкертләргә караганда зиһеннәре буш булган шәкертләрнең куркынычлары азрак.

Коръән һәм хәдис-шәриф дәресләрендә [шәкертләрнең] күңелләренә хәлләренә һәм заманга карата азык салынмавы, иҗтимагый тормыш, кануннар рухы кебек нәрсәләрдән кайбер мәгълүмат бирелмәү сәбәбле, мәҗбүри рәвештә шәкертләр Монтескье, Вальтер, Жан-Жак Руссо, Кант кебек фәлсәфәчеләр сүзләрен ишеткәч, хәйран калалар һәм исламда шундый бөек тәгълимат булмавына кайгыралар. Шунысы гаҗәп ки, шәкертләрнең кыска рәвештә күп мәгънә бирә торган хәдисләрне һәм хикмәт чишмәсе булган аять-шәрифләрне бер тарафка куеп, икенчеләргә сарылуларына сәбәп булган мөгаллим бу турыда җаваплы булган хәлдә, шәкертләрен гаепләп орышыр һәм һәр кабәхәтлекне алар өстенә атар.

Америка хастәханәләренең берсендә тәҗрибә ясаган бер христиан гарәп докторының гарәп сүзләре белән язылган бер китабын укыганда: «Моның кебек бер галим зат тәфсир һәм хәдис дәресләрен укытып, Коръән һәм хәдисләрнең камиллекләреннән шәкертләр хәбәрдар булсалар иде», – дип кызыктым. Чөнки сөйләгән мәгълүматы тулысынча ислам кагыйдәләренә тәңгәл килә иде.

# XVI

## Көтебе ситтә

Хәдис гыйлеменең асылы һәм нигезе итеп әһәмият бирелгән «Көтебе ситтә», икенче төрле әйткәндә, «Өммеһате ситте», «Сыйхах ситтә» болар: «Сахих Бохари», «Сахих Мөслим», «Сөнән Әби Дауд», «Җамигъ Тирмизи», «Сөнән Нәсаи», «Сөнән Ибне Маҗә».

«Көтебе ситтә»не болай бәян итүебез күпчелек галимнәр фикере буенча. Кайберәүләр[60] «Сөнән Ибне Маҗә» урынына имам Мәлик хәзрәтләренең «Әл-мөватта»ны санаганнар, кайберләре алтынчы китап булырга «Мөснәд әд-Дарими» лаек дигәннәр[61]. Без бу җирдә шуның өчен «Сөнән Ибне Маҗә» белән «Әл-мөватта»ның һәр икесен сөйләячәкбез. «Мөснәд әд-Дарими хакында мәгълүматыбыз булмаганлыктан, нөсхәсенең басылу-басылмавын белмәгәнлектән һәм бу көнгә кадәр ул китапны күрмәгәнлектән, аның хакында бәхәсләшергә көчебез булмады.

Боларның исемнәрен санаган китапларның әүвәлге икесе «сахихайн», калган дүртесе «сөнән әрбәга»; «Сөнән Ибне Маҗә» белән «Әл-мөватта»дан башкалары «Көтебе хамсә» дип билгеле.

Бохари белән Мөслим «Сахих»ларында булган хәдисләр хакында Бохари белән Мөслим тарафыннан берүк фикердә булган мәгънәсе белән «мөттәфәкъ галәйһи» диләр. Сахих хәдисләрнең бөтенесе дә «Сахихайн»да [Бохари һәм Мөслимнең ике «Сахих»ы] булу мәҗбүри түгел, Бохари һәм Мөслим үзләре дә моны мәҗбүри итмәгәннәр. Шул сәбәпле, бу ике «Сахих» хәдисләреннән арттырып төзелгән башка «Сахих»лар да бар: «Сахих Ибне Хиббан», «Сахих Ибне Хөзәймә», «Әл-

---

[60] Болардан Морад Рәзин әс-Сәркастый булып, аңа исә Мәҗдеддин Ибне әл-Әсир ияргән. «Фәтех әл-мөгыйс». – Б. 33.

[61] Бу сүзне әйтүче Галяи белән Нәвави. Фәтех әл-мөгыйс. – Б. 33, «Тәдриб әр-рави» – Б. 57.

мөстәдрәк[62] лил-Хаким» кебек китаплар бу җөмләдән. Әмма «Сахихайн»да булган хәдисләрнең һәрберсенең сахих дип кистереп әйтергә мөмкинме, монда гыйлем әһелләре арасында зур бер низаг бар[63].

## 1. «Сахих әл-Бохари»

«Җамигъ әс-сахих» дип танылган булган бу хезмәт, Корьән-шәрифтән соң, ислам галәмендә иң ышанычлы һәм хөрмәтле китапларның берсе, бәлки, беренчеседер. Анда булган хәдисләрнең аз гына саны искәрмәгә керә, калганнарының дөрес хәдисләр булуында галимнәр бер фикердә булганнар һәм мөмкин кадәр эчтәлеге белән гамәл кылуны важиб дип күргәннәр[64].

Бу хезмәт эчендә 100дән артык китап һәм 3450 баб [бүлек] булып, кабатланулары белән санаганда хәдисләре 9082 һәм кабатлануларны төшереп калдырганда 2602[65]. Кабатланган хәдисләрдә күп вакытта иснадлар башка-башка була. Иснадлары белән бергә кабатланган хәдисләр бары тик 23. Исемнәре белән телгә алынган шәехләре 289 булып, аларның Мөслим риваятендә булмаганнары 134. Хөрмәтле рәсүл әфәндебез хәзрәтләреннән өч кенә арадашчы белән риваять ителгән хәдисләр кабатланулары белән 22 һәм кабатлануларын санамаганда 16. Иң ерак чылбыр 9 арадашчы белән сөйләнелә.

Сахих Бохариның бөтен хәдисләре 183 сәхабә-арадашчылары белән риваять ителеп, аларның 31е хатын-кызлар. Хәдисләре иң күп булган сәхабәләр болар: Әбү Һөрәйрә (446 хәдис), Әнәс бине Мәлик (268 хәдис) Габдулла бине Габбас (217 хәдис), хәзрәти Гайшә (242 хәдис), Җабир бине Габдулла әл-Әнсари (90 хәдис).

---

[62] Бу хезмәттә Хәким тарафыннан, Бохари һәм Мөслим шартларына туры килгән хәлдә, «Сахих»ларына кермәгән хәдисләр җыелган. Фәкать бу китап хәдисләре хакында күп тәнкыйть бар, диләр.

[63] Бу сорауга дөрес җавап бирүчеләр дә «мөттәфикъ гәләйһи»дән 52, тик Бохари риваятеннән 68, Мөслим риваятеннән 100, барлыгы 220 хәдисне искәрмә итәләр. Тәдриб әр-рави. – Б. 43.

[64] Шәрх Нәвави галә Мөслим. – Т. 1. – Б. 36.

[65] Фәтех әл-мөгыйси шәрхү әлфийят әл-хәдис. – Б. 13.

Имам Бохари бу китап хакында: «Һәрбер хәдисне китабыма керткән вакытта иң элек тәһарәт алып, соңра, ике рәкәгать нәфел намазы укыйм, аннан соң хәдисне яза идем; мин бу хәдисләрне 600 000 хәдис арасыннан сайлап алдым[66] һәм [китабын] төзер өчен дә ун ел гомеремне сарыф иттем, Аллаһ Тәгалә белән үз арамда дәлил булачагына өмет итәм», – дип сөйләгән.

Бу китапны турыдан-туры төзүченең үзеннән риваять итүчеләрнең 90000гә җитүе һәм аларның иң ахыргы вафат булганы Әбү Тальхә Мансур бине Мөхәммәд булуы (329да вафат) риваять ителә.

**Басылган нөсхәләре.** Сахих әл-Бохари бөек бер китап булган хәлдә, берничә тапкыр басылып, һәр мәртәбә басылганда меңләгәнчә нөсхәләре таралган. Нинди җирләрдә һәм кайсы елларда басылуы моннан мәгълүм булыр:

1) Дәһли, (?) том, 1270 (1854);
2) Мисыр, 10 том 1279 (1862);
3) Лейден, 3 том 1285 (1868);
4) Болак, 8 том 1296 (1879);
5) Мисыр, 4 том, 1309 (1892);
6) Болак[67], 8 том, 1313 (1895);
7) Истамбул, 8 том, 1315 (1897);
8) Мисыр («Фәтех әл-бари» исемле), 1319 (1901);
9) Мисыр, 8 том, 1320 (1902).

---

[66] Бу сүзләрдә шәрекъ күпертүе булмаса, яхшы булыр иде, Бохари үзе күпертмәс, бәлки, аңа иснад иткән бер равидән шундый нәрсә чыгып, башкалар шуңа ияргәннәр. Алты йөз мең хәдис иснадлары белән бергә «Сахих әл-Бохари» кадәр 66 томлык бер китап булырга тиешле» диючеләр бар. Фәкать китап басу сәнәгате барлыкка килүдән элек кешеләрдә ятлау куәтенең бик көчле булуы һәм, аерым алганда, гарәпләрдә зиһен адәм ышанмаслык дәрәҗәдә куәтле булуы турында хәбәр китерелсә, югарыда телгә алынган сүзләр хаклыктан ерак булмас. Ибне Габбас, Хәммад әр-Равия, Әбү әл-Галәэ әл-Мәгарри, Әбү Рәяш, Әсмәгый, Ибне әл-Кәлби, Ибне Габдун әл-Әндәлүси, Ибне әл-Мөрәххәл һәм башкаларның зиһеннәре һәм ятлаулары хакында булган хәбәрләр хәйран калырга мәҗбүр итә.

[67] Бу басма солтан Габделхәмид акчасына 5000 нөсхә басылган.

Бу басмаларның иң дөресе һәм иң гүзәле 6 нчы номер белән күрсәтелгән «Болак» басмасы, диләр.

**Басылган шәрехләре [аңлатмалары].** Бохари «Сахих»ына тулысынча җиренә җиткереп шәрех язуны бөек галимнәр кыен хезмәтләрдән санаганнар һәм язылган шәрехләрнең күбесеннән риза булмаганнар. Хәтта ки Ибне Хальдун: «Үземнең күп шәехләремнән ишеттем, Аллаһ Тәгалә аларга рәхим кылсын: Бохари китабын шәрехләү – өммәт өчен бурыч», – ди[68]. Максаты исә «Бохари китабына шәрех язу өммәт өстендә бурыч иде, ләкин бу бурычның һаман үтәлгәне юк» дип әйтү була. Ләкин Ибне Хальдуннан соң, Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани белән Гайни тарафыннан гүзәл шәрехләр язылган. Шуның өчен Ибне Хальдун сүзләренә каршы, Кятиб Чәләби: «: Ибне Хәҗәр әл-Гаскаланиның һәм Гайнинең шәрехләре белән, бәлки, теге бурыч үтәлгәндер», – ди[69]. Бу шәрехләр хакында да замандашыбыздан бер кемсә: «Ибне Хәҗәр белән Гайни шәрехләрендә сөйләүне һәм хәдисләрне яраклаштыру, тарихи вакыйгаларны аңлату һәм хөкемнәрне чыгарулар камил булса да, иҗтимагый хәлләр һәм бүгенге халык тормышына караган шәрехләр җитәрлек түгел, бәлки, тулысынча юк, шуның өчен өммәт өстендә булган бурыч һаман өстеннән төшмәде», – ди.

Һәрхәлдә, Бохари «Сахих»ына төрле заманнарда һәм төрле мәмләкәтләрдә танылган мәшһүр галимнәр тарафыннан озынлыкта һәм кыскалыкта, төрле караштта шәрехләр язылган. Болардан без бары тик басылган шәрехләрне бер җирдә язачакбыз[70].

1) **«Фәтех әл-бари».** Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852) хезмәте булган бу шәрех, «Сахих әл-Бохари» шәрехләре

[68] Т. 1. – Б. 126.
[69] Кәшф әз-зонун. – Т. 2. – Б. 426.
[70] Бохари шәрехләре белән «Кәшф әз-зонун» һәм башка хезмәтләрдән алып төзүчеләренең вафат еллары тәртибендә «Сахих Бохари»га булган шәрехләрдән 27 китап исеме язган идек. Соңра, китабыбыз озын булмасын, дип, бастыру вакытында бары тик басылган шәрехләрне телгә алып, башкаларын төшереп калдырдык һәм «Көтебе ситтә»нең башкалары хакында да шул рәвешле иттек.

арасында иң хөрмәтлеләреннән. Ибне Хәҗәр аны 817дә башлап, 842нең рәҗәб аенда тәмамлады һәм шундый бер нигъмәткә ирешү сәбәпле, шул елның шәгъбән аенда (юбилей уңаеннан) олуг бер бәйрәм ясады. Замандашлары булган бөек затлар бу мәҗлестә бергәләп катнаштылар. (Читләрдән котлау телеграммалары җибәрелмәве ул вакытта телеграмма булмау сәбәпле булган). Бу мәҗелес өчен 500 динар (якынча 1875 сум) тотылган. Китап тәмам булу хәбәре дөньяга таралуы белән һәр тарафта булган ислам падишаһлары һәм әмирләре нөсхә итеп алдырдылар һәм нөсхәсе дә 300 динар (якынча 1215 сум) бәрабәренә язылган. Бу хезмәт Мисырда берничә тапкыр буларак, 1301дә Сиддыйк Хәсән әл-Баһвапали акчасына, икенче мәртәбә 1319да әл-Хишаб тарафыннан унбер томда басылдылар. Бу хезмәт мөхәддисләр каршында кыйммәтле булуына дәлил йөзеннән болар җитәр булса кирәк, «Сахих әл-Бохари»га шәрех язуны сораучыларга Шәүкәни: «Җиңгәннән (фәтехтән) соң һиҗрәт юк», – дип җавап биргән.

2) **«Гомдәт әл-кари».** Бәдреддин әл-Гайни (855) хезмәте булган бу шәрехнең төзүче каләме белән язылган нөсхәсе Мисырда Әзһәр китапханәсе янында булган «Китапханә»дә, 21 томда. 821нең рәҗәб аенда башлап, 847дә җөмадел-әүвәл аенда тәмамлады. Ибне Хәҗәр тарафыннан төзелгән булган «Фәтех әл-бари» нөсхәсен үрнәк итеп алып торган һәм шуннан файдаланган. Хәтта ки кайбер урыннарда тоташтан берәр биткә кадәр күчерә. Моннан башка, Рөкнеддин әл-Карими[71] шәрехеннән дә күп нәрсәләр алган һәм файдаланган. Хәтта Гайни шәрехен мактап сөйләүчеләргә Ибне Хәҗәр: «Гайни Рөкнеддин шәрехеннән файдалана, Рөкнеддин шәрехе беткәннән соң,

[71] Бу кемсә үзәк нигезе кыпчак башкаласы булган Сарай шәһәреннән. Исеме Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габделмөэмин булып, кушаматы да Рөкнеддин. Кулларында калтырау булганлыктан, «Әл-мөртәгыйш» дип билгеле булды. Соңра, Мисырга барып, Җамигъ әл-Әзһәрдә дәрес бирде. «Гараиб эн-нәвадир» исемле бу хезмәттән файдаланганнан, гаебен танып: «Аннан соң мин һиҗри 800 елга кадәр төньяк илләренә сәфәр кылгач, анда кайбер остазларымнан «Гараиб эн-нәвадир» китабын таптым», – дип искә ала.

күрерсез, Гайни сүзләре дә азаер (чөнки Рөкнеддин шәрехе тәмам түгел)», – дигән; чыннан да шулай булган. Гайни шәрехе ни өчендер үзе исән вакытта «Фәтех әл-бари» дәрәҗәсендә шөһрәт тапмаган. Ихтимал ки, бу нәрсә Ибне Хәҗәр шәрехеннән соң тәмам булганнан һәм Ибне Хәҗәр кебек зур мәҗелесләр ясап танытмавыннан, хәнәфиләргә караганда бу вакытта Мисырда шафигыйларның мәртәбәләре югары булуыннандыр. Шулай булса да, Гайни шәрехе файдалы шәрехләрдән булуын галимнәр таныганнар. Ибне Хәҗәр белән Гайни – һәр икесе дә бер заманда бер-берсенә якын буларак Мисырда тормыш итәләр һәм һәрберсе хәдис гыйлеменең белгечләреннән иде. Аерым-аерым шәрехләр язган җирдә икесе бергә язган булсалар иде, шәрехләре тагын да бик гүзәл һәм файдалы булган булыр иде. Фәкать исламда ике-өч кеше бергә китап төзү гадәте булмаган яки бик сирәк булган. Моннан башка, бу хезмәтләр үз шәкертләренә дәрес бирү ысулы белән язылган һәм, шул сәбәпле, бер-ике кемсәнең бергәләп эшләве мөмкин булмаган. Бу шәрех Истамбулда 1309да 11 томда басылган.

3) **«Иршад әс-сари».** Төзүчесе Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әбү Бәкер әл-Касталани (933). Бу шәрех 1267дә Болакта һәм 1304тә, 1326да Мисырда басылган. Әүвәлге басмасы 10 томда, өченчесе 12 томда булып, икенче басмасы хакында мәгълүматым юк. Нигездә, бу шәрех Ибне Хәҗәрнең «Фәтех әл-бари»еннән алынган, фәкать исемнәрне дөресләве, һәр исем очраганда кабатлавы шәкертләр һәм, аерым алганда, мөдәррисләр өчен кулай булган.

4) **«Төхфәт әл-бари».** Шәйхелислам Әбү Зәкәрия әл-Әнсари (926) төзүчесе булган бу хезмәт өченче басма «Иршад әс-сари» белән бергә басылган.

5) **Ән-нур әс-сари».** Хәсән әл-Гадәви (1303) төзүчесе булган бу шәрех 2нче басманың китап читендә басылган.

6) «**Хашият әс-Синди.** Әбү әл-Хәсән әл-Мәдәни әс-Синди төзүчесе булган бу хезмәт 5нче басманың китап читендә басылган.

Ислам дөньясында укудан һәм файдаланудан күбрәк язу һәм укытуга камил теләк булу сәбәпле, «Сахих әл-Бохари»га

язылган шәрехләр, аңлатулар хисапсыз дәрәҗәдә күп булып, инде бу хезмәтләрнең күбесе Европа һәм Мисыр китапханәләрендә җыелып торалар. Фәкать өйрәтүчеләр һәм дәрес бирүчеләр өчен «Иршад әс-сари», хәдис гыйлеменә иярәшү һәм осталык булдыру максатында булганнар өчен «Фәтех әл-бари», хәнәфи мәзһәбенчә, хәдисләрдән хөкем чыгара белү теләгендә булганнар өчен «Гомдәт әл-кари» җитәрлек булганлыктан, шулар белән башкалардан хаҗәтсез булырга мөмкин. Бер-берсенең нөсхәсеннән булган озын шәрехләр гомерне әрәм итүгә һәм күп вакытта гыйлемне бетерүгә сәбәп була. Ибне Хальдун китапның күп булуы гыйлем алудан тыя, дип саный[72].

**Кыскартылганнары**. Китапларның кыскартылганнары үз дәрәҗәләренә җитми. Аерым Бохари «Сахих»ы кебек мөбарәк бер китапның кыскартылганы ышанычлы булу җәһәтеннән асылына тиңләштерелми. Кайбер китап төзүчеләр үзләренең китапларының кыскартылуына һич риза булмыйлар, имеш. Имам Мәсгуди «Мәруҗ әз-зәһәб» кереш сүзендә: «Кем аның мәгънәсен үзгәртсә, берәр рөкенен алып ташласа, ачык бер билгесен бетерсә, үзгәртсә, кыскартса яки бездән башка берәүгә нисбәт итсә, аңа Аллаһның ачуы булсын һәм сабырлыгы җитмәслек төрле бәлаләргә дучар булсын һәм Аллаһ аны башкаларга гыйбрәт итсен!» – ди. Якут Хәмәви «Мөгъҗәм әл-бөлдан» кереш сүзендә: «Бу китапны күчерүчегә, файдаланучыга минем хакым бар: язганнарымны бозып, үзгәртеп, урыннарыннан күчереп, тырышлыгымны бетермәсен, чөнки кайберәүләр берәр сүзне кирәксенмәскә мөмкин, ә башкалар ул сүз өчен үлеп торалар. Әгәр дә минем нәсыйхәтемне үтәсәгез, Аллаһ сезне изгеләрдән кылсын, әгәр сүземне тотмасагыз, Аллаһ кыямәт көнендә тиешле җәзасын бирсен!» – дигән. Шуңа карамастан, Хәмәвинең бу үтенүенең имам Сөютыйга тәэсире булмаган, ул «Мөгъҗәм әл-бөлдан»ның кулларын, аякларын һәм канатларын сындырып кыскарткан. Төзүче [моңа] ризамы-түгелме, «Җамигъ әс-сахих»ны кыскарткан затлар да булган. Бу көндә басылган кыскартмалар болар:

---

[72] Т. 1. – Б. 274.

1) «Җәмегъ ән-ниһаяти фи бәдәэ әл-хайри вә әл-гаяһ». 675тә вафат булган Габдулла бине Сәгъд бине Хәмзә тарафыннан кыскартылган. 1302 елда ташбасма белән Мисырда басылды, янында Габделмәҗид әш-Шурнуби шәрехе дә бар.

2) «Әт-тәҗрид әс-сарих». Төзүчесе 893тә вафат булган Шиһабеддин Әбү әл-Габбас Әхмәд бине Әхмәд бине Габдел-латыйф әш-Шәрҗи әз-Зөбәйди[73]. 1287дә бер томда Мисырда «Болак» нәшриятында басылган. Моңа исә 1307дә вафат булган Әбү әт-Таййиб Сиддыйк бине Хәсән әл-Хөсәени әл-Каннуҗи әл-Бохари тарафыннан «Гаунә әл-бари лихилли әдилләт әл-Бохари» исемле бер шәрех язылып «Нәйл әл-әүтар»ның китап читендә Мисырда 1297дә басылды.

**Әсмаи риҗәл.** «Сахих Бохари»да телгә алынган кемсә-ләрнең тормыш юллары белән таныштыру хакында язылган хезмәтләрдән мәшһүрләре болар:

1) «Әсмаи риҗәл әл-Бохари»[74], Әбү Наср әл-Кәлябази (378).

2) «Әл-игъләм бимән зүкира фи әл-Бохари мин әл-әгъләм», Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852).

3) «Әл-җәмгъ бәйнә китабәй әл-Кәлябази вә Әби Бәкер әл-Исбаһани», Әбү әл-Фадыл әл-Мәкъдисинеке (507). Бу хезмәт Хәйдәрабад әддәкәндә ике томда басылган.

4) «Куррат әл-гайни фи дабтый әсмаи риҗәл әс-сахихайн». Габделгани әл-Бахрани. 1 томда Хәйдәрабад әддәкәндә басыл-ган.

**Бабларының [бүлекләренең] тәрҗемәләренә [аңлату-ларына] булган шәрехләр.** «Шәрхү тәраҗими әбваб әл-Бо-хари». Шаһ Вәлиулла әд-Дәһләви (1176). Бу хезмәт тә Хәйдә-рабад әддәкәндә басылган.

**Күрсәткечләре.** «Мифтахү сахих әл-Бохари». Истамбулда Фатих Җамигы мөдәррисләреннән Мөхәммәд Шәриф әт-Ту-кади. Бу хезмәт 192 биттә 1313тә Истамбулда басылган. Хәдис-

---

[73] Замандашларыбыздан мөхтәрәм Мөхәммәд Зәһәни хәзрәтләре бу китапны Хөсәен бине Мөбарәк әз-Зөбәйди исемле затка нинди дәлилгә нигезләнеп иснад итүен аңламадык. Әл-хәкаик. – Т. 1. – Б. 8.

[74] Бу китапның исемен белмәвем сәбәпле, «Әсмаи риҗәл әл-Бохари» дип яздым.

шәрифләрнең беренче сүзе хәтердә булса, бу күрсәткечтән карап, кирәк булган хәдисне табарга мөмкин була. Шул яктан, бу китап файдалы хезмәтләрдән.

## 2. «Сахих Мөслим»

«Җамигъ әс-сахих» һәм «Әл-мөснәд әс-сахих» дип танылган бу китап «Көтебе ситтә»нең икенчесе булып, Бохари «Сахих»ы белән бергә икесе «Сахихан» һәм «Сахихайн» дип билгеле. Әбү Гали әл-Хөсәен ән-Нисабури Мөслим «Сахих»ын хәтта Бохари «Сахих»ыннан өстен күргән һәм кайбер Көнбатыш галимнәре дә бу фикерне алганнар. Тик бу әһәмиятле бер мәсьәлә түгел. Чөнки төзелеше буенча – Мөслим «Сахих»ы һәм иснадларның ышанычлыгы буенча – Бохари «Сахих»ы гүзәл икәнлеге турында күпчелек галимнәр бер фикердә торганнар.

«Сахих Мөслим» өч йөз мең хәдис сайлап алган, хәдисләрнең саны кабатланулар белән 12000 һәм кабатланулардан башка 4000. Иң яхшы сәнәдле хәдисләр Расүлуллаһ хәзрәтләреннән дүрт арадашчы белән сөйләнелеп, болар якынча 80.

Мөхәддисләр, тикшергәннән соң, «Сахих Мөслим»дә булган бу хәдисләрне аерып алып, хаталы булганнарын игълан иткәннәр: 1) Көсуф намазын рәсүлүллаһ өч рөкүгъ белән укыды дигән хәдис (т. 1, б. 247); 2) Җирнең шимбә көн барлыкка китерелүе хәдисе (т. 2, б. 340); 3) Әбү Суфьян, мөселман булганнан соң, кызы Өмме Хәбибәне рәсүлүллаһ хәзрәтләренә бирүе хакында булган хәдис (т. 2, б. 264). Фәкать болар гаять аз һәм дә гамәл кылуга карамаганнар[75].

[75] Шулай ук «Нәхнү нәҗи яумәл-кыямә ган кәзә вә кәзә унзур» («Без кыямәт көнендә киләчәкбез һәм моны кара») хәдисе дә (Т. 1. – Б. 70) хаталы булган, диләр. Гүя дөресе «Нәхнү нәҗи яумәл-кыямә галә күм» булып, «күм» сүзе «кәзә» рәвешендә язылган, мәгънәсен килештерә алмаган бу кемсә китап аңлатмасына «асылында шулай тикшер» мәгнәсендә булган «кәзә унзур» дип язган, соңра шул сүз мәтен [төп текст] буларак күчерелгән була.

**Басылган нөсхәләре.** «Сахих Мөслим» бу көнебезгә кадәр бу урыннарда басылган:

1) Калькутта, 1265 (1849);

2) Болак, 2 том, 1290 (1873);

3) Мисыр, 1327 (1909).

**Басылган шәрехләре.** «Шәрех ән-Нәвави» (676). Бу шәрех «Сахих Бохари» шәрехе булган «Иршад әс-сари» нөсхәләре аңлатмасында ике тапкыр басылган.

**Әсмаи риҗәл.** Басылган «Әсмаи риҗәл» Бохари «Әсмаи риҗәл»ен сөйләгәндә үтте, шунда мөрәҗәгать ителә.

**Күрсәткечләре.** Аңа күрсәткеч буларак Истамбулда Фатих Җамигый мөдәррисләреннән Мөхәммәд Шәриф әт-Тукади «Мифтахү сахихый Мөслим» исеме белән бер китап төзеп, 52 биттә бастырган. Хәдисләрнең беренче сүзләре алфавит тәртибе белән бирелгән.

## 3. «Сөнән Әби Дауд»

«Сөнән Әби Дауд» «Көтебе синттә»нең өченчесе булып, хәдис фәнендә кабул ителгән хөрмәтле бер хезмәт. Фикһ мәсьәләләрен җыю буенча хәтта аны «Сахихайн»нан дә артык күрүчеләр бар. Бөек галимнәрдән булган Ибне әл-Әгъраби: «Кулында Коръән-шәриф белән «Сөнән Әби Дауд» булган кемсә һәрбер китаптан хаҗәтсез булыр» – дигән. Бу хезмәттә сөләсияттән (өч кешедән торган иснадлы) бер генә хәдис барлыгы риваять ителә. Әбү Дауд бу китапны төзегәннән соң Әхмәд бине Хәнбәл хәзрәтләренә күрсәткән һәм, югарыда күрсәтелгәнчә, яхшы дип табылган. Имам Газали, мөҗтәһидләр өчен «Сөнән Әби Дауд» җитәрлек булачагын әйткән һәм шафигыйлардан күп затлар Газалинең бу фикере белән килешкәннәр. Әбү Дауд белән Тирмизи хакында: «Һәр икесе, һичшиксез, мөҗтәһид иделәр, фәкать карашларда берсе Әхмәд, икенчесе Исхак бине Раһуя мәзһәбенә карадылар», – диләр.

**Басылган нөсхәләре.** «Сөнән Әби Дауд» бер тапкыр 1280дә Мисырда һәм икенче тапкыр 1283тә ташбасма белән Дәһлидә басылган.

**Басылган шәрехләре.** «Дәрәҗатү миркат әс-согуд». Бу гасыр башында вафат булган Гали әд-Дәмнати тарафыннан язылган һәм 1298дә Мисырда басылган.

## 4. «Әл-мөҗтәба»

«Көтебе силтә»нең дүртенчесе – имам Нәсаи тарафыннан җыелган «Әл-мөҗтәба». Югарыда күрсәтелгән хәзрәтләре иң элек «Әс-сөнән әл-көбра» исемле бер китап төзеде, соңыннан, аны төзәтеп, кыскартып «Әл-мөҗтәба» һәм икенче исем белән дә «Әс-сөнән әс-сугра» китабын мәйданга китерде. Һәр ике китап «Сөнән эн-Нәсаи» дип танылган булса да, «Көтебе силтә»дән саналганы «Әлмөҗтәба»[76]. Бу китап мәртәбәсен «Сахихайн»нан соң гына санаучылар бар. Хәтта кайберәүләр: «Имам Нәсаи «Сөнән»е («Әл-мөҗтәба») дәрәҗәсендәге хөрмәтле бер китап ислам дөньясында төзелмәде», – диләр. Көнбатыш галимнәреннән кайберәүләр имам Нәсаи китабын Бохари «Сахих»ыннан да алдынгы санаганнар. «Көтебе силтә» эчендәге бары тик бу хезмәттә Әбү Хәнифә хәзрәтләреннән берникадәр хәдис риваять ителгән. Бу китап исемен кайберәүләр «н» белән «Әл-мөҗтәна» рәвешендә язганнар.

**Басылган нөсхәләре.** «Әл-мөҗтәба» 1847 һәм 1882дә бер том буларак ташбасма Канпурда, 1312дә ике томда Мисырда басылды.

**Басылган шәрехләре.** 1) «Зәһер әр-руба». Имам Сөютый төзүчесе булган бу хезмәт «Әл-мөҗтәба»нең һәрбер нөсхәсе белән бергә басылган. 2) «Шәрхү Әби әл-Хәсән әл-Мәдини әс-Синди. Өченче басманың китап читендә басылган. 3) «Гареф зәһер әр-руба». Гали әд-Дәмнати хезмәте булган бу шәрех 1299да Мисырда басылган.

---

[76] Хәдис китапларының «раваһү эн-Нәсаи» яки «раваһү әл-хамсә» яки «раваһү әс-силтә» дип әйтелүләренең максаты – шул «Әл-мөҗтәба» хәдисләре [күздә тотыла]. Кятиб Чәләбинең «Зәкиеддин әл-Мөнзири «Сөнән Әби Дауд»ны кыскартып, «Әл-мөҗтәба» дип исем куйды һәм аңа да Сөютый «Зәһер әр-руба» исеме белән шәрех язды» диюендә ялгышлык булса кирәк. Чөнки Сөютый «Зәһер әр-руба»се – имам Нәсаинең үз китабына шәрех.

## 5. «Җамигъ әт-Тирмизи»

«Көтебе ситтә»нең бишенчесе – төзүчесе имам Тирмизи булган «Җамигъ әт-Тирмизи» һәм «Сөнән әт-Тирмизи» исемнәре белән билгеле булган китап.

Имам Тирмизи, бу китапны төзегәннән соң, Хиҗаз, Гыйрак, Хорасан галимнәренә тәкъдим иткән һәм алар, тикшергәннән соң, мактаганнар. Төзелеше гүзәл, кабатланулары аз булып, дәлилләрен, сәхабәләр һәм табигыйннар мәзһәбләрен, шөбһәле булу ихтималы булган равиләрнең күньяләрен бәян итеп китүе, хәдисләрнең төрләрен һәм кимчелекләрен күрсәтүе буенча, бу китап «Сөнән» китаплары арасында файдалану өчен иң җиңеле. Бу китап хакында: «Мөҗтәһид өчен дә, мөкаллид [кайсыдыр галимгә иярүче] өчен дә җитәрлек, «Җамигъ Тирмизи» булган өйдә, гүя, пәйгамбәр үзе килеп сөйләп торыр», – дигән булганнар. Бу хезмәттә сөләсияттән [өч кешедән торган иснадлы] фәкать: «Кешеләргә шундый заман килер: алар арасында диндә сабыр итүче утлы күмер тотучыга тиң булыр» хәдисе генә бар. Шәйхелислам Әбү Исмәгыйл Габдулла әл-Әсбаһани «Җамигъ Тирмизи» хакында: «Минем уйлавымча, бу китап Бохари белән Мөслим «Сахих»ларына караганда да файдалырактыр», – дип әйтүе риваять ителә[77]. Шуңа карамастан, кайбер хәдисләре тәнкыйть ителгән[78].

**Басылган нөсхәләре.** «Җамигъ Тирмизи» 1844тә һәм 1849да ташбасма белән Дәһлидә, 1292дә 2 томда Болакта басылган.

---

[77] Тәзкирәт әл-хөффаз. – Т. 3. – Б. 38.

[78] Ибне әл-Каййим: «Хөрмәтле рәсүл белән Әбү Талибнең Шам сәфәре хакында озын хәдистә булган: «Әбү Бәкер аның белән Билалны җибәрде» дигән җөмлә хакында (Җамигъ Тирмизи. – Т. 2. – Б. 203): «Бу ачык хата, чөнки Билал ул вакытта булмаска тиеш әле», – дигән (Зад әл-мәгад. – Т. 1. – Б. 17). Ибне Тәймия: «Мин – гыйлемнең шәһәре һәм Гали – аның ишеге» хәдисе хакында ««ялган» ди (Әл-мәҗмугат әл-көбра. – Б. 337.). Имам Тирмизи «Гали казанышлары» бүлегендә: «Мин – хикмәт йорты һәм Гали – аның ишеге», – дип бер хәдис сөйли (Т. 2. – Б. 214). Ибне Тәймия максаты бу хәдисме, гаҗәп?!

**Басылган шәрехләре.** «Нәфегъ куәт әл-могътәзи», Гали әд-Дәмнәти хезмәте булган бу шәрех Дәһлидә басылган нөсхәнең китап читендә басылган.

## 6. «Сөнән Ибне Маҗә»

«Көтебе ситтә»нең алтынчысы, күпчелек галимнәр санавынча – «Сөнән Ибне Маҗә». Хәдисләренең саны 4000 булып, арада хөрмәтле рәсүлдән өч кенә арадашчы белән риваять ителгән өч хәдис бар.

Моны исә башлап алтынчы китап итеп санаучы әл-Фадыл бине Таһир әл-Мөкаддәси булган. Әмма Мәҗдеддин бине әл-Әсир: «Ибне Маҗә «Сөнән»е фикыһ буенча караганда, файдалы бер хезмәт булса да, хәдисләре сафлык җәһәтеннән «Көтебе хәмсә» дәрәҗәсендә түгел, бәлки, арада мөнкәр [кире кагылучы] хәдисләр дә бар», – дип аның урынына «Әл-мөватта»ны алтынчы китап итеп караган. Ибне Маҗәнең Казвин [шәһәр исеме] фазыйләте хакында риваять иткән хәдисе (т. 2, б. 92–93) – мәудуг, диләр. Шулай ук аягүрә бәвел итүдән тыеп, Җабирдән риваять иткән хәдисе хакында да мөхәддисләр зур низаглар чыгара[79]. Сөләсият буларак биш хәдис барлыгы риваять ителә.

**Басылган нөсхәләре.** «Сөнән Ибне Маҗә» 1282дә һәм 1889да ташбасма белән Дәһлидә, 1313тә ике томда Мисырда басылды.

**Басылган шәрехләре.** 1) «Мәсабих әз-зөҗәҗә», имам Сөютый (911) хезмәте булган бу шәрех 1282дә басылган булган

---

[79] 1) Ибне Маҗәнең: «Җабир радыяллаһү ганһү әйтте: «Рәсүлүллаһ (саллаллаһү галәйһи вә сәлләм) басып бәвел итүдән тыйды» хәдисе шәрехендә «Нәйл әл-әүтар» төзүчесе: «иснадында Гали бине Фадыл бар, ул [хәдис] – мәтрүк (яраксыз). Моңарчы пәйгамбәр галәйһиссәламнең басып бәвел итүдән тыя торган бер хәдис тә дөрес түгел, дип әл-Хафиз (Ибне Хәҗәр) сүзен китергән идек», – ди. Бу бәхәстә Ибне әл-Каййим «Зад әл-мәгад»та: «Пәйгамбәр саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнән басып, утырып бәвел итүе дә риваять ителде, шуңа күрә икесе дә сөннәт», – ди. Болар исә Ибне Маҗә риваятен тәнкыйтьләү була. Казвин хәдисе хакында «Мизан әл-игътидәл»дә (т. 1, б. 224): «Ибне Маҗә үзенең китабын бу ялган хәдисне кертеп ямьсезләде», – ди.

нөсхәнең китап читендә чыккан. 2) «Шәрхү Әби әл-Хәсән әл-Мәдәни әс-Сәнәди (1138). Бу шәрех 1313тә басылган нөсхәнең китап читендә басылган. 3) «Инҗах әл-хаҗәти галә «Сөнән Ибне Маҗә». Габделгани бине Әби Сәгыйд әл-Гомәри (1296) хезмәте булган бу шәрех «Мәсабих әз-зөҗәҗә» белән бергә берничә басманың китап читендә басылган.

## 7. «Әл-мөватта»

«Көтебе ситтә»нең алтынчысы – Мәҗдеддин бине әл-Әсир атаганча, имам Мәлик хәзрәтләре тарафыннан төзелгән «Әл-мөватта». Имам Мәлик бу китапны 100000 хәдистән сайлап алып, кырык ел төзегән. Иң беренче мәртәбә бабларга аерылып язылган хәдис китабы бу «Әл-мөватта» булып, сәхабәләр һәм табигыйннар сүзләре кертелеп, бөтен хәдисе якынча 1720 кадәр була. Аның эчендә мөснәд 600, мөрсәл 222, мәукуф 613, табигыйн сүзләре 285.

«Әл-мөватта»ны үзеннән турыдан-туры риваять итү максаты белән җиһанның дүрт тарафыннан гыйлем әһелләре төркем-төркем булып имам Мәлик янына килгән булганнар. Арадашсыз буларак бер меңнән артык адәм риваять итүе риваять ителә. Бу җөмләдән Шафигый, Мөхәммәд бине әл-Хәсән, Ибне Вәһеб, Ибне әл-Касыйм кебек мәшһүр фәкыйһләр [фикыһ галимнәре]; Яхъя бине Сәгыйд әл-Каттан, Габдрахман бине Мәһди, Габдерраззак кебек хәдис имамнары; Һарун әр-Рашид, әл-Әмин, әл-Маэмун кебек хәлифәләр була иде. Имам Мәлик үзе исән вакытында «Әл-мөватта» бөтен ислам дөньясына танылган булып, нөсхәсе һәрбер вилаятькә таралган. Әбү Йосыф хәзрәтләренең «Әл-әмали» исемле хезмәте һәм имам Мөхәммәднең «Әл-асар»ы «Әл-мөватта» белән бер заманда дөньяга чыкса да, шөһрәт һәм игътибарда аралары җир белән күк арасы шикелле калган.

Имам Шафигый «Әл-мөватта» хакында: «Коръән-шәрифтән соң иң дөрес китап», – дигән булган[80]. Казый Гаяз: «Ислам

[80] Имам Шафигый бу сүзен «Җамигъ Суфьян Сәүри», «Мөсаннәф Хәммад бине Сәлмә» кебек хезмәтләрдән [кыйммәтен] арттыру максаты белән сөйләгән. Аның заманында Бохари һәм Мөслим «Сахих»лары юк иде.

галәмендә «Әл-мөватта» дәрәҗәсендә адәмнәрнең игътибарына тиң булган бер китап юк», – дигән.

«Әл-мөватта»да булган бер фазыйләт – мөхәддисләр арасында иң дөрес булганлыгы белән танылган иснадлардан күбесен үз эченә алганлыгыннан. Бу иснад Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя каршында: Мөхәммәд бине Мөслим бине Шиһаб Зөһри – Сәлим бине Габдулла – Габдулла бине Гомәр. Гали бине әл-Мәдәни һәм башкалар каршында: Мөхәммәд бине Сирин – Гобәйдә бине Гомәр һәм Салман – Гали бине Әбү Талиб. Яхъя бине Мәгыйн белән Нәсаи каршында: Ибраһим Нәхәгыйи – Галькамә – Габдулла бине Мәсгуд. Әбү Бәкер бине Әбү Шәйбә һәм башкалар каршында: Мөхәммәд бине Мөслим бине Шиһаб Зөһри – Зәйнелгабидин Гали бине әл-Хөсәен – әл-Хөсәен бине Гали – Гали бине Әбү Талиб. Имам Бохари каршында: Мәлик – Нәфигъ – Габдулла бине Гомәр.

**Басылган нөсхәләре.** «Әл-мөватта» нөсхәләре берничә булып, араларында кайбер аермалар булуы риваять ителә. Бүгенге көндә ике төрле нөсхәсе басылды. Берсе Яхъя бине Яхъя әл-Масмуди риваяте булып, 1280дә Түниста һәм ташбасма белән ике томда Мисырда, 1291дә Дәһлидә, 1889да Лаһорда басылган. Икенчесе исә Мөхәммәд бине әл-Хәсән әл-Шәйбани риваяте булып, 1291дә Лудьяниждә һәм Габделхәй әл-Ләкнәви дөресләве белән ике тапкыр ташбасма белән басылган. Быел 1327 (1909) елда «Мәгариф» акчасы белән Казанда басыла башлады[81].

**Басылган шәрехләре.** 1) «Шәрхү Зәркани», Мөхәммәд бине Габделбакый бине Йосыф Зәркани (1122) хезмәте булган бу шәрех 1280дә 4 томда Мисырда басылды. 2) «Әл-мосаффа». 3) «Әл-мөсәввә». Һәр икесе Вәлиулла әд-Диһләви әл-Гомәри (1239) хезмәте булып, беренчесе фарсыча, икенчесе гарәпчә. Һәр икесе Һиндстанда басылган. 4) «Әт-тәгъликъ әл-мөмәҗҗид», имам Мөхәммәд риваятендә булган бу шәрех Габделхәй

[81] «Мәгариф» тарафыннан безгә бүләк ителгән нөсхәсеннән бу хезмәтнең 1328 (1910)да рабигыль-әүвәл аенда тәмам булганлыгы аңлашылды. Бөтенесе 394 биттә булып, китап читендә Габделхәй әл-Ләкнәвинең «Әт-тәгъликъ әл-мөмәҗҗид»е [белән] бергә гүзәл кәгазь һәм гүзәл хәрефтә хәдис китабына лаек рәвештә басылган.

әл-Ләкнәви (1304) хезмәте булып, Һиндстанда һәм Казанда имам Мөхәммәд риваяте булган басылган мәтеннәрнең китап читендә чыккан.

# XVII

## «Көтебе ситтә» төзүчеләре

Хәдис фәнендә «Көтебе ситтә»нең иң хөрмәтле, мөбарәк хезмәтләре булган кебек, аларның төзүчеләре дә ислам галәмендә иң ышанычлы һәм иң бөек затлар. «Көтебе ситтә» белән тиешле дәрәҗәдә таныш булыр өчен төзүчеләре белән дә таныш булырга кирәк. Шуның өчен без бу җирдә «Көтебе ситтә» төзүчеләренең тормыш юлларын язарга булдык. Югарыда «Көтебе ситтә»не сөйләвебез тәртип буенча булмаса да, төзүчеләрен сөйләгән җирдә сөйләвебез имам Мәлик хәзрәтләреннән башланачак. «Әл-мөватта» берникадәр «Сахих Бохари» һәм «Сахих Мөслим» дәрәҗәсендә булмас, хәтта ки күпчелек галимнәр бу китапны «Көтебе ситтә» арасына куймаса да, имам Мәлик үзе «Көтебе ситтә» төзүчеләренә караганда, әлбәттә, элегрәк бер зат булып, «Көтебе ситтә» төзүчеләре аның шәкертләренең шәкертләре. Шуңа күрә мөхтәрәм остазларын үзенең лаеклы урынына кую максаты белән иң элек сөйләячәк кемсәбез имам Мәлик хәзрәтләре булыр.

### Имам Мәлик

Хәдис галимнәренең остазы һәм мәшһүр дүрт мәзһәбнең берсе булган мәлики мәзһәбенең имамы. Бу затның исеме Мәлик, күньясе Әбү Габдулла булып, атасы да Әнәс бине Мәлик (мәшһүр Әнәс бине Мәлик түгел) бине Әбү Гамир әл-Әсбәхи әл-Мәдәни иде. Бабасы Әбү Гамир хөрмәтле рәсүлне күреп сәхабә булуы риваять ителә. Хөрмәтле сәләфләр арасында имам Мәлик «фәкыйһ әл-өммә» [өммәт фәкыйһе],

'«имам дар әл-һиҗрә» [һиҗрәт җиренең имамы] кебек горур кушаматлар белән танылган иде.

Имам Мәлик хәзрәтләре һиҗрәттән 93нче елда Мәдинәдә анадан туып, Габдулла бине Гомәр бине әл-Хәттабның азат ителгән колы булган Нәфигъ Әбү Габдулла һәм Зөһри Мөхәммәд бине Мөслим бине Шиһаб кебек олуг табигыйн-нардан хәдис-шәриф тыңлаган. Рабига әр-Раэи бине Әбү Габдрахман әт-Тәйми, Гамир бине Габдулла бине әз-Зөбәйр, Габдулла бине Динар, Җәгъфәр бине Мөхәммәд әс-Садыйк һәм башкалар имам Мәлик хәзрәтләренең шәехләреннән иде. Нәфигъ бине Әбү Нәгыймнән һәм башкалардан кыйраәт [уку] гыйлеме алды. Үзендә укыган галимнәрнең чиге һәм хисабы юк. Габдулла бине әл-Мөбарәк, Мөхәммәд бине әл-Хәсән әш-Шәйбани, Суфьян әс-Сәүри, Габдрахман әл-Әүзагый, Ләйс бине Сәгъд, Мөхәммәд бине Идрис әш-Шафигый һәм башкалар имам Мәлик шәкертләреннән.

Мәшһүр җырчылардан [булуы] хакында да әл-Маэмун хәлифә тарафыннан: «Әгәр дә җырлау белән халык арасында шөһрәте чыккан булмаса, мин, әлбәттә, казый итеп куяр идем, чөнки аның гыйлеме, динилеге, әманәте һәм камиллеге күп казыйлардан артык», – дип шәһадәт бирүен[82] Исхак бине Ибраһим әл-Мәүсыйли [китерә], [ул] югарыда күрсәтелгән хәзрәтләренең шәкерте иде.

Тәфсирдә, хәдистә һәм фикыһта имам Мәлик гаять тирән белемле булганлыктан, соңгы вакытларында үзенең остазлары һәм шәехләре аның гыйлеменнән файдалана торган булдылар (болардан имам Зөһри).

Имам Мәлик заманынында фәтва бирү вазыйфасы Мәди-нәдә фәкать югарыда күрсәтелгән хәзрәтләре белән чикләнгән иде. Хәдис-шәриф дәресе вакытларында тәһарәт алып, тезләнеп утыра, камил хөрмәт һәм әдәп белән хәдис-шәриф сөйли иде. Галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез хәзрәтләренә [ка-рата] әдәп саклап Мәдинә урамнарында җәяү йөри иде, хәтта картайган көннәрендә дә бу максатка нигезләнеп, һичвакыт хайванга атланып йөрмәгән.

[82] Әгани. – Т. 5. – Б. 49.

Замандашлары хәтта яшь буенча үзеннән олы затлар югарыда күрсәтелгән хәзрәтләрен зурлыйлар һәм хәрмәт итәләр иде. Әшһәб бине Габделгазиз: «Мәлик янында Әбү Хәнифәне күрдем, атасы янында әдәпле сабый бала ничек утырса, Әбү Хәнифә дә шулай утыра иде», – ди[83].

Имам Шафигый һәрвакыт: «Әгәр дә Мәлик белән Суфьян бине Гуяйнә булмаса, Хиҗазда гыйлем калмаячак иде» һәм: «Мәлик кебек галим һәм өстен кемсә күрдегезме?» – дип сораучыларга: «Аның кебек галим һәм өстен затны күрү безгә түгел, хәтта остаз һәм шәехләребезгә дә насыйп булмаган», – ди иде.

Имам Мәлик хакында имам Шафигый белән имам Мөхәммәд арасында бу рәвештә бер бәхәс булуы риваять ителә:

«Имам Мөхәммәд [Шафигыйга]: «Сезнең остазыгыз Мәликме галим, юкса, безнең остазыбыз Әбү Хәнифәме?»

Имам Шафигый: «Вөҗдан белән хөкемгә ризамы сез?»

Имам Мөхәммәд: «Шөбһәсез».

Имам Шафигый: «Уйлап сөйләгез, Коръән-шәриф гыйлемен сезнең остазыгызмы яки безнең остазыбызмы [күбрәк] белә?»

Имам Мөхәммәд: «Шөбһә юк, сезнең остазыгыз белә».

Имам Шафигый: «Сөннәт гыйлемен сезнең остазыгызмы [күбрәк] белә, юкса, безнең отазыбызмы?

Имам Мөхәммәд: «Шөбһә юк, сезнең остазыгыз».

Имам Шафигый: «Рәсүлүллаһ сәхабәләренең сүзләрен сезнең остазыгызмы [күбрәк] белә, юкса, безнең остазыбызмы?

Имам Мөхәммәд: «Шөбһә юк, сезнең остазыгыз».

Имам Шафигый: «Инде урталыкта фәкать бер кыяс [чагыштыру] калды. Хәлбуки, чагыштыру Китап белән сөннәт буенча була[84].

Бу вакыйга дөрес булган тәкъдирдә, имам Мөхәммәднең Мәдинәгә барып, имам Мәлик янында «Әл-мөватта»ны укуын-

---

[83] Бу хәл Әбү Хәнифәнең дә бик әдәпле булуын күрсәтә. Әбү Хәнифә хәзрәтләре Имам Мәликкә караганда унөч яшькә олы.

[84] Бу хикәятне казый Ибне Халликян «Вәфият әл-әгъян»да сөйләгән (Т. 1. – Б. 439). Күңелем теләгәненнән түгел, бәлки, «шуны күрмәгән, имеш» димәсеннәр өчен бу җирдә сөйләдем.

нан элегрәк була. Фәкать имам Мөхәммәд гаять акыллы бер зат булуыннан шундый рәвештә бер бәхәскә кермәячәге, керешкән тәкъдирдә, бу дәрәҗәгә китермәячәге мәгълүм. Бәлки, имам Мөхәммәд белән имам Шафигый, бәхәс юлы белән түгел, бәлки, әдәпле бер ысулда (безнеңчә, арага салып) сөйләшкән сүзләрен мәзһәб хакында фанатизмга җиткән затлар бу калыпка куйган булалар.

Казыйларның казые Әбү Йосыфның, Һарун Рашид белән хаҗ сәфәренә барганда, Имам Мәлик белән бәхәсләре булуы риваять ителә. Имам Мәлик: «Намазда булган ялгыш кечкенә генә булса, сәҗдәи сәһүне [намазда ялгышканда өстәмә сәҗдәне] сәламнән алда кылырга, әгәр дә артык зур булса, сәламнән соң кылырга тиешле», – дип әйткәч, Әбү Йосыф та: «Бер кемсә намаз эчендә кечкенә дә, зур да ялгышлыгы булса, ни кылыр?» – дип имам Мәлик хәзрәтләрен бәхәстә җиңгән[85].

Әбү Йосыф хөрмәтле рәсүлнең саубуллашу хаҗында җомга көн Гарәфәт тавында торганда җомга намазын укуны дәгъва кылып: «Чөнки рәсүлуллаһ иң элек хөтбә һәм аннан соң ике рәкәгать намаз укыды», – дип дәлил китергән иде. Моңа каршы Имам Мәлик: «Хата сөйлисең, хөрмәтле рәсүл шимбә көн булса да, шулай иткән булыр иде, чөнки мөсафир булуыннан өйлә намазын ике рәкәгать укуы тиеш иде, кыйраәтне яшерен укуы бу намазның җомга түгел, бәлки, өйлә булуына ачык дәлил», – дип бәхәстә җиңгән, Һарун да имам Мәликнең бу сүзен дөрес күргән.

Әхмәд бине Хәнбәл хәзрәтләреннән: «Хөрмәтле рәсүл сөннәтен һәм хөрмәтле сәхабәләр сүзләрен Мәлик белән Суфьян Сәүридән кайсысы белүчерәк иде?» – диючеләргә: «Имам Мәлик белүчерәк иде», – дип җавап биргән. Әмма: «Кайсысы заһидрәк [дөньядан күбрәк ваз кичүче] иде? – диючеләргә: «Монысын үзегез беләсез, мин җавап бирмим», – дигән.

Тарихчылар һәм, аерым алганда, мөхәддисләр имам Мәлик тормыш юлын тәфсилләп язганнары кебек, кайберәүләр исә мөстәкыйль китапларда язганнар. Бу җөмләдән, Әбү Бәкер Әхмәд бине Мәрван әл-Мәлики әд-Динәвәри (310да вафат), Әбү әр-Равах Гайсә бине Мәсгуд әш-Шафигый (744тә вафат),

---

[85] Әл-мәбсуту ли-Шәмседдин әс-Сәрәхси. – Т. 1. – Б. 220.

Сөютый (аның китабы «Тәзйин әл-әраики би-мәнакыйб Мәлик» исемле).

Имам Мәлик ак йөзле, озын буйлы, зур башлы иде. Гаять вәкарьле, мәһабәт булганлыктан, мәҗлестә гайбәт сөйләнми, тавыш күтәрелми, гауга булмый һәм дә һичкем буш сүз сөйләми иде. Элекке гомерендә бөтен вакытын рәсүлүллаһ мәчетендә кичергәнлеге, соңгы вакытларда үз өендә торуы, хәтта җәмәгать намазына һәм җомга намазына чыкмавы риваять ителә. Чит җирләргә яки асыл ватаннарына китәр өчен саубуллашкан шәкертләренә: «Хак Сөбханә вә Тәгалә хәзрәтләренә тәкъвалык кылыгыз [Аннан куркыгыз], бу гыйлемне таратырга тырышыгыз, өйрәтегез, һичкемнән яшермәгез!» – ди һәм һәрвакыт: «Мин дөреслеккә ирешергә һәм хата ясарга мөмкин булган бер бәндә идем, фәтваларымны Коръән белән сөннәткә тәкъдим итегез, аларга туры килгәннәрен кабул итеп, башкаларын ташлагыз!» – дип нәсыйхәт кыла торган булган[86].

Имам Мәлик озын гомерле булганлыктан, риваяте бөек иде, шул сәбәпле, бик ерак мәмләктләрдән аның янына укыр өчен кешеләр төркем-төркем булып килделәр. Унҗиде яшеннән башлап бөтен гомерен дәрес белән кичерде. Зиһене үткен, аңлавы тиз, гыйлеме киң, диндар һәм гадел, сөннәт белән гамәл кылучы, фикыһ бүлегендә алдынгы һәм кирәкле иде. Аның заманында ислам дөньясының бөек галимнәреннән булган Әбү Хәнифә фикыһ гыйлемендә, Суфьян Сәүри хәдис риваятендә, Әүзагый сөннәт гыйлемендә башкалардан аермалы булу белән шөһрәт тапканнар иде. Бу өч кемсә арасына өләшенгән камиллекләрнең бөтенесен Хак Сөбханә вә Тәгалә имам Мәлик хәзрәтләрендә җыйды», – диләр. Үзеннән соралган кырык сигез мәсьәләнең утыз икесенә «Лә әдри» [«Мин белмим»] дип җавап бирүе һәм Әбү Җәгъфәр әл-Мансур «Әл-мөватта» белән гамәл кылыр өчен бөтен ислам мәмләкәтенә таратырга ниятләгәндә: «Алай итмә! Һәркем һәм һәрбер шәһәр халкы үз каршында нык булган дәлилләр белән гамәл кылсыннар!» – дип нәсыйхәт бирүе риваять ителә[87].

[86] Мохтәсар җамигъ бәян әл-гыйлем. – Б. 61.
[87] Мохтәсар җамигъ бәян әл-гыйлем. – Б. 67.

Габбасиларның җәберләү белән [хакимлекне] алулары [сәбәпле], бәйгатьнең [присяганың] тиеш түгеллеген сөйләгәне өчен Мәдинәдә әмир булган Җәгъфәр бине Сөләйман исемле зат тарафыннан камчы белән суктырылды һәм бу вакытта бер кулын суырып чыгардылар. Халык күзеннән төшәргә һәм игътибары бетәргә тиеш булган бу вакыйгадан соң, киресенчә, имамның хөрмәте тагын да артуы һәм мөселманнар үзенә аерым сурәттә мәхәббәт баглаулары күренгән.

Югарыда сөйләнелгән хәзрәтләренең: «Минем хакымда халык нинди фикердә һәм нинди сүзләр сөйлиләр?» дип соравына каршы: «Дусларың мактый, дошманнарың, табигый ки, әрлиләр», – дип җавап биргәннәр. Бу җавапны ишеткәч, имам хәзрәтләре дә: «Кешеләр шундый булыр инде, ләкин барлык кешеләрнең дә явыз итеп сөйләүләреннән Аллаһ сакласын!» – дигән[88].

Ибне Габделбәр хәзрәтләре имам Мәлик хакында: «Кайберәүләр аны өйдә, сәфәрдә читеккә мәсехне рөхсәт итмәгәне, Гали һәм Госман хакында кайбер сүзләре, рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләм мәчетендә төркемгә җыелган кешеләрне карап утыруы өчен гаепләделәр. Шуның белән бергә төрле ямьсез нәрсәләр белән тәнкыйтьләделәр. Ләкин Аллаһ тәгалә имам Мәликне ул гаепләрдән пакьлады һәм ул Аның каршында сөекле бәндәләрдән булды», – ди[89].

Имам Мәлик хәзрәтләренең мәзһәбе һәрбер җирдә, аерым алганда, Хиҗазда таралган булса да, соңра, көнбатыш мөселманнары арасында таралган. Бүгенге көндә Тараблис [Триполи], Бәнгази, Тунис, Җәзаир, Мәррәкеш һәм бу тарафлар бөтенләй имам Мәлик мәзһәбендә булалар.

Имам Мәлик хәзрәтләре мәшһүр риваятьләр буенча, 86 яшь вакытында 189 елда Мәдинә шәһәрендә вафат булып, «Җәннәт бәкыйг» зиратында җирләнде. Кабере билгеле. Рахимәһү Аллаһү Тәгалә [Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын]!

---

[88] Тәзкират әл-хөффаз. – Т. 1. – Б. 191.
[89] Мохтасар җамигъ бәян әл-гыйлем. – Б. 202.

# Имам Бохари

Мөхәддисләр шәехе имам Бохариның исеме Мөхәммәд, күньясе Әбү Габдулла булып, атасы Исмәгыйль бине Ибраһим бине әл-Мөгыйрә бине Бәрдизбәһ әл-Җөгъфи әл-Бохари[90]. Бәрдизбәһ дип билгеле булган (асыл исеме ачык беленмәде) кемсә фарсы кавеменнән һәм фарсылар мәзһәбеннән булып, аның улы Мөгыйрә «әл-Ямән әл-Җөгъфи» дип билгеле бер зат кулында ислам кабул итте һәм бу мөнәсәбәт белән имам Бохари «әл-Җөгъфи» дип нисбәт ителенер булды. «Әл-Ямән» исә Габдулла бине Мөхәммәд бин Җәгъфәр бине әл-Ямән исемле мөхәддиснең ерак бабаларыннан бер зат. Ибраһим бине әл-Мөгыйрә хакында мәгълүмат күренмәде. Атасы Исмәгыйль бине Ибраһим хәдис галимнәреннән булып, имам Мәлик, Хәммад бине Зәед кебек бөек затлардан риваять иткән һәм Ибне әл-Мөбарәк белән дус булган.

Имам Бохари 194 елда шәүвәл аенда Бохара шәһәрендә дөньяга килеп, яшьтән үк атасыннан ятим калды һәм анасы тәрбиясендә үсте. Бервакыт күзләре агарып, хәтта сукыр калачак, дип уйласалар да, Аллаһ Тәгалә ярдәме белән шифа тапты. Бик яшь вакытыннан ук хәдис гыйлеменә мәхәббәте төшеп, бу фәнгә булган сәләтлелеге сәбәпле, бик аз вакыт эчендә хыялы тулысынча чынга ашты. 16 яшенә ирешкәндә Габдулла бине әл-Мөбарәк һәм Вакигъ[91] кебек галимнәр тара-

---

[90] Имам Бохари тормыш юлын язучылар «Бәрдизбәһ» сүзен «бә»нең фәтхәсе, «ра» белән «зә»нең сәкене, «дәл»нең кәсрә белән, дип дөресләгәннәр. Фәкать бу дөресләү бер кемсәнең хатасына килештерү нияте белән мәйданга чыккан булса кирәк. Чөнки фарсы булган бу сүз «пәрдахтин» масдарыннан (тамырыннан) сазда яхшы уйнаучы һәм маһир дип әйтү мәгнәсендә исем фәгыйль төре булган «пәрдаз». Шуңа карамастан, бу сүзнең Мәгъриби «бә»нең һәм «дәл»нең фәтхәсе белән «Бәрдәз» булырга тиеш.

[91] Бу кемсә мөхәддисләрдән Вакигъ бине әл-Җәррах бине Мәлих булса кирәк. Фәкать моның төзүчесе юк иде, диләр (Тәзкират әл-хөффаз. – Т. 1. – Б. 281). Әбьяри аның хакында: «Шәйхелимам әш-Шафигый Зур Карафада җирләнгән», – дип белдерсә дә, моның дөреслеге шикле. Бик гаҗәп ки, хәдис имамнарыннан булган бу Вакигъ бине әл-Җәррах

фыннан төзелгән китапларны ятлаган, «Әсхаб әр-раэи» (хәнәфи мәзһәбе) дип танылган мәзһәб белән дә таныш булды. Моннан соң, 210 елда үзенең олы абыйсы Әхмәд һәм анасы белән бергә Мәккәгә сәфәр кылдылар. Хаҗ гыйбадәте тамалангач, Әхмәд асыл ватаннары булган Бохара шәһәренә кайтып вафат булды һәм Мөхәммәд бине Исмәгыйль дә хәдис-шәриф өйрәнү нияте белән Мәккәдә калды. 18 яшенә җиткәч, сәхабәләр һәм табигыйннар хөкемнәре хакында булган китабын төзеде. Мәдинәгә барып галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез хәзрәтләренең кабер-шәрифләре янында ай яктысында «Әт-тарих әл-кәбир» исемле хезмәтен язды.

Имам Бохари хәдис җыю һәм хөрмәтле шәехләрдән ишетү нияте белән ислам шәһәрләренә сәяхәт иткән, күп вакытлар Хорасан, Гыйрак, Шам, Хиҗаз, Йәмән, Мисыр кебек мәшһүр шәһәрләр һәм билгеле булган мәмләкәтләрдә йөргән, һәр җирдә бөек остазларның түгәрәккә утырып биргән дәресләренә кереп файда алган. Меңнән артык шәехләрдән хәдис-шәриф тыңлаганлыгы һәм сөйләгәнлеге риваять ителә, Әхмәд бине Хәнбәл, Яхъя бине Мәгыйн, Исхак бине Раһуя, Әбү Бәкер бине Әбү Шәйбә, Әбү Нәгыйм әл-Әсбаһани бу җөмләдән. Шуның белән бергә, «гамәл иманнан бер өлеш түгел» дигән ышануда булган кемсәләрнең хәдисләрен язмавын үзе хәбәр биргән. Чөнки Бохари: «Иман сүз белән гамәлдән гыйбарәт, шуның өчен [иманның] артуын һәм кимүен кабул итәм», – ди[92].

Имам Шафигый хәзрәтләреннән хәдис ишетсә дә, «Сахих»та аның риваяте юк. «Сахих»та ике урында булган Ибне Идрис дип әйтүе Габдулла әл-Әвәди әл-Куфи, диләр[93]. Язид бине Һарун, Әбү Давыт әт-Таялиси, Габдерраззак бине Һәммам әс-Сангани кебекләрнең заманнарына ирешсә дә, күчеп килүе беркадәр соңрак булганлыктан, алардан ишетә алмады, аларның хәдисләрен бер арадашчы белән риваять итә. Әгәр дә

---

хәзрәтләрен Ибне Хәзем шигый төзүчеләреннән санаган (Әл-фасыл. – Т. 1. – Б. 26).

[92] Җамигъ әс-сахих. – Т. 1. – Б. 7.

[93] Боларның берсе «Фи әр-рикяз әл-хумүс» бабында (т. 2, б. 137) һәм икенчесе «Тәфсир әл-гарая» бабында (Т.3. – Б. 33).

турыдан-туры үзләренә юлыкса, Бохари хәдисләре тагын бер дәрәҗәгә артык булыр иде.

Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани хәзрәтләре имам Бохари шәехләрен шушы биш төркемгә аера:

1) Табигыйннан риваять итүчеләр. Мөхәммәд бине Габдулла әл-Әнсари, Мәкки бине Ибраһим, Әбү Гасыйм ән-Нәбил, Габдулла бине Муса, Әбү Нәгыйм һәм башкалар бу төркемнән.

2) Бу беренче төркемнең замандашлары; фәкать табигыйннан риваять итү җиңел булмаган. Адәм бине Ияс, Әбү Мисһәр Габделәгъләә бине Мисһәр һәм башкалар бу төркемнән.

3) Табигыйн заманына ирешмәгәннәр. Сөләйман бине Хәрб, Кутәйбә бине Сәгъд, Нәгыйм бине Хәммад, Гали бине әл-Мәдьяни, Яхъя бине Мәгыйн, Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя һәм башкалар бу төркемнән. Бу төркемнән хәдис риваять итүдә имам Бохарига имам Мөслим дә иптәш.

4) Үзенең замандашлары һәм яшьтәшләре. Мөхәммәд бине Яхъя әз-Зөһли, Әбү Хатим әр-Рази, Габед бине Хөмед һәм башкалар бу төркемнән.

5) Үзенә шәкерт хөкемендә булганнар. Болардан исә аерым бер файда күренгән урыннарда риваять итә. Габдулла бине Хәммад әл-Амәли, Габдулла бине Әбү әл-Казый әл-Хаварезми һәм башкалар бу төркемнән. Имам Бохари үзенә шәкерт хөкемендә булган затлардан хәдис риваять итүе белән үзенең: «Үзеннән югарырактан, үзенә тиңнән һәм үзеннән түбәнрәктән хәдисләр язмыйча мөхәддис камил булмас», – дигән сүзләре белән раслаган.

Ифтирак [мөселманнарның 73 төркемгә бүленүе хакындагы] хәдиснең асылы булу-булмавы[94], булган тәкъдирдә дә, адашкан фиркалар кайсылары булуы мәкаләт һәм кәлям [динифәлсәфи юнәлеш] әһелләренә караган. [Моны да] туры аңлатырга тиеш булган имам Бохари хәзрәтләренең кәлям әһелләре тарафыннан адашкан фирка, дип хөкем ителгән мәзһәбләргә караган мөхәддисләрдән хәдис алуы мәгълүм. Хавариҗ мөҗтәһиде булган Гыймран бине Хаттан һәм

[94] Ифтирак (аерылган) хәдис иснад ягыннан дөрес түгел. Әл-фасыл. – Т. 3. – Б. 248.

башкаларның хәдисләре Бохари тарафыннан «Сахих»та чыгарылган[95].

Имам Бохариның дәрес мәҗлесендә һәрвакыт йөзәрләп укучысы булып, үзеннән укыган һәм хәдис риваять иткән шәкертләре җитмеш меңнән артык булуы риваять ителә. Алардан Мөслим бине әл-Хәҗҗаҗ, Тирмизи, Әбү Зөрга, Әбү Бәкер бине Хөзәймә кебек олуг мөхәддисләр дә бар иде. Иң соңгы вафат булган шәкерте Әбү Заһир Габдулла бине Фарис әл-Бәлхи булып, 346 елда вафат булган.

Имам Бохариның хәдис гыйлемендәге көче һәм сәләте, гыйлем өчен булган мәхәббәте һәм теләге гадәттән тыш булып, хәтеренә килгән нәрсәне кәгазьгә терки иде. Йокыга ятканнан соң, хәтеренә килгән нәрсәләрне язу нияте белән унбишәр тапкыр торып, ут яндырып, хәтердәгесен кәгазгә теркәве риваять ителә. Хәтереннән йөз мең сахих һәм ике йөз мең сахих булмаган хәдисне үзе сөйли торган булган. Имам Тирмизи: «[Хәдисләрнең] иснадларын, кимчелекләрен, тарихларын белүдә Гыйракта да һәм Хорасанда да имам Бохари дәрәҗәсендә бер адәм күрмәдем», – дигән булган.

Сәмәрканд шәһәрендә шул вакытларда дүрт йөз микъдарында хәдис галимнәре бар иде. (Бүгенге көндә Сәмәрканд шәһәрендә ничә йөз хәдис галиме бардыр, гаҗәп?!). Болар исә имам Бохарины ялгыштыру нияте белән җиде көн әзерләнделәр, Шам иснадларын Гыйрак иснадларына һәм Гыйрак иснадларын Шам иснадларына, шулай ук Хиҗаз иснадларын Йәмән иснадларына катыштырып (болай итүне хәдис галимнәре дөрес күрмиләр, бәлки, хәрам саныйлар), имтихан кылып сынадылар; фәкать өлешчә булса да, бер ялгышка төшерә алмадылар.

[95] Әбү Хәнифә хәзрәтләре шигыйлардан зәйдия фиркасының мөҗтәһиде мәшһүр Васыл бине Гатаның шәкерте булган имам Зәед бине Гали хәзрәтләреннән игътикад (ышану) һәм фикыһ гыйлемен алды. Шулай ук мөгътәзиләләр башлыгы булган Гамру бине Гобәйд «әһле сөннә» шәехе булган Хәсән Басрида гыйлем алды. Боларның һичберсе икенчесенең мәзһәбенә каршы чыгуы риваять ителми. Кәлям әһеле (икәне) билгеле булып та, бер-берсенә шик-шөбһәләр атмаганнар һәм ислам әһелләрен аермаганнар, элек булган хәлләр шул рәвештә дәвам иткән.

Багдад шәһәренә кергәч[96], бу шәһәрдә булган мөхәддисләр йөз хәдисне сайлап алып, мәтеннәрен һәм иснадларын алмаштырдылар (бу гамәл дә дөрес түгел). Арадан ун кеше сайланып, Бохаридан сорар өчен һәрберсенә унар хәдис билгеләделәр. Җирлеләрдән һәм читләрдән гыйбарәт булган зур бер җәмгыятьтә ун мөхәддис берәм-берәм үзләренә билгеләнгән унар хәдисне берәм-берәм укып, Бохарига тәкъдим иттеләр. Бохари һәрберсенең һәрбер хәдисе укылуына каршы: «Лә әгъриф» [«Мин моны белмим»], – дип җавап биреп торды. Багдад мөхәддисләренең үз араларында кайберләре: «Сизде», – дип, кайберләре: «Хәдистән хәбәре юк, имеш», – дип колактан колакка сөйләшәләр иде. Сораулар тәмамланганын белгәннән соң, имам Бохари йөз хәдиснең иснадларын берәм-берәм дөресләп укып чыккан. Шул вакытта бөтен халык аның дәрәҗәсе олы булуын таныганнар.

Басра шәһәренә баргач: «Әй, гыйлем әһелләре, шәһәребезгә Бохари килде», – дип төп мәчеттә чакыру булган һәм бу вакытта яшь егет булган имам Бохари мәчет эчендә бер стена артында намаз укый, имеш. Гыйлемгә мәхәббәте булган кешеләр дә янына килеп, түгәрәкләнеп тезләнгәннәр һәм язу мәҗелесе ясауны сораганнар. Бохариның хәдис мәҗлесенә меңнәрчә галимнәр җыелып, тыңлаганнар. Имам Бохари саф күңелле, ялагай булмаган, риясыз бер зат булганлыктан: «Миннән хәдис мәҗлесе таләп иттегез, мин бер яшь кемсәмен, шулай булгач, мин сезгә үз шәһәрегез мөхәддисләреннән сез ишетмәгән иснадлар белән хәдис риваять итәрмен», – дигән. Моңа исә шунда булучыларның кәефләре бозылмаган, тулы шатлык белән кабул иткәннәр. Рәсүл саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәдисләрен ихтирам итү һәм гыйлемне олылау шулай була. Гыйлем елга кебек, һичвакыт үз-үзләрен бөек һәм югары күргән затлар тарафына йөрмәс [акмас].

Имам Бохари диндар, тәкъва бер зат булып, ачу тотудан, көнчелектән пакь, югары дәрәҗә яратмый һәм мактану белән шөгыльләнми иде. Бөтен гомерендә гайбәт сөйләмәве риваять ителә. Багдад шәһәре ислам милләтенең мәркәзе булу белән һәм

[96] Имам Бохари Багдад шәһәренә сигез мәртәбә кергән.

әмирләрнең йогынтылары җиһанда өстен булса да, бер вакытта кат-кат Багдадка кереп, имам Бохари ни бер хәлиф, ни бер әмир капкасына барсын. Түгәрәккә утырып биргән дәресләре заманының бөек галимнәре белән тулы булып, Багдад шәһәрендә хәдис укытуда булган Бохариның Габбаси хәлифәләренә өлешчә игътибар бирүе хакында мәгълүмат тапмадык.

Имам Бохари ябык гәүдәле, урта буйлы, гадәттән тыш зиһенле һәм зирәк, хәтере куәтле булып, сабый булган вакытында җитмеш мең хәдис ятлавы риваять ителә. Бер мәртәбә уку белән ятлый торган булган. Аның бу хәлен белгән иптәшләре: «Бу адәм чиктән тыш бер камиллек иясе булачак, моннан өстен чыгарга һичкемнең кодрәтеннән килмәячәк», – дип үз араларында сөйләшәләр иде.

Атасы дәүләтле [бай] адәм булып, вафат булган вакытында күп мал мирасы калдырган. Имам Бохари да болар белән яшәп, фәкыйрь шәкертләргә яхшылык, ярдәм кыла һәм үзе кәнәгатьлек белән гомер сөрә торган булган.

**Хезмәтләре.** Имам Бохариның «Җамигъ әс-сахих»тан башка бу исемдәге хезмәтләре бар: «Әл-әдәб әл-мөфрад»[97], «Әсами әс-сәхабәт», «Бәдьү әл-мәхлукат», «Биррү әл-вәлидәйн», «Тарих әс-сикат вә әд-дугафәи мин рөват әл-хәдис», «Тарихү Бохара», «Әс-сөләсият», «Әл-җамигъ әс-сагыйр», «Әл-җамигъ әл-кәбир», «Хальку әфгаль әл-гыйбад», «Әл-фәваид», «Әл-кыйраәтү хальфә әл-имам», «Әл-күнә», «Әл-вөждан», «Әл-һибә», «Әл-мөснәд әл-кәбир», «Әт-тарих әл-кәбир», «Әт-тарих әл-әүсат», «Әт-тарих әс-сагыйр», «Әт-тәфсир әл-кәбир», «Әл-әшрибә», «Әл-мәбсут» һәм башкалар.

**Шигырьләре.** Имам Бохари шигырь сөйләмәгән яки бик аз сөйләгән. «Буш вакытыңның кадерен бел һәм намаз укы, бәлки, үлемең кинәт булыр. Күпме сәламәт кеше кинәт кенә дөньядан киткәнен күрдем» шигыре, шулай ук: «Кешеләр белән киң күңел белән мөгамәлә кор, кешеләргә карата эт булма» һәм

[97] Бу язманың бер нөсхәсе «Димәшкъ» китапханәләрендә булуы риваять ителә.

«Әгәр дә бөтен якыннарыңны югалту сиңа көтелмәгән хәл булса, үзеңне дә югалтудан курыкмассың, дип уйлыйм» шигырьләре югарыда күрсәтелгән хәзрәтләренекенә карый. Бохари шигырь сөйләмәсә, бу нәрсә үзенең моңа теләге булмаганлыктан. Чөнки шигырь сөйләү табигый бер куәткә ияреп, бу куәт һәрбер адәмдә булмас. Юкса, имам Бохари «Сахих»та бөек сәхабәләр тарафыннан сөйләнгән һәм галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез янында укылган шигырьләрдән берничәсен риваять иткән. Монда телгә алынган иң соңгы шигырен имам Сөбки Таграиның: «Берәү, яшьтәшләре аны узып киткәндә, әҗәленең кичектерелүен теләде» – дигән шигыреннән гүзәл [дип] санаган.

**Бер нәсыйхәте.** Әбү әл-Габбас әл-Вәлид бине Ибраһим бине Зәед әл-Һәмдани гыйлем алып адәм арасына кергәннән соң, хәдис гыйлеме белән шөгыльләнергә теләп, имам Бохари янына барып, үз максатын җиткергән. Имам Бохари аның сүзен тыңлаганнан соң: «Әй, улым! Һәрьяклап фикер йөртмәстән, файдаларын һәм нәтиҗәләрен тасвирламастан, тыю һәм мәшәкатьләренә көчең булу-булмавын яхшы белмәстән элек һич эшкә адым атлау дөрес түгел. Шуның өчен хәдис гыйлемен алу ниятең булса, бу турыда яхшы уйла!» – дигән. Моңа каршы Әбү әл-Габбас әл-Һәмдани: «Әй, мөхтәрәм остаз! Шулай икән, бу турыда миңа беркадәр булса да аңлатып бирегез, мин үземнең бу эшкә көчем булачагын-булмаячагын аңлыйм [белим], [бу] йөкләмәдән чыгачагым-чыкмаячагымны тикшерим!» – дип сораган. Имам Бохари шул вакытта аңа әйткән: «Шуны бел: дүрт нәрсәне дүрт нәрсә белән дүрт нәрсәгә тиң дүрт нәрсә белән дүрт нәрсәгә дүрт нәрсә вакытында дүрт нәрсә аша дүрт нәрсә өчен дүрт нәрсә турында дүртәү өчен язмыйча кеше чын мөхәддис була алмас һәм бу дүртлек дүрт нәрсә белән дүрт нәрсәсез тулы булмас. Алар тулы булгач, дүрт нәрсә шул кеше өчен җиңел булыр һәм ул дүрт нәрсә белән сыналыр. Әгәр дә шуңа сабыр итсә, Аллаһ бу дөньяда аны дүрт нәрсә белән хөрмәтләр һәм ахирәттә дүрт нәрсә белән бүләкләр».

Әбү әл-Габбас әл-Һәмдани бу сүзләрне ишетеп хәйран калган һәм аңлатмасын имам хәзрәтләреннән көтеп торган. Имам хәзрәтләре: «Әйе», – дип, шушы рәвештә аңлаткан: «Кеше аларны язарга мохтаҗ булган дүрт нәрсә: хәдисләр һәм аның рәсүл саллаллаһү галәйһи вә сәлләм шәригате; сәхабәләр һәм аларның дәрәҗәләре, Аллаһ алардан риза булсын; табигыйннар һәм аларның тоткан урыннары; бөтен галимнәр һәм аларның тарихлары, хәдис тапшыручыларның исемнәре, кушаматлары, яшәгән урыннары, заманнары. Болар хөтбә укыганда Аллаһны мактау, берәр нәрсә белән мөрәҗәгать иткәндә дога, сурә укыганда «бисмилла» сүзе, намаз укыганда тәкбир шикелле һәм балачакта, яшь чакта, картлык вакытында, буш һәм мәшгуль, ярлы һәм бай, тауларда, диңгездә, шәһәрләрдә, чүлләрдә чакта мөснәд, мөрсәл, мәүкуф, мәкътуг кебек. Ул язганнарын кәгазь битләренә күчерергә мөмкинчелеге барлыкка килгәнче аларны ташларга, тукыма кисәкләренә, тирегә, папируска төшерә башлаячак. Үзеннән югарырактан, үзенә тиңнән һәм үзеннән түбәнрәктән, язуы буенча башка кешенеке түгел, нәкъ менә атасыныкы икәнлегенә ышанып, атасы китабыннан тапшырачак. Аллаһка омтылып, Аның ризалыгын эзләп, Бөек Аллаһ китабына туры килгән нәрсәләрне үтәп, аларны үзеннән соң да саклап калу өчен укучылары, тарафдарлары арасында, хезмәтләре аша таратачак. Боларны ул бәндәләр казанышы булган дүрт нәрсә белән генә ирешә алачак, ягъни язу, гарәп телен, морфологиясен һәм синтаксисын белү. Аллаһ Тәгаләнең дүрт бүләге аша дигәндә, мин сәләтлелек, сәламәтлек, омтылыш һәм хәтерне күздә тотам. Кеше менә шуларга ирешкәч, аңа дүрт нәрсәне – гаилә, мал, балалар һәм ватанны калдыру җиңел булачак. Ул дүрт нәрсә – дошманнар мәкере, дуслар әрләве, наданнар гаепләве һәм галимнәр көнләшүе белән сыналачак. Әгәр дә бу сынауларны җиңеп чыкса, Бөек Аллаһ аны дүрт нәрсә – ризалык бөеклеге, үз-үзен хөрмәт итү, гыйлем аша ләззәтләнү, бәхетле тормыш белән хөрмәтләр. Ахирәттә Аллаһ Тәгалә дүрт нәрсә – теләсә кайсы кардәше өчен шәфәгать итү, башка бернинди дә күләгәле җир булмаган вакытта Үзенең тәхете күләгәсе астына алу, кемгә тели, шуны пәйгамбәр саллаллаһү

галәйһи вә сәлләм сулыгыннан эчертү, җәннәтнең иң югары дәрәҗәсендә пәйгамбәрләр белән бергә булу белән бүләкләр».

Моның соңында имам хәзрәтләре: «Озын гомерләрдә һәм төрле вакытларда остазларыбыздан һәм шәехләребездән алган нәсыйхәтләрнең иң яхшысын сезгә [сиңа] бәян иттем, инде үз хәлеңне тикшереп, шуңа таба хәрәкәт итәрсең», – дигән. Әбү әл-Габбас әл-Һәмдани әйтә: «Имам җәнапларының сүзен ишеткәч, бик тәэсирләндем, бу юлның авыр икәнен белеп, үземнең зәгыйфь калачагымны күңелемә китердем һәм аптырау дәрьясына чумып, тик утырдым, бу эшне булдыра алмауны белеп бик кечерәйдем. Имам [Бохари] хәлемне аңлаган булса кирәк, кабат сүз башлап: «Әй, газиз улым! Шундый мәшәкатьләрне күтәрергә көчең булмаячагын сизәрлек булсаң, фикыһ гыйлемен ал! Аны алу җиңел, хәтта өйдә утырган хәлдә дә мөмкин булыр, фикыһ гыйлемен шәехләр авызыннан ишетергә һәм моның өчен шәһәрләрдә, сахраларда йөрергә, чит җирләр сайларга мәҗбүрлек юк. Фикыһ гыйлеме дә гыйззәтле бер гамәл», – диде. Моннан соң мин хәдис гыйлемен алудан ваз кичтем, фикыһ гыйлемен укырга керештем һәм бу гыйлемнең беренче дәрәҗә галимнәре арасына кердем».

**Ялгышлары.** Никадәр бөек булса да, булсын, гөнаһсыз булмаган галимнәрнең хаталары һәм ялгышлары булуы мөмкин. Шундый ялгышларга ияреп башкалар да юлдан язмасыннар өчен сәләф галимнәре тарафыннан «җәрх вә тәгъдил» фәне төзелгән. Моның иң эшлекле булган хезмәт куючыларының берсе имам Бохари хәзрәтләре үзе иде. Югарыда күрсәтелгән хәзрәтләренең дә кайбер ялгышлары булган. Моңа мисал итеп, үз заманында кулланылган Тәүратны иңгән китаплардан һәм эзлеклелек белән сөйләнелгән, дип уйлап, моның хакында Коръән-шәриф риваять иткән [Тәүраттагы] үзгәрүләр һәм алмаштырулар бары тик ялгыш аңлату һәм аңлатуга караган нәрсәләрдә, дип кылган дәгъвасын китерәләр[98]. Бу дәгъваның ялгышка нигезләнүендә шөбһә юк. Кулларында булган китапларны иңгән китаплардан икәнлеген хәтта яһүдләр һәм

[98] Әл-мәнар. – Т. 6. – Б. 87.

нәсаралар үзләре дә дәгъва итмәгәннәр, бәлки, алар фикеренчә, бу китаплар рәсүлләр тарафыннан илһам белән язылган. Боларның эзлеклелек белән сөйләнелгән булу-булмавы хакында күп сүзләр бар[99].

**Имам Зөһли белән булган вакыйгасы.** Шәһәрләренә килгәнен ишетеп, Нисапур халкы ике-өч туктап хәл җыю урыны кадәр җиргә имам Бохари каршысына барган. Нисапурның башкалардан аерылып торган галимнәреннән булган Мөхәммәд бине Яхъя бине Габдулла әз-Зөһли[100] һәм башкалар шул [Бохарины] кабул иткәннәр арасында булалар иде. Имам Зөһли үзенең шәкертләренә: «Арабызда дошманлык һәм күңелсезлек төшмәсен өчен Бохари белән бәхәсләшмәгез!» – дип кисәтү булса да, ике-өч көн үтмәде: «Әгәр язмыш килсә, киң җир дә тар кала» дигәндәй, Зөһли шәкертләренең берсе Бохаридан кешеләр гамәлләре һәм «халькы Коръән» [Коръән бар ителгәнме-юкмы] мәсьәләләренә караган сүз сорый. Бохари тарафыннан бирелгән җавап хакында халык ике төркем булып үзара бәхәскә керешәләр. Шул хәл сәбәпле, Зөһли белән Бохари арасына суыклык, күңелсезлек төште һәм мәхәббәт белән кабул итеп алынган Бохари хакында имам Зөһли: «Кем моннан соң Бохари янына барса, аның белән сөйләшмибез», – дип игълан итте. Бу вакытта Бохари да Нисапурны ташлап чыгып киткән. Шулай булса да, Бохари имам Зөһлидән риваять иткән булган

---

[99] Фәхреддин әр-Рази да Тәүрат эзлелелек белән күчерелгән булуын һәм үзгәртү максатыннан сүзләрне чын мәгънәләреннән читләштерүне кабул иткән. Мәфатих әл-гаеб. – Т. 3. – Б. 236. Ибне Хәзем бу сүзне каты тел белән кире кагуда. Әл-фасыл. – Т. 1. – Б. 215.

[100] Имам Зөһли хәдис гыйлемендә хөрмәтле бер кемсә булып, Шәйхелислам Хафиз Нисапур кебек олуг урыннар белән танылган булган иде. Әбү Дауд әт-Таялиси һәм Габдерраззак кебек затлардан риваять итә. Хәдис гыйлемен алу нияте белән Хәрәмәйн (Мәккә, Мәдинә), Шам, Мисыр, Гыйрак, Рай, Хорасан, Йәмән һәм Җәзирә вилаятьләрендә сәяхәт иткән. Мөслим искәрмә булган хәлдә, «Көтебе ситтә» төзүчеләре аннан хәдис риваять итәләр. Шәкерте күп, бик намуслы һәм чиста кемсә булып, үзен Әхмәд бине Хәнбәл ихтирам итә иде. Тууы 190 ел ахырында булып, вафаты имам Бохаридан соң 258 елда булган.

30га кадәр хәдисне «сахих»тан чыгармаган, бәлки, «безгә Мөхәммәд бине Яхъя әз-Зөһли сөйләде» диячәк җирдә «безгә Мөхәммәд сөйләде» яки «безгә Мөхәммәд бине Габдулла сөйләде» дип фәкать исемен генә бирә яки атасы исеменә бабасы исемен әйтү белән чикләнгән. Бохариның саф күңелле адәм һәм гыйлемгә җинаять эшләү дөрес түгел, дигән ышануда булганлыгына бу хәле дәлил булса кирәк.

**«Халькы Коръән» [Коръән бар ителгәнме-юкмы] мәсьәләсе.** Ислам дөньясының иң яхшылары, сәләф галимнәренең каймагы булган иң ышанычлы кешеләрнең бәхетсезлекләренә, көчләре җитмәслек нәрсәләрдән булган мәшәкатьләр, зәхмәтләр таратуларына сәбәпче булган бу «халькы Коръән» мәсьәләсе нинди мәсьәлә? Безнең бу хезмәтебезне түгел, хәтта ки имам хәзрәтләренең нинди җирдә булса да, булсын, тормыш юлларын укучыларның һәрберсенең күңелендә шундый бер сорау туачагында шөбһә юк. Шуның өчен без бу мәсьәләнең асылын бу җирдә бәян итәчәкбез.

Коръән сүзе шушы нәрсәләргә әйтелә:

1. Кәлям нәфси әзәли. Бу мәгънә белән Коръән Хак Сөбханәһү вә Тәгаләнең заты белән бар булып торучы һәм «ул да түгел, башкасы да түгел» дип әйтелүдә булган хакыйкый сыйфат җөмләсеннән була. Бу мәгънә белән Коръән хакында булган низаг «әһле сөннә» белән «мөгътәзилә» арасында. «Мөгътәзилә»ләр мондый сыйфатны инкяр иткәннәре хәлдә, «әһле сөннә» [сөнниләр] исбат иткән. Исбат итүчеләр каршында бар ителмәгән булуында шөбһә юк. Әгәр дә «мөгътәзилә»ләр сыйфат белән әйтүче булсалар, әлбәттә, бу мәгънә белән Коръәннең бар ителмәгән булуы хакында «әһле сөннә»гә туры килгән булырлар иде.

2. Укылуда булган язылган сүзләр, кушылган хәрефләр, шулай ук хәреф ясалган битләр. Бу мәгънәдә булган Коръәнгә шәригать телендә «китап» һәм «мосхәф» дип атала.

Сәләф галимнәренең җәфалануларына сәбәп шул икенче мәгънәдә булган Коръән низагы торган. Моның билгеләнгән, күренеш булуын инкяр итмәгән хәлдә шәригать тарафыннан

боеру булмаган, шундый нәрсәләр гасры сәгадәттә юк иде, шуның өчен бу бәхәс бидгать [дингә кертелгән яңа нәрсә] дип, галимнәр [Коръән –] «мәхлук» [бар ителгән] сүзен әйтүдән сакланганнар. Әмма икенче тарафта Маэмун хәлифә беренче мәгънәсе белән Коръәнне инкяр итмәгән хәлдә (Маэмун белән «мөгътәзилә»ләр арасында булган аерма шул ноктада) ахыргы мәгънәсе белән Коръәнне «мәхлук» дип әйтү хакында галимнәргә боерган. Галимнәр: «Кирәге юк, шәригать боерыгыннан түгел, бәлки бидгать бер бәхәс», – дип моңа бөтен көчләре белән каршы торганнар, Маэмун боларның бу хәлләрен «Болар ахыргы мәгънәсе белән Коръәнне борынгырак, диләр, имеш, бу исә Аллаһ Тәгаләдән башкага алдарак булуны исбат итү була», – дип аңлап, үз сүзендә нык торган һәм галимнәргә төрле рәхимсезлекләр күрсәткән. Маэмун кебек галим һәм аңлаучы адәм мәсьәләнең олы түгеллеген белеп, галимнәр белән аңлашырга тиеш иде. Фәкать һәрвакыт моның кебек өлешчә низагларны үзләренчә аңлаучы төрле юнәлешләрдә булган төркемнәрнең кулланулары сәбәпле, зурая-зурая мондый гомуми хөкеменә керә. Коръәннең бар ителүе мәсьәләсе дә шул рәвештә зурайды һәм күпләрнең бәхетсезлекләренә сәбәпче булды.

Вакыйганың мәйданга килүенә шул юл булган: бик матур сүзле һәм кәлям әһелләре имамнары дигән кадәр бу фәндә оста булган казый Әхмәд бине Әбү Дуад Маэмун янында якыннарыннан булып сүзе үтә һәм яклаулары кабул ителә иде. Һәрбер форсат чыкканда Маэмун янында Коръән-шәрифне бар ителгән дип ышандыру максаты белән халыкны моңа чакырырга кирәклеген сөйләгәннән соң, Маэмун күңеле моңа карар тапты һәм бу турыда кайбер әмирләргә 218 елда указ язды. Багдад галимнәреннән күпләр җаннары, гаиләләре өчен куркып Маэмун боерыгын кабул иттеләр. Үз сүзләрендә нык булган галимнәрне Багдад вәлие булган Исхак бине Ибраһим богаулатып, Маэмун янына җибәрде. Болар барып җитмәстән элек Маэмун вафат булып, Тарсус шәһәрендә җирләнде. Маэмун үзенең васыятьнамәсендә мөселманнарны Коръәннең бар ителүе өчен чакыру хакында әйткән. Әл-Мөгътәсыйм хәлифәлек тәхетенә утыруы белән бу мәсьәләгә керешеп, сүзен кабул итмәгән өчен

үз янында Әхмәд бине Хәнбәлне камчы белән суктырды. Янында булган кайбер муллалар Әл-Мөгътәсыймга: «Бу бәдбәхетне үтер, ахирәттә җавапны без бирербез», – дип кыздырып торалар иде. Бөтен тәне һәм киеме канлы булган хәлдә күтәреп алып чыгулары риваять ителә. Бөек галимнәрдән булган Әхмәд бине Наср әл-Хузагый хәзрәтләрен шул мәсьәлә хакында хәлифә әл-Васикъ: «Аллаһ ризасы өчен бу кәферне үз кулым белән үтерергә кирәк», – дип кылыч белән башын чабып алган һәм башын Багдадка җибәреп, халык күзе уңында астырып куйган. Шулай ук Мөхәммәд бине Нух бине Мәймун исемле кемсәне Әхмәд бине Хәнбәлне [җәзалаган] шикелле камчы белән суктырдылар. Нәгыйм бине Хәммад богауланып яткан хәлдә зинданда вафат булды. Бу фетнә 234 елга кадәр дәвам итте. Әл-Мөтәвәккил хәлифә бу турыда указлар язып, Коръәннең бар ителүе хакында булган боерыкларны гамәлдән чыгарган һәм, шул сәбәпле, уртада [ике арада] булган фетнә басылган.

Имам Бохари никадәр яшь булса да, бу низаг кайнап торган вакытларның соңгы сәгатьләренә җитешкән. Аерым алганда, остазы Әхмәд бине Хәнбәл хәзрәтләре вакыйгасын кешедән ишетеп белгән иде. Нисапур шәһәрендә «Коръән белән сүзебез бар ителгәнме?» сорауларына каршы имам Бохари җавап бирмичә ике тапкыр дәшмичә калса да, өченче мәртәбәсендә: «Безнең гамәлләребез бар ителгән һәм безнең сүзләребез безнең гамәлләребездән», – дигән мәгънәдә бер җавап сөйләгән. Имам Зөһли исә, Әхмәд бине Хәнбәл шикелле бу турыда сүз сөйләүдән саклануы сәбәпле, имамның бу сүзләрен «Минем Коръән белән әйтелгән сүзем бар ителгән» дигән мәгънәсендә уйлап, шундый сүзгә керешүенә риза булмаган, моның нәтиҗәсе буларак аралары бозылган. Юкса, имам Зөһли хәзрәтләренең авызыннан чыккан сүзләргә «бар ителмәгән һәм беренчел» дип хөкем итүе сурәтләнми. Имам Бохари өченче тапкыр сорауга да җавап бирмәгән сурәттә мәҗлес әһелләре үзе хакында шундый гаепләүдә булачакларын уйлап, мәҗбүри сурәттә телгә алынган җавапны биргән. Юкса, моннан максаты «мөгътәзилә»ләр шикелле сөйләшү һәм алар мәзһәбенә ярашу булмаган. Бохари белән Зөһли вакыйгасын шундый рәвештә

белергә, бу турыда моннан башка рәвештә язылган хәбәрләргә сукырларча ышанмаска кирәк. Мәсьәлә мөһим булган кадәр нәзек, игътибарсыз булма.

Сәләф галимнәре Хак Сөбханәһү вә Тәгалә хәзрәтләре хакында «һәр нәрсәне бар итүче» дип хөкем иткән хәлдә, «дуңгызларны бар итүче» дип әйтүдән саклаunion аналар. Моннан максатлары исә дуңгызны бар итүен инкяр итү түгел, бәлки, әдәпкә һәм тәрбиягә игътибар итү өчен шулай эшлиләр. «Кәлям» сүзе хакында «мәхлук» сүзен атаудан саклануларыда бу нәрсәдән. Юкса, моннан максатлары, Аллаһ сакласын, «бар ителмәгән» дип әйтү түгел. Бер нәрсә хакында дәшми тору кире кагу яки исбатлау белән хөкем итү түгел.

**Соңгы көннәре.** Имам Бохари Нисапурдан чыгып, Бохара шәһәренә кайтуында икенче бер бәхетсезлеккә очрады. Гадәттә, хәсрәтләр һәм бәлаләр бер-берсе артыннан киләләр. Хорасан әмире Халид бине Әхмәд бине Халид әз-Зөһли фәкать үз балаларына дәрес бирдерү һәм балаларына тәрбияче, мөгаллим сыйфатында тоту нияте белән имам Бохарины чакырды. Бохари исә гыйлемлекне тик әмир балаларына гына түгел, бәлки, гомуми тарату ниятендә булуын бәян итеп, әмир чакыруын кире кага. Шул сәбәпле, әмир Бохара шәһәрендә булган галимнәрдән ярдәм сорап, Бохарига каршы хәрәкәт итәргә керешә. Бохара галимнәреннән имамга яла ягтырып һәм мәзһәбен хурлаучылар ярдәме белән әмир имам хәзрәтләрен Сәмәрканд янында булган Хартәнк авылына сөрде[101]. Бу авылга килүе белән Бохари Әбү

[101] Телгә алынган әмир Халид галим бер зат булып, Бохара вәлие булган хәлдә, хафизләрнең (яттан белүчеләрнең) түгәрәккә утырып биргән дәресләренә йөреп, хәдис тыңлый иде. Атасы Әхмәд бине Халид, Исхак бине Раһуя кебек шәехләрдән гыйлем алды һәм үзеннән дә Әбү Хатим әр-Рази һәм башкалар хәдис риваять итте. Шул сәбәпле, әмирнең Бохари хакында булган бу мөгамәләсе гыйлем кадере белмәгәнлегеннән түгел, бәлки, күктән төшкән афәт шикелле булган хурлык, дип санаган. Пакьлек фәкать бер Аллаһта гына. Хартәнк сүзендә «ха» һәм «тә»ның өсте, «ра» һәм «нүн» сәкене һәм «кәф» гарәпчә белән. Ноктасыз «х» белән язылуының сәбәбе безгә мәгълүм булмады.

Мансур Галиб бине Җәбраил әл-Хартәнки йортына тукталуы белән, аз көннәрдән соң вафат булды.

Бохара шәһәрендә булган дуслары, иярченнәре, хәтта якыннары, шәкертләре, дошманнары элемтәләрен, мөнәсәбәтләрен кисүләреннән, дөньяда һичбер хәерлесен һәм зарын, ялваруын сөйләр адәм дә калмавын күреп, имам хәзрәтләре дөньядан, тормыштан бизеп, җанын алу өчен Хак Сөбханәһү вә Тәгалә хәзрәтләренә ялваруы риваять ителә.

Имам Бохари 256 елда Ураза гаете кичәсе ястү намазыннан соң вафат булып, гает көнне өйлә намазыннан соң җирләнде. Яше 62дә иде. Ир баласы калмады. Нәгый ирештергәнчә, Хафиз Габдулла әд-Дарими хәзрәтләре Бохариның үз бәете булган ди, «Әгәр дә син яшәсәң, бөтен туганнарың үлеп бетәр, кешенең мәңге яшәве аннан да фаҗигалерәк» дигән сүзләр белән мәкаль китергән. Кабере Сәмәрканд шәһәреннән ике таш аралыгында (һәр таш арасы якынча 8–16 чакрым була) Хартәнк исемле урында икәнлеге билгеле[102]. Бу каберлеккә Сәмәркандтан барганда Зәрафшан елгасы бер-ике тапкыр кичелә. Каберлек тарафларында башка бер каберлек юк, өстенә бер мәчет төзелсә дә, елы һәм исеме язылган таш юк, диләр. Аллаһ аннан риза булсын, туфрагын җиңел кылсын, мәңгелек урынын җәннәт итсен!

---

[102] Уфа шәһәрендә торган вакытта 1314 елның мөхәррәм аенда Бохара тарафыннан сәяхәт итеп килгән булган Сәед Мөхәммәд Гали әз-Заһир әл-Ватри хәзрәтләреннән Мәрьям бинте Тимерпулад йортында имам Бохари каберлеген сораштым. Бу мәҗлестә шәһәр галимнәре һәм түрәләре бар иде. Күп җентекләп аңлатты һәм сүз арасында: «Гадәттән тыш гаҗәпләндем, Төркестан һәм Мәвараннәһер халкы имам каберлеген харап итеп барган хәлдә, аның хезмәтчесе булуыннан мәхрүм булган фәлән кемсә каберен падишаһ сарае шикелле төзекләндергән, диде. Уйлавымча, хәдис гыйлеменә хезмәте бәрәкәтендә булса кирәк, Хак Сөбханәһү вә Тәгалә имам Бохари каберлеген гыйбадәт урыны сыйфатында тоту һәм сәҗдә кылыначак пот булу афәтеннән саклаган. Шул сәбәпле, табигый, ташланмас.

## Имам Мөслим

Хәдис имамнарының олугларыннан булган Мөслим Әбү әл-Хөсәен бине әл-Хәҗҗаҗ бине Мөслим әл-Кушәйри 206 елда Нисапур (Нишапур) шәһәрендә дөньяга килде. Яхъя бине Яхъя әл-Нисапури, Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя, Габдулла бине Мәсләмә әл-Кагнәби кебек имамнардан хәдис-шәриф тыңлаганнан соң, бу гыйлеменә тагын күбрәк ныклык бирү максаты белән Гыйрак, Шам һәм Мисыр вилаятьләренә сәфәр кылды. Багдад шәһәренә кергәч, хәдис-шәриф укытты. Багдадта иң соңгы мәртәбә [әйткән] сүзе 259да иде. Үзеннән Әбү Хатим әр-Рази, Әбү Гайсә әт-Тирмизи, Әбү Бәкер бине Хазимә һәм башкалар хәдис тыңлаганнар. Нисапур шәһәренә килгән вакытында имам Бохаридан гыйлем алса да, «Сахих»та югарыда телгә алынган Бохариның исеме һәм аннан хәдис риваяте юк. Бохарига булган мәхәббәте һәм ихласлыгы сәбәпле, аның белән араларына авырлык төшкән булган Мөхәммәд бине Яхъя әз-Зөһли белән бозышып, мәҗлесеннән чыкты һәм гомере буе тыңлаган хәдисләрен бер кешегә йөкләп, үзенә кире кайтарды, диләр.

Имам Мөслим Шафигый мәзһәбендә булып, бу турыда нык иде. Шафигый мәзһәбенә каршы килми һәм мөмкин кадәр аны яклый иде. Әмма имам Бохари Шафигый мәзһәбендә булса да, күп урында аңа каршы килә[103].

Имам Мөслим хезмәтләре («Сахих»тан башка) шулар: «Китаб әл-әсма вә әл-күнә»[104], «Китаб әл-гыйләл», «Китаб әл-вөҗдан», «китабү Гамри вә Ибне Шөгаеб», «Китабү мәшаехи Мәлик», «Китабү мәшаех әс-Сәүри», «Китабү мәшаехи Шугбә», «Китабү мән ләйсә ләһү иллә равин вахид», «Китабү әүлад әс-сәхабә», «Китабү әүһам әл-мөхәддисин», «Китаб әт-табәкат», «Китабү әфрад әш-шамиййин» һәм башкалар.

---

[103] Бу сүз Шафигый галимнәренең хезмәтләреннән алынды, болар исә бөтен дөньяга галимне шафигый итү хакында көч куюлары җәһәте белән сүзләренә ышану мөшкел. Бохари һәм Мөслим кебек затларның мәзһәбләргә иярүләре, үзләре танымаса һәм аңлатмаса, расланмый.

[104] Бу китаптан язма бер нөсхә бүгенге көндә Димәшкъ китапханәләрендә булуы риваять ителә.

Имам Мөслим 55 яшендә 261 елның рәҗәб аенда Нисапур шәһәрендә вафат [булды] һәм Насрабад исемле урында җирләнде. Төрбәсе мәгълүм.

## Имам Әбү Дауд

Мәшһүр мөхәддисләрдән булган Әбү Дауд Сөләйман бине әл-Әшгас бине Исхак бине Бәшир бине Шәддад бине Гамру бине Гыймран әл-Әзди әс-Сиҗистани 202 елда Басра шәһәрендә дөньяга килгән. Ерак бабасы булган Гыймран Сыйффин сугышында хәзрәти Гали тарафында булганлыгы риваять ителә.

Хәдис гыйлемен алу өчен гайрәтен, гомерен сарыф итеп, күп җирләрдә сәяхәт итте. Әхмәд бине Хәнбәл, Яхъя бине Мәгыйн, Габдулла бине Мәсләмә әл-Кагнәби һәм башкалардан файда алды. Үзеннән дә күп кемсә риваять иткән. Бу җөмләдән, үзенең улы Әбү Бәкер Габдулла[105], имам Нәсаи һәм башкалар. Бу кемсәне шәех Әбү Исхак әш-Ширази «Табәкат әл-фөкаһаэ» исемле китабында Әхмәд бине Хәнбәл иярченнәреннән санаган.

Имам Әбү Дауд гаять изге һәм тәкъвалы бер зат булып, әдәби кыюлыкка ия иде. Заманының әмире булган Әбү Әхмәд әл-Мөваффак: «Әмир баласы гади кеше баласы белән бергә гыйлем алмас, шуның өчен минем балаларыма аерым сурәттә «сөнән» (хәдисләр) укыт!» – дип әйткәч, Әбү Дауд: «Бу нәрсә булмас, гыйлемдә әмирлек, гади катламлылык юк», – дигән.

Үзеннән: ««Сөнән»дә 4800[106] хәдис җыйдым, болар эчендә диннәре өчен адәм улларына бу дүрт хәдис-шәриф җитә: 1) Дөреслектә, гамәлләр ният белән хисапланыр. 2) Кирәкмәгән эшне калдыру исламның күркәмлегеннән. 3) Мөэмин, үзенә яратканны башка дин кардәше өчен дә яратмаса, чын мөэмин булмас. 4) Дөреслектә, хәләл дә, хәрам да билгеле», – дип әйтүе риваять ителә.

---

105 Бу зат үзе дә бөек мөхәддисләрдән булып, «Әл-мәсабих» исемле китап төзеде һәм 316да вафат булды.

106 «Дүрт мең сигез йөз» дигән җирдә ялгыш «Кәшф әз-зонун»да «дүрт мең һәм сигез йөз хәдис» рәвешендә басылган. Т. 2. – Б. 34.

**Хезмәтләре:** «Әл-мәрасил», «Әр-раддү галә әл-кадәрия», «Ән-насиху вә әл-мәнсух», «Фәдаил әл-әнсар», «Мөснәдү Мәлик бине Әнәс», «Әл-мәсаил», «Мәгърифәт әл-әүкат», «Мә тәфәррадә биһи әһлү әл-әмсар» һәм башкалар.

Имам Әбү Дауд хәзрәтләре 73 яшендә 275 елда шәүвәл ае уртасында җомга көн Басрада вафат булды. «Сиҗистан» сүзе «с» һәм «җ»ның асты (кәсрәсе), «с» һәм «т»ның фәтхәсе белән билгеле булган бер вилаять.

## Имам Нәсаи

Имам Нәсаиның күньясе Әбү Габдрахман һәм исеме дә Әхмәд бине Гали бине Шөгаеб ән-Нәсаи. Бу хәзрәтләре мәшһүр хафиз һәм мөхәддисләрдән булып, Хорасанда Нәсаэ шәһәрендә 215 елда дөньяга килгән иде. Исхак бине Раһуя, Юныс бине Габделәгълә, Әбү Дауд әс-Сиҗистани, Сөләйман бине Әшгас кебек хәдис имамнарыннан хәдис тыңлады һәм хәдис-шәриф уку теләге белән провинцияләрдән провинцияләргә сәяхәт итте. Үзеннән Әбү әл-Касыйм әт-Табарани, Тахави, Ибне әс-Сөнни кебек бөек затлар риваять иткәннәр. Хәтере куәтле булуы буенча, имам Нәсаины имам Мөслим бине әл-Хәҗҗаждан да өстен күрәләр. «Җәрех һәм тәгъдил» хакында имам Нәсаи сүзләре кабул ителә һәм шәһадәте игътибарлы, диләр. Шафигый мәзһәбенә карый иде, шуңа нигезләнеп «Мәнасик әл-хаҗ» китабын язуы риваять ителә.

Имам Нәсаи Мисырда торуы сәбәпле, хезмәтләре шунда таралды һәм бик күп затлар да Мисырда үзендә [Нәсаида] укыганнар. Гомеренең ахырында 302 елда Мисырдан чыкты һәм Димәшкъ шәһәренә барды. Димәшкъта хәзрәти Гали һәм гаиләсе фазыйләтләре хакында «Әл-хасаис» исемле китап төзеде. Монда булган риваятьләренең күбесе Әхмәд бине Хәнбәл хәзрәтләреннән. Үзеннән: «Димәшкъ шәһәренә кергәч, бик күп яшәүчеләрнең хәзрәти Гали хакында зәгыйфь һәм яраксыз ышануда булуын күрдем, Аллаһ Тәгалә һидәять [туры юл] бирмәсме, дип, бу «Әл-хасаис»ны төзедем», – дип сөйләгән

булган. Телгә алынган «Әл-хасаис» китабы 41 биттә 1308дә Мисырның Каһирә шәһәрендә басылды.

Имам Нәсаи канәгатьле һәм динле бер адәм булып, бөтен гомерен бер көн ураза һәм бер көн ифтар итү белән [ураза тотмыйча] кичерде, солтан һәм түрәләр мәҗелесендә катнашудан гаять саклануы риваять ителә.

**Хезмәтләре:** «Мөснәд Гали», «Мөснәд Мәлик», «Әл-күнә», «Гамәл әл-яүми вә әл-ләйлә», «Әсмаэ әр-руваһ», «Мә әгърәбә Шөгъбә Гали Суфьян вә Суфьян Гали Шөгъбә», «Мөснәд Мансур бине Зазан» һәм башкалар.

Димәшкъ мәчетендә бөтен халык янында үзеннән Мөгавия фазыйләте хакында сүз сорадылар. Имам Нәсаи да: «Мөгавия башыма баш корытылса, бәхетледер, фазыйләте нинди җирдә?!» – дип җавап биргән. Бу вакытта Мөгавия тарафдарлары өстенә һөҗүм итеп, мәчеттән чыгарганнар һәм кыйнап, өстенә менеп, каты таптаганнар, моның тәэсире белән вафат булган. Бер риваятькә караганда, вафат булудан элек үзенең үтенүе буенча, якыннары Мәккәгә алып барган һәм шунда Сафа белән Мәрвә арасында җирләнгән булган. Вафаты 303 елның шәгъбан аенда.

## Имам Тирмизи

Имам Тирмизинең күньясе Әбү Гайсә һәм исеме дә Мөхәммәд бине Гайсә бине Сәүрә бине Муса бине әл-Даххакь әс-Сәлми (Әнсар кабиләсеннән булган Бәнү Сәлмәгә караган). Мәшһүр хафизләреннән һәм хәдис гыйлеменең имамнарыннан булып, 209да дөньяга килде. Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Бохари белән иптәш буларак гыйлем алса да, соңыннан, Бохарига шәкерт булып, аннан алды. Шуңа карамастан, имам Бохари аңа: «Синең миннән файдаңа караганда минем синнән булган файдам күбрәк», – дип әйтә торган булган.

Имам Тирмизи Әхмәд бине Хәнбәл белән Исхак бине Раһуя мәзһәбләренә караган булса да, чынлыкта, һичберсенең мәзһәбендә булмады, бәлки, үзе, һичшиксез, мөҗтәһид булган.

**Хезмәтләре:** «Әл-гыйләл», «Әт-тарих», «Әз-зөһед», «Шәмаил ән-нәби», «Әл-Әсмаү вә әл-күнә» һәм башкалар. «Шәмаил» төрле урыннарда берничә тапкыр басылды.

Имам Тирмизи хәтере куәтле булуы белән танылган иде. Гомеренең ахырында күзләре сукырайды һәм сукыр хәленчә һаман да үзенең хезмәтен давам итте. 289 елның рәҗәб аеның 13 нче көнендә вафат булган.

## Ибне Маҗә

Мәшһүр мөфәссирләрдән [Коръәнгә аңлатма язучылардан], хафизләрдән һәм мөхәддисләрдән булган бу имамның исеме Мөхәммәд бине Язид бине Маҗә, күньясе Әбү Габдулла булып, нисбәте [берәр урынга карап исем ясалуы] – Казвини.

Ибне Маҗә Казвин шәһәрендә 209 елда дөньяга килде, Мөхәммәд бине Габдулла бине Нөмәер, Ибраһим бине әл-Мөнәззир әл-Хәрами кебек мәшһүр мөхәддисләрдән хәдис тыңлады һәм хәдис гыйлеме алу нияте белән, Рай, Багдад, Басра, Куфә, Шам, Мәккә, Мисыр шәһәрләренә сәяхәт итте. Имам Мәлик шәкертләренә юлыгып, иптәш булды һәм алардан файда алды.

Ибне Маҗәнең хәдис гыйлемендә озын куллы булуы кебек, тәфсир гыйлеме белән дә шөгыльләнгән һәм Корьән-шәрифкә бер тәфсир язган. «Казвин тарихы» һәм башка исемдә төзегән хезмәтләре бар.

«Маҗә» «җ»ның кыскартылуы белән «хаҗә» формасында, атасы Мөхәммәд бине Язиднең күньясе һәм бер риваятькә караганда, үз анасының исеме иде.

Ибне Маҗә 64 яшендә 273 елның рамазан аенда вафат булды. Җеназасын туганы Әбү Бәкер укып, шул Әбү Бәкер, икенче туганы Габдулла, үзенең улы Габдулла һәм башкалар белән бергә җирләделәр[107].

[107] Аның вафаты Гасыйм әфәнденең «Укъянус»та, «Таҗ әл-гарус»ның типография хатасына ияреп, 293 елда дип күрсәтелгән. Т. 1. – Б. 830.

# XVIII

## «Көтебе ситтә» җыентыклары

Кабатланган хәдисләрне төшерү һәм төзелешләрен үзгәртү сәбәпле, кыскартып, «Көтебе ситтә»нең кайберләрен, кайвакыт җөмләләрен җыеп, бер китап рәвешендә хезмәтләр бар. Бу җөмләдән, шушы хезмәтләр билгеле:

1. **«Әл-җәмгу бәйнә әс-сахихайн».** Бу исем белән Бохари һәм Мөслим «сахих»ларын җыючылар шушы затлар:

1) Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Әбү Наср әл-Хәмиди әл-Әндәлүси (488). Аңа берничә шәрехләр һәм хашияләр (аңлатмалар) язылган.

2) Әбү Мөхәммәд Хөсәен бине Мәсгуд әл-Бәгави (516).

3) Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Габдулла ән-Нисабури (388).

4) Әбү Мөхәммәд Габделхак бине Габдрахман әл-Ишбили (582).

5) Әбү Мөхәммәд Исмәгыйль бине Әхмәд Ибне әл-Фөрат әс-Сәрахси әл-Һәрави (414).

6) Әбү Җәгъфәр Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Куртуби Ибне Әбү Хөҗҗә (642).

7) Әбү Бәкер Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Бәркани (425).

8) Әбү Мәсгуд Ибраһим бине Мөхәммәд бине Гобәйд әд-Димәшкый (401).

Әбү әс-Сәгадәт Ибне әл-Әсир бу китаплар арасыннан Хәмиди төзегәнен өстен күргән.

2. **«Тәҗрид әс-сыйхах әс-ситтә».** Бу исем белән Әбү әл-Хәсән Разин бине Мөгавия әл-Габдәри әс-Сәракустый (535), «Әл-мөватта»ны кертеп, («Сөнән Ибне Маҗә»дән башка) «Көтебе ситтә»нең җыентыгы белән бергә төзегән.

3. **«Җамигъ әл-ысул лиәхәдис әр-рәсүл».** Әбү әс-Сәгадәт әл-Мөбарәк Ибне әл-Әсир Мәҗдеддин (606) тарафыннан шул исем белән Разиннең «Тәҗрид әс-сыйхах әс-ситтә» исемле китабы белән бергә «Көтебе ситтә» төзегән. Ибне әл-Әсир бу хезмәттә, башкаларда артык бер [нәрсә] бәян итү һәм файда

күренмәгән сурәттә, Бохари белән Мөслим гыйбарәләренә төп игътибар биргән[108]. «Җамигъ әл-ысул»ның күп затлар тарафыннан кыскартылганлыгы риваять ителә.

4. **«Җамигъ әл-мәсанид».** Гыймадеддин Әбү әл-Фида Исмәгыйль бине Гомәр Ибне Кәсир әл-Басри әд-Димәшкый[109] тарафыннан төзелгән бу хезмәттә «Көтебе ситтә» белән дүрт «мөснәд» тә җыелган.

5. **«Җәмгъ әл-җәвамигъ».** Сөютый (911) тарафыннан бөтен хәдис китапларын бер җиргә җыеп төзегән. Тәмамлавыннан элек вафат булуы һәм, шул сәбәпле дә, төзәтелергә һәм яңадан каралырга тиеш булганлыктан, зәгыйфь, бәлки, мәүдуг (ялган) хәдисләр калуы риваять ителә. Мөттәкый Галәведдин Гали бине Хисамеддин әл-Һинди (975) бу китапны «Кәнз әл-гоммәл фи сөнән әл-әкъваль вә әл-әфгаль» исеме белән икенче рәвештә төзегән.

[108] «Мишкят әл-Мәсабих»тә һәрвакыт телгә алынган «Җамигъ әл-ысул» – бу хезмәт.

[109] Бу кемсә тормыш юлында «Камус әл-әгълям» иясе «Даирәт әл-мәгариф»кә иярүе сәбәпле булса кирәк, Гыймадеддин Әбү әл-Фида Исмәгыйль бине Гали белән бутап язган. Шул сәбәпле, чиктән тыш сурәттә хата барлыкка килгән. Моңа исә бу ике кемсәнең исеме, күньясе, кушаматы, шәһәре һәм заманы да уртак булулары сәбәп булуы хәтергә килә. Гыймадеддин Әбү әл-Фида Исмәгыйль бине Гали «Әл-мохтасар фи тарих әл-бәшәр» исемле тарих китабы төзүчесе булып, «Хәмаһ шәһәреннән әл-Мәлик Мөәййид» дип билгеле. Димәшкъ әмирләреннән булып, вафаты 712дә иде. Әмма безнең бу җирдә телгә алынган Гыймадеддин Әбү әл-Фида Исмәгыйль бине Гомәр «Әл-бидаятү вә ән-ниһая» исемле тарих (китабы) төзүчесе һәм Ибне Тәймиянең шәкерте булып, әл-Хафиз һәм Ибне Кәсир дип танылган. Вафаты 74 яшендә 774нең шәгъбан аенда иде («Кәшеф әз-зонун» аның вафатын төрле урында төрлечә күрсәткән). Әбү әл-Фида Исмәгыйль әд-Дәнәшмәнди боларның һәр икесеннән башка (кеше).

# XIX

## Хәдис гыйлемендә ышанычлы имамнар һәм [аларның] вафат еллары

«Көтебе ситтә һәм төзүчеләре»ннән башка хәдис гыйлемендә тагын берничә хөрмәтле имамнар бар, хәдисләре кабул ителә һәм үзләре дә «Көтебе ситтә» төзүчеләре кебек ихтирам ителәләр. Болар исә шулар:

1) Әбү Мөхәммәд Габдулла бине Габдрахман әс-Сәмәрканди **әд-Дарими**, 255.

2) Әбү Бәкер Әхмәд бине Гамру әл-Басри **әл-Бәззар**, 292.

3) **Әбү Ягъләә** Әхмәд бине Гали әл-Мәүсыйли, 307.

4) Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Исхак **Ибне Хөзәймә ән-Нисабури**, 311.

5) **Әбү Гаванә** Ягъкуб бине Исхак әл-Әсфәраини ән-Нисабури, 316.

6) Әбү Җәгъфәр Әхмәд бине Сәләмә әл-Әзди әл-Мисри **әт-Тахави**, 321.

7) Әбү Хатим Мөхәммәд бине Хиббан бине Әхмәд әл-Бөсти **Ибне Хиббан**[110], 354.

8) Әбү әл-Касыйм Сөләйман бине Әхмәд **әт-Табарани**, 360.

9) Әбү Әхмәд Габдулла әл-Җөрҗани **Ибне Гади**, 360[111].

---

[110] Замандашлары тарафыннан динсезлек белән гаепләнеп, иленнән сөрелде. Бу кемсәне «Даирәт әл-мәгариф» төзүчеләренә иярү йөзеннән, «Камус әл-әгълям» иясе беренче мәртәбә Ибне Хиббан сүзе астында Әбү Хәмид бине Әхмәд дип аңлатып һәм икенче тапкыр Әбү Хатим бине Хиббан сүзе астында телгә алган.

[111] 323тә вафат булган Габделмәлик бине Мөхәммәд Ибне Гади белән шөбһәләнепме, бу кемсәнең вафаты «Камус әл-әгълям»да 323 дип күрсәтелгән.

10) Әбү Бәкер Әхмәд бине Мөхәммәд әд-Динәвәри **Ибне әс-Сөнни**, 364.

11) Әбү әл-Хәсән Гали бине Гомәр әд-Даракутни, 385.

12) Әбү Нәгыйм Әхмәд бине Габдулла әл-Әсбахани, 430[112].

13) Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Габдулла ән-Нисабури **әл-Хәким**, 405.

14) Әбү Мөхәммәд **Габделгани** бине Сәгыйд әл-Мисри әл-Әзди, 409.

15) Әбү Бәкер Әхмәд бине әл-Хөсәен **әл-Бәйһәкый**, 458.

16) Әбү Гомәр Йосыф бине Габдулла ән-Нәмәри әл-Куртуби **Ибне Габделбәр**, 463.

17) Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали әл-Багдади **Ибне әл-Хатыйб**, 463.

# XX

## «Көтебе ситтә»дән башка булган басылган хәдис китаплары

Күз уңыбызда булган бер хисап дәфтәренә караганда, җиһанның һәр тарафында булган типографияләрдә бу көнгә кадәр басылып таралган хәдис китапларыннан кайберләре болар:

**«Әл-итхафат әс-сөнниятү фи әл-әхәдис әл-кудсия».** Шәех Мөхәммәд әл-Мәдәни хезмәте булып Хәйдәрабад әд-дәкәндә басылган.

**«Әхсән әл-хәдис».** Төркия галимнәреннән Укчызадә хезмәте булып, монда исә кырык хәдис-шәриф язылган һәм төзүче тарафыннан һәрбер хәдискә төркичә шәрех әйтелгән. 1035 елда

[112] «Камус әл-әгълям»да хата белән төзелгән булса кирәк, 403 рәвешендә күрсәтелгән, дөресләргә тиешле.

тәмам булганлыгы китапның ахырында телгә алынган. 1313 елда Истамбулда «Әкъдам» типографиясендә нәшер ителде.

**«Әл-әрбәгунә хәдисә».** Төзүчесе Нәвави булган бу хезмәт Һиндстан, Мисыр, Истамбул, Казан һәм Петербург шәһәрләрендә күп тапкыр басылды. Аның басылган шәрехләре болар: 1) «Әл-фәтех әл-мөбин», Ибне Хәҗәр әл-Мәкки хезмәте; 2) «Әл-фөтүхат әл-вәһбия», Ибраһим Мәргый әш-Шәбәрхыйти хезмәте; 3) «Әл-мәҗалис әс-сәнийя», Әхмәд бине Хәҗар [әл-Хиҗази] әл-Фәшни хезмәте. Әүвәлгесе 1307дә, икенчесе 1304тә, өченчесе 1299 һәм 1303тә Мисырда басылган.

**«Әл-әрбәгунә хәдисә».** Исмәгыйль Хәккый хезмәте булып, Гали Хафиз әл-Кастамуни шәрехе белән бергә 1303дә Истамбулда басылды.

**«Бөлуг әл-мәрами мин әхәдис әл-кәлям».** Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани хезмәте булган бу китап Әбү әл-Хәер Нур әл-Хәсән әл-Хөсәени әл-Кануҗи әл-Бохари шәрехе белән 2 томда 1302дә Мисырда басылды. Хөрмәтле, мөхтәрәм Муса әфәнде Җарулла тарафыннан язылган «Ифадат әл-кирам» исемле шәрехе «Вакыт» газетасында һәм «Шура» журналы наширләре булган Мөхәммәдшакир әфәнде белән Мөхәммәдзакир әфәнде тарафыннан Казан шәһәрендә Харитонов типографиясендә басыла башлавы исемебезгә килгән ике-өч формасыннан мәгълүм булды. «Ифадат әл-кирам» гыйльми өслүб белән язылганлыктан, гүзәл бер хезмәт булачагына өметебез зур.

**«Мең бер хәдис шәрехе».** Мөхәммәдгарифбәк тарафыннан «Җамигъ әс-сагыйр»дән сайлап алынып, үзе тарафыннан төркичә язылган шәрехе белән бергә 460 биттә 1319да Мисырда басылды. Аның мәтенен аерып 1327дә Казан шәһәрендә дә бастырдылар.

**«Әт-тәргыйб вә әт-тәрһиб».** Зәкиеддин Габделгазыйм бине Габделкави әл-Мөнзири тарафыннан төзелгән бу хезмәт 2 томда 1324тә Мисырда басылды.

**«Тәйсир әл-вөсули илә мәгърифәт әл-усуль».** Ибне Әсирнең «Җамигъ әл-усуль»ыннан Ибне әр-Рабигъ исемле кемсә кыскарткан хезмәт. 1253тә Калькутта шәһәрендә басылды.

**«Әл-җамигъ әс-сагыйр фи хәдис әл-бәшир эн-нәзир».** Сөютый хезмәте. 2 томда 1286да Болакта һәм 3 томда 1325тә Мисырда басылды. Китап читендә бу шәрехләре дә бергә басылган: 1) «Әс-сираҗ әл-мөниру фи шәрхи әл-җамигъ әс-сагыйр; 2) «Шәрех әл-хәфәни». Сөютый бу хезмәтендә бик күп мәүдуг [ялган] хәдисләр кертүе әйтелә. Шуның өчен бу китапны хәдис китабы булу сыйффатыннан күбрәк хәдисләр эчтәлеге булу сыйффаты белән кулланырга тиешле.

Замандашларыбыздан Мөхәммәд Бәдреддин әл-Хәләби әйтә: «Сөютыйның китап язу юлы, безнең белүебезчә, шул: әгәр дә аның кулына төрле гыйлемнәрдән торган китап килеп керсә һәм ошаса, әлеге китапны кыскарта һәм үзенеке итә. Шул ук вакытта Сөютый андагы кирәкле һәм кирәксез нәрсәләрне аермый һәм асылына да төшенми. Шуңа күрә аның хезмәтләрендә бик күп каршылыклар бар, чөнки үз акылын эшкә җикми, ә, бәлки, шул китапны язган автор фикере белән бара, кайбер үзгәрешләр генә кертеп, аны үзенеке итә. Мәсәлән, әгәр дә Сөютыйның «Әл-җамигъ әс-сагыйр фи хәдис әл-бәшир эн-нәзир», «Әл-әлләали әл-маснугатү фи әл-әхәдис әл-мәүдуга» китапларын укысаң, беренчесендә бик күп хәдисләрне дөрес дип атый, әмма «Әл-әлләали»дә шул ук хәдисләрне ялган дип хөкем чыгара. Болардан шул аңлашыла: Сөютый үзе язмый, ә, бәлки, башка кешеләрнең китапларын кыскартып, үзенеке итә»[113].

**«Җәвамигъ әл-кәлим».** Урта сыйныфларда балалар өчен һәм әхлак, гарәп телен яхшыртырга китап юклыгына шикаять итүчеләр күп булганлыктан, бу хезмәтне телгә алынган «Җамигъ әс-сагыйр фи хәдис әл-бәшир эн-нәзир» китабыннан сайлап алып

---

[113] Әт-тәгълимү вә әл-иршад. – Т. 1. – Б. 92–93.

[төзегән] идем. Соңра, мәүдугат [ялган хәдисләр] китапларында һәм «Җамигъ әс-сагыйр» шәрехләрендә мәүдуг булуларына ишарә иткән хәдисләрне төшерә-төшерә яруымнан аз калды. Бу калганнарының күбесенең асылын «Көтебе ситтә»дә таптым. Берничә шөбһәле хәдис калса да, шул хәленчә 1326да Казан шәһәрендә басылды. Цензор тарафыннан хәдисләр бозылуы сәбәпле, өч-дүрт мәртәбә төзәтеп һәм үзгәртеп язарга туры килде.

**«Әл-җәваһир әл-мөнифәтү фи әдилләт әл-имам Әби Хәнифә».** Төзүчесе Сәед Мортаза Зәбиди булган бу хезмәт 2 томда 1296да Искәндәриядә басылды.

**«Румуз әл-әхәдис».** Төзүчесе Әхмәд Зыяэддин әл-Көмешханәви булган бу хезмәт 1307дә 468 биттә Казан шәһәрендә басылды. Аның «Әл-ләвамигъ әл-бәййинат» исемле шәрехе Истамбулда басылган иде.

**«Әл-каүл әл-мөсәддид галә мөснәд әл-имам Әхмәд».** Төзүчесе Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани булган бу хезмәт Хәйдәрабад әд-дәкәндә бер томда басылды.

**«Кәнз әл-гоммәл фи сөнән әл-экъвали вә әл-әфгаль».** Гали бине Хөсамеддин әл-Мөттәкый тарафыннан кыскартылган бу хезмәт Хәйдәрабад әд-дәкән шәһәрендә һәм Әхмәд бине Хәнбәл «Мөснәд»е китап читендә Мисырда басылды.

**«Көнузәл-хәкаикый фи хәдиси хайр әл-халаикъ».** Мөнави тарафыннан 10000 хәдис-шәриф сайлап алып төзегән бу хезмәт (?) дә басылган.

**«Мәбарикъ әл-әзһари шәрхү мәшарикъ әл-әнвар».** Төзүчесе Ибне Мәлик булган бу хезмәт мәтене белән бергә бер томда Мисырда басылды.

**«Мөснәдү Әби Хәнифә әл-имам әл-әгъзам».** Төзүчесе Мөхәммәд Габид әл-Мәдәни әс-Синди булган бу хезмәт 373 биттә ташбасма белән Ләкнәү шәһәрендә басылды. Бу исем белән Әбү әл-Мөәйяд Мөхәммәд бине Мәхмүд әл-Хаварезми (665) тарафыннан төзелгән икенче бер хезмәт 1326да Мисырда басылды.

**«Мөснәдү Әби Дауд әт-Таялиси».** Бу хезмәт Һиндстанда Хәйдәрабад әд-дәкәндә бер томда басылган.

**«Мөснәдү Әхмәд бине Хәнбәл».** 1303тә 6 томда Мисырда басылды.

**«Мишкят әл-мәсабих».** Төзүчесе Вәлиеддин әл-Хатыйб булган бу хезмәт 1259да Калькуттада 4 томда һәм, соңыннан, икешәр томда Петербург шәһәрендә басылды. Әүвәлгесе ташбасма белән басылып, соңгысы да хәреф белән 1899да Мөхәммәдгалим әфәнде әл-Максуди акчасы белән басылды. Бу китапның басылган шәрехләре болар: 1) «Әшиггат әл-ләмгат», мәтене белән бергә 1259да Калькуттада басылды; 2) «Миркат әл-мәфатих», төзүчесе Гали әл-Кари булган бу хезмәт 5 томда 1309да Мисырда басылды. «Мишкят әл-мәсабих»нең бүгенге көндә Казан шәһәрендә басылуы да ишетелде.

**«Мәсабих әс-сөннә».** Төзүчесе Багави булып, хәдисләре, якынча, 4719. Аның 315е Бохари һәм 875е Мөслим хәдисләре булып, 1051е аларның икесенеке дә, аннан калганнары башка мөхәддисләрдән сөйләнелгән. «Мәсабих» 2 томда 1294тә Болакта басылган[114].

**«Мәгани әл-әсәр».** Төзүчесе Имам Тахави булган бу хезмәт ташбасма белән 2 томда Ләкнаһурда 1302дә басылды.

**«Әл-мөгътәсыйру мин әл-мөнтәхаби мин мөшкил әл-әсәр».** Төзүчесе казый Әбү әл-Мәхасин Йосыф бине Муса әл-Хәнәфи булган бу хезмәт бер томда Хәйдәрабад әд-дәкәндә басылды.

**«Мөнтәкый әл-әхбари фи әл-әхкям».** Төзүчесе Мәҗдеддин бине Тәймия булган бу хезмәт Шәүкяни тарафыннан

---

[114] Хөрмәтле әтием Фәхреддин хәзрәтнең 1296–1879 елда хаҗ сәфәреннән алып кайткан язма – «Мәсабих әс-сөннә» ахырында күчерүчесе шушы гыйбарәне язган: «Аллаһның рәхмәте һәм ярдәме белән китап тәмамланды. Аны фәкыйрь, зәгыйфь, гөнаһлы, Аллаһның рәхмәтенә мохтаҗ бәндә Әюб бине Ягкуб әл-Әбкәрми рабыгыль-ахир аеның уртасында якшәмбе көнне Бурса шәһәрендә һиҗри 774 елда язып бетерде. Аллаһ аларны төрле афәтләрдән сакласын!»

язылган «Нәйл әл-әүтар» исемле шәрехе белән 8 томда 1297дә Мисырда басылды.

* * *

Хәдис фәнендә болардан башка да басылган китаплар, китапчыклар булса кирәк. Белгәнебезгә караганда белмәгәнебез күбрәк булачагында шөбһә юк.

Монда телгә алынган хәдис китапларының һичберсе «Көтебе ситтә» дәрәҗәсендә түгеллеген сөйләргә хәҗәт юк. Үз араларында иң хөрмәтлеләре «Мөснәдү Әхмәд бине Хәнбәл», аннан соң «Мөснәдү Әби Дауд әт-Таялиси» һәм аннан соң имам Нәвави белән Ибне Хәҗәр, аннан соң Мәҗдеддин бине Тәймия хезмәте булса кирәк. Имам Сөютыйның «Әл-җамигъ әс-сагыйр»е хакында замандашларыбыздан бер зат әйтә: ««Әл-җамигъ әс-сагыйр» кебек Сөютый хезмәтләре һәм аның кыскартылганнары зәгыйфь, бәлки, мәүдуг хәдисләрне үз эченә алган. «Әл-җамигъ әс-сагыйр»ның хәдисләрен, хәдис әһелләре юлы буенча, чыгарырлык шәрех язучы бу көнгә кадәр пәйда булмаган. Хәлбуки, мөселман шәкертләре «Әл-җамигъ әс-сагыйр»ны хәтта «Сахих әл-Бохари»дан да артык күреп шөгыльләнәләр.

# Йомгак

Ислам дине иҗтимагый тормыш өчен кирәкле булган гыйлемнәрне уку һәм укытудан тыймый түгел, хәтта, киресенчә, рөхсәт итә. Шуның өчен изге галим булуның сәбәбе булган гыйлемнәрне һәм һөнәрләрне ислам шәкертләре укыган вакытта һәм укыган җирләрдә ала белерләр. Шәригатебез гыйлемле эт белән гыйлемсез этләрне бер хөкемдә санамаган, бәлки, әүвәлгесенә кайбер өстенлек биргән. Инде адәм балаларына ни калды?! Бу сүзләребез, югарыда да әйттек, дөньяви гыйлем һәм мәгърифәт хакында. Әмма дини гыйлемнәрне алу ниятендә булганнар өчен иң беренче максат итеп Коръән һәм хәдис-шәриф гыйлемнәрен тотарга тиешле булса кирәк. Галәмнәрнең горурлыгы һәм җан ияләренең патшасы булган әфәндебез хәзрәтләре: «Сезгә ике нәрсә калдырдым, әгәр шуларга ябышсагыз һич адашмассыз, ул – Аллаһының китабы һәм рәсүленең сөннәте», – дип боерган (Җамигъ бәян әл-гыйлем. – Б. 168–217).

Коръән һәм хәдис гыйлемнәреннән мәгълүматы булмаган адәм үзенең тоткан шәригатен аңлы рәвештә ничек белсен?! Сәхабәләргә, табигыйннарга, изге сәләфләргә нинди җеп белән мәхәббәт багласын?! Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең сияр-шәрифәсе [тормыш юлы], әхлагы һәм күркәм гадәтләре белән ничек таныш булсын?!

Аннан моннан ишетелгән яки ата-анага һәм башкаларга иярү сәбәпле багланган ихлас нигезсез һәм мәхәббәте тә көчсез булыр. Хәләл һәм хәрам гыйлеме кирәк булса, Коръән һәм сөннәттә; әхлак гыйлеме кирәк булса, башы боларда; сира [пәйгамбәрнең тормыш юлы] гыйлеме кирәк булса тагын боларда.

«Фикыһ китаплары төзелү сәбәпле, хәдис гыйлеменә ваемсызлык хасил булды, фикыһ китапларын укыган адәмнәрнең хәдис китаплары белән шөгыльләнергә хәҗәтләре калмады», – дигән кемсә бик хата сөйли. Чөнки фикыһ китабында дөньядагы вакыйгаларны ихтимал тотмаган мәсьәләләр күп булса да,

монда булган мәгълүмат, хәдис китапларына нисбәт белән, бик аз. Никадәр хәдисләр, хәтта мөҗтәһидләр ишетмәгәннәре, риваять ителә. Хәдисләрнең аерым мәсьәләләргә караган өлешләре булган кебек, тарих, әхлак, ахирәттә булачак бәхеткә һәм бәхетсезлекләргә караган бүлекләре дә бик күп. Хәлбуки, аерым мәсьәләләрдән башкалары фикыһ гыйлемендә телгә алынмый.

Бер гыйлем, әгәр дә аның асылы галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез хәзрәтләренең эшләреннән, сүзләреннән гыйбарәт булса, нәтиҗәсе дә дөньяда һәм ахирәттә бәхеткә тоташу булса, аның кирәклеге хакында сүз сөйләргә хәҗәт юк.

# Эчтәлек

Кереш сүз *(А. Гайнетдинов)* ........................................ 3
Бүләгем ........................................ 6
Кереш ........................................ 7
I. Хәдис һәм сөннәт, аларның сөйләнүләре ........................................ 8
II. Хәдис гыйлеменең фазыйләте.
Риваять һәм дираять хәдис.
Хәдис нигезләре хакында басылган хезмәтләр ........................................ 11
III. Хәдис, хөрмәтле сәхабәләр һәм табигыйннар ........................................ 14
IV. Хәдис һәм мәшһүр мөҗтәһидләр ........................................ 16
V. Хәдисләрне язу хакында рөхсәт һәм тыюлар ........................................ 19
VI. Хәдис һәм тарих ........................................ 22
VII. Сәнәд һәм мәтеннәр, бу турыда булган вазыйфалар ........................................ 23
VIII. Мөхәддисләр һәм ятлаулары, сахих хәдисләр ........................................ 26
IX. Тормыш һәм күренми торган
нәрсәләргә караган хәдисләр ........................................ 29
X. Мәүдуг хәдисләр. Хәдис уйлап чыгаручылар.
Мәүдуг хәдисләр хакында басылган хезмәтләр ........................................ 33
XI. Хәдис китаплары язылуы. Нигезләре һәм мөснәдләр.
Хәдис теле ........................................ 36
XII. Хәдис китаплары белән гамәл кылу ........................................ 39
XIII. Әсмаи риҗәл (хәдис тапшыручылар исемнәре)
һәм бу турыда булган басылган хезмәтләр ........................................ 42
XIV. Хәдис гыйлеме һәм Русия мөселманнары ........................................ 44
XV. Хәдис һәм аның мөгаллиме ........................................ 47
XVI. Көтебе ситтә ........................................ 50
1. «Сахих әл-Бохари» ........................................ 51
2. «Сахих Мөслим» ........................................ 58
3. «Сөнән Әби Дауд» ........................................ 59
4. «Әл-мөҗтәба» ........................................ 60
5. «Җамигъ эт-Тирмизи» ........................................ 61

6. «Сөнән Ибне Маҗә» .................................................. 62
7. «Әл-мөватта» .................................................. 63
XVII. «Көтебе ситтә» төзүчеләре .................................................. 65
Имам Мәлик .................................................. 65
Имам Бохари .................................................. 71
Имам Мөслим .................................................. 86
Имам Әбү Дауд .................................................. 87
Имам Нәсаи .................................................. 88
Имам Тирмизи .................................................. 89
Ибне Маҗә .................................................. 90
XVIII. «Көтебе ситтә» җыентыклары .................................................. 91
XIX. Хәдис гыйлемендә ышанычлы имамнар
һәм [аларның] вафат еллары .................................................. 93
XX. «Көтебе ситтә»дән башка булган басылган
хәдис китаплары .................................................. 94
Йомгак ..................................................100

***Гайнутдинов Айдар Марсилевич***
*(составитель)*

**Ризаэтдин Фахретдин.**
**Шесть книг по хадисам и их составители**

*(на татарском языке)*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *Л.М. Зигангареева*
Подписано в печать 20.11.2019 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. листов 6,5 Тираж 200 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

Логос
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46, 231-08-71,
231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

**Сайт**
**Института истории**
**Академии наук РТ**
**Татаровед.рф**